НОДАР
ДУМБАДЗЕ

Мәңгелек канун



НОДАР ДУМБАДЗЕ



Мәңгелек канун

РОМАН

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1986

ББК 84.Гр.-4
Д-77

1980 елда Нодар Думбадзеның «Мәңгелек канун» («Закон вечности») романы Ленин премиясе белән бүләкләнде.

Русчадан НАИЛӘ ВӘЛИТОВА тәрҗемәсе

Әсәр 1979 елда Тбилисидә «Мерани» нәшриятында чыккан китап буенча тәрҗемә ителде.

Думбадзе Нодар Владимирович
Д77 Мәңгелек канун: Роман.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.— 231 бит.

Нодар Думбадзе — танылган грузин язучысы.
Кеше тормышының мәгънәсе, асылы турындагы уй-фикерләргә бай фәлсәфи бу романында язучы бүгенге көннең күп кенә үткен мәсьәләләрен кузгата.

Д $\frac{4702170000-241}{М132(03)-86}$ 72—86

© татарчага тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 1986.

1

Иң элек аның уң як җилкәсе авыртырга кереште, аннары әрнү әкрен генә, сулкылдап, күкрәгенә таба үрмәләде һәм сул имчәк турысына җитәрәк туктап калды. Шуннан кемнендер сөялле тупас кулы, күкрәк читлегенә кереп, йөрәкне учына йомарлап тотты, йөзем тәлгәшен сыткандай, рәхимсез кысарга кереште. Ул аны ашыкмыйча, тырышып-тырышып кысты: бер-ике, ике-өч, өч-дүрт... Инде, ниһаять, сыгылып, тәмам хәлен җуйган йөрәктә канның тамчысы да калмагач, шул ук кул аны гамьсез генә читкә алып ыргытты. Йөрәк тибүдән туктады. Хәер, башта ул, тәрәз пыяласына килеп сугылган кошчык сыман, каядыр түбәнгә очты, бәргәләнде, тырпылдады һәм шуннан соң инде хәрәкәтсез тынып калды. Әмма йөрәкнең туктавы әле үлем түгел, ул — һәлакәтле дәһшәт алдында зур булып ачылган күзләр, ул — газап катыш сагаеп көтү: кузгалырмы тагын, юкмы каһәр төшкән бу йөрәк?

— Йөрәкне каһәрләргә ярамый, батоно [1]! Аны кадерләргә, кайнап, ташый башлаган сөткә өргәндәй, өф-өф итеп кенә торырга кирәк...— диде шунда фельдшер хатын.

— Кадерлем, матур әдәбият кайгысы түгел миндә! Ярдәм итсәгез иде!

— Надя, анальгин!.. Хәзер, сызлавы бераз басылыр.

— Доктор, эчкән ләбаса ул!

— Кардиограммасын ясагыз!

Кемдер куллары белән авыруны кочаклап тотты.

— Йә, ничек? — дип сорады врач.

— Бик тирән... Белмим, нәрсә генә эшли алырбыз икән...

— Авыртамы?

— Доктор, зинһар, бу әрнүдән коткара күрегез, инде юк икән, йомдырыгыз гына шунда!

---

[1] *Батоно* — Грузиядә ир-атка хөрмәтләп эндәшү сүзе.

— Промедол!

. . . .

Биш минут чамасы вакыт үтте.

— Ничек, бераз җиңеләйдеме?

Авыру кеше, кайсысы шундый беркатлы сорау бирә икән дип, күзен ачып карамакчы иде, ләкин күз кабаклары, салкын кургаш кисәкләре бастырып куйгандай, ачылырга теләмәде.

— Морфий! — дип боерды тәмам аптырашка калган врач һәм җәһәт кенә телефон трубкасына сузылды: — Мин бу, Антелава. Мониторны бушатып, дефибрилляторны көйләгез. Тиз булыгыз!

— У-ух, үтерегез генә ичмаса! — дип сыкранды авыру.

— Азот! — дип боерды врач.

Авыру кеше шунда битенә дымлы марля кисәге орынуын тойды. Аннары аның гәүдәсен, иплэп кенә күтәреп алып, көймәгә китереп салдылар һәм...

...Көймә, җай гына чайкалып, тыныч диңгез өстеннән шудырып алып китте. Шул вакыт каекчы, кулына зур бер күгәргән кадак алды да, көчле йодрыгы белән сугып, авыруны күкрәк турысыннан көймәнең утыргычына беркетеп-кадаклап куйды.

— Нәрсә эшлисең син, вәхши! — дип ыңгырашты авыру.

— Юкса, көймәдән егылып төшүең бар! — дип аңлатты каекчы.

Аннары ул шундый ук күгәргән зур кадак белән авыруның аяк-кулларын да утыргычка ныклап беркетеп куйды һәм... үзе суга сикерде.

— Зинһар, ташлама мине, мәрхәмәтле бәндә! — дип инәлде авыру кеше.— Соң, кадакларны кем суырып алыр?

Ерактан, тоныкк кына булып, каекчының:

— Тегендә, аргы якка чыккач алырлар! — дигән тавышы килде.

Авыруның колагына яр буеннан ишетелер-ишетелмәс кенә башка тавышлар да чагылып киткәләде, ләкин ул аларның үзе белән хушлашу авазларымы, кемнәрнеңдер кисәтүеме, яки юату сүзләреме, әллә аны кызганып сыктауларымы икәнен тәгаен генә төшенмәде.

...Бераздан тавышлар тынды, сирәкләнеп, тәмам эреп юкка чыкты. Тәндә әрнү урынына тупас авырту, җанда газаплы бер билгесезлек калды, очсыз-кырыйсыз дәрья һәм, көймәгә кадакланган килеш, барысы тарафыннан онытылган ул үзе генә торып калды.

— И ходаем, и ходаем, ни өчен болай ташладың син мине?! — дип пышылдады авыру, тик шунда ук ул әлеге сүзләрнең үзе тарафыннан әйтелмәвен, шуңа ходайның да аны ишетмәячәген аңлап алды.

Ә көймә зәңгәр диңгез-дәрьяның уенчак дулкыннарында һаман шулай җай гына тирбәлә бирде...

Мең еллап вакыт үтте, һәм кинәт авыру шыксыз бер төртелү тойды. Аның тәнен үтәдән-үтәли тишеп әче әрнү яндырып үтте. Көймә яр читенә килеп туктады.

Шунда көймәне зур халык төркеме урап алды.

— И аллам, нинди нык кадакланган, бичара! — дип кызганды кайсысыдыр, көймәне ярга өстерәп.

— Суырып алыгыз шул кадакларны, башка түзәр хәлем калмады! — дип ялварды авыру.

— Яшвили кайда соң? — диде каршы алучыларның берсе.

— Монда мин!

— Алчы суырып!

— Бик тирән шул...

— Әйдәгез алайса, бөтенебез бергә! Йә... бер, ике — тарттык!

«И ходаем, суырып ала алмаслар микәнни?» — дип борчылды авыру, кулын чак кузгата төшеп.

— Хәрәкәтләнергә ярамый! — дип кисәтте кемдер аны һәм шундук янәшәсендәге кешеләргә дәште: — Йә, әйдәгез, тагын бер тапкыр тарт-тык!

Яңадан мең еллап вакыт үтте. Кешеләр авыруның тәнендәге кадакларны инде тешләре белән суыралар иде.

— Йә, ничек? — дип сорады арадан бер өлкәнрәге.

— Күтәрелә! — дип җавап кайтарды янәшәсендәгеләр.

— Ничә?

— Алтмыш!

— Ярар, басымны куеп торыгыз, йөрәкне карагыз хәзер!

— Йөрәк тибеше — илле!

— Котылды бугай! — диде шунда монитор янында басып торучысы.

— Тәгәрәп төшеп китте! — дип, авыру иркен сулап куйды.

— Нәрсә төшеп китте? — дип сорады врач гаҗәпләнеп.

— Тәгәрмәч төшеп китте! — дип кабатлады авыру.

— Нинди тәгәрмәч? Кайдан? — Докторның тавышы калтыранып китте.

— Менә моннан, шушы турыдан, батоно! — Кулын йөрәге турысына китереп, авыру елмаеп куйды.

Врач җиңел сулыш алды, авыруның маңгаена тибеп чыккан салкын тирне сөртте.

— Коткарып калдык бугай! — диде ул.

— Һм, шушы яшьтән инфаркт... Бик иртә түгелме? — диде шунда икенче берсе, калтыранган куллары белән кабыннан сигарет ала-ала.

Авыру, мондый беркатлы сорау биргән кешене күрергә дип, кабат күзен ачмакчы булды, тик ача алмады: күз кабакларын басып торган салкын кургаш кисәкләре тагы да авырая төшкән кебек иде...

...Ә аннары, әллә нинди җылы, җиңел-рәхәт һәм ал-су булып, тәнне гаҗәеп-хәйран савыктыргыч бер исерү биләп алды. Авырту бетте. Сихәтле исереклеккә талып, авыру янә озын юлга кузгалды. Тик монысында инде ул диңгез өстеннән йөзеп түгел, ә бәлки очсыз-кырыйсыз текә баскычлар буйлап барды. Шунысы гаҗәп тоелды аңа: баскычлардан түбән төшкән саен, ни өчендер ул үзен һаман югарырак күтәрелә барган кебек хис итте...

2

Кара күлмәк итәген чалбар өстенә чыгарып, киндерә буган биленә агач пычагын кыстырып куйган чатан аяклы Аветик Бабаянц җырлап ишегалдына килеп керде. Аның артыннан аркасына шарманка аскан бер хатын ияргән, хатын артыннан исә, маңгаена салынып төшкән озын ак йон арасыннан төймә сыман түгәрәк кара күзләрен елтыратып, кечерәк бер эт — француз болонкасы теркелди иде.

Бабаянцның күчмә театры ишегалдының нәкъ урта бер җирендә туктап калды. Аксак артист дүрт катлы йортның балконнарына чыгып тезелешкән хатыннарны канәгать бер елмаю белән күздән кичерде дә фырт кына сул кулы белән билендәге пычагының сабына таянды, уңы белән хатын-кыз халкына үбү ишарәсе юллап, үз театрының репертуарын игълан итте.

— Тбилисиның хөрмәтле тамашачылары һәм галиҗәнаблары! Грузиянең дан казанган артисты Аветик Бабаянц карамагындагы сәхра театры бүген сезгә «Отелло» трагедиясенең заманча эшләнгән яңа вариантын тәкъдим итә. Катнашалар:

Отелло — Аветик Бабаянц,
Дездемона — Мария Павловна,
Яго — болонка Стелла.
Увертюраны шарманкада Мария Павловна башкара. Билет бәясе — егерме тиен. Хакы алдан түләп куела!

— Башла әйдә, аңгыра баш!

Мария шарманканың сабын әйләндерергә кереште. Шарманканың карлыккан тавышына кушылып, Аветик Бабаянц җыр суздды:

Багдадтан чебен оча...
Багдадтан чебен оча...
Һай-да-да-да, һай-да-да-да...
Арагызда кем изге зат,
Әйдә, тизрәк акчаңны ат!
Һай-да-да-да, һай-да-да-да...

Ишегалды ташына яңгыр булып вак акчалар чылтырап коела башлады. Бала-чага, ач чыпчык көтүе сыман, акчага ябырылды.

— Әй, юлбасарлар, сез тагын үзегезнең кесәгә шудырмагыз!

— Монда бакыр акчалар да бар, Бабаянц абый!

— Аларын, утта кыздырып, берәр төшеңә чәпәп куй, ә көмешләрен монда китер!

— Ә иләк ягы белән төшкәннәрен?

— Монда китер, монда, кесәгә кергәч күн ягы белән әйләнә ул!

— У-у, кара син, күпме җыелды!

— Атаң алган хезмәт хакыннан бер дә артык түгел!.. Әй, Мария, нәгъләт, чыгар ими капчыгыңа яшергән акчаларны!

Ясак җыю шуның белән тәмамланды. Бабаянц биленә буган киндерәсен чишеп, акчаларны чалбарының эчке кесәсенә салды, тышкы кесәсеннән газета чыгарып, урам ташына җәйде, аннары шырпы сызды. Газета янып беткәч, көлен сак кына учына җыеп шуңа төкерде дә икенче учы белән ышкып угач, корымлы куллары белән битен сыпырды һәм... куанычлары эченә сыймаган тамашачыларның күз алдында Венеция маврына әверелде.

— Стелла, бире чык! — дип боерды Отелло.

Көчек аның янына чабып килде. Отелло, иелә төшеп, колагын этнең ялтырап торган кара борынына китерде. Көчек — Яго рәттән өч тапкыр өрде дә арт тәпиләренә басты.

— О! — дип күкрәде Отелло, тамашачыларга ка-

рап.— Яго, беләсезме, нәрсә ди: минем хатыным Дездемонаны Қассио белән бутала ди!

Отелло, йөзенә коточкыч зур кайгы галәмәте чыгарып, кабат болонканың борынына иелде, эт тагын өч тапкыр өрде. Бу юлы аның тавышы усалрак һәм катырак яңгырады.

Отелло бермәлгә тәмам аптырап калды. Аннан, «инде хәзер нишләргә?» дигән сыман, берәр минут чамасы сүзсез-өнсез торды да кинәт шаркылдап көләргә тотынды:

— Ха-ха-ха! Юк, юк, ышанмыйм! Ялганлыйсың, эттән туган нәрсә!

Шушы сүзләрне ишетүгә, Стелла Мария янына йөгереп барды да аның кулындагы чәчәкле Багдад яулыгын тешләре белән йолкып алып, маврга китерде. Отелло, яулыкны күреп, тораташтай катып калды.

— Әйе, узган ел мин Мариягә бүләк иткән яулык бу,— дип фаҗигале тавыш белән кычкырып җибәрде ул һәм башын рәттән өч тапкыр сәрби куагына китереп орды. Куркышкан чыпчыклар төрлесе төрле якка сибелеште.— Мария, кил бирегә! — дип, Дездемонаны чакырып алды мавр. Хатын, шарманкасын куакка сөяп куйды да, башын түбән иеп, Отелло катына килеп басты.

— Мин бүләк итеп биргән яулыкны син кая куйдың? — диде Отелло, хатынына сынаулы караш ташлап...

— Нәрсә бәйләнәсең миңа? Қайдан белим мин синең яулыгыңны? Үзең югалткансың, йә каядыр куйгансың да хәзер миннән таптырасың! — дип әрепләште Дездемона.

— И-и, себерке! Син дә йөрисең бит хатын-кыз булып! Қемгә алыштырдың син мине?! Шул адәм актыгы Қассиогамы?! — Отелло, акылдан шашардай булып, Дездемонаның муенына килеп ябышты.

— Чамалабрак кылан, ахмак!— Дездемона, Бабаянцның кулыннан чак ычкынып, җиргә алдан җәелеп куйган шәл өстенә барып ятты.

Отелло тагын бер тапкыр шаркылдап көлде, җиргә тезләнеп, колагын Дездемонаның күкрәгенә куйды. Аннары, хатынының үлгән икәнлегенә ышангач, коты чыгып, ике кулы белән чигәсенә ябышты. Шуннан соң билендәге агач пычагын суырып алды да термометр куйган сыман култык астына кыстырды һәм гөнаһсыз хатынының җансыз гәүдәсе янына ауды. Ул арада болонка, җай чыкканны көтеп кенә торгандай, сәрби куагына сө-

яп куелган шарманка янына чабып барды һәм, арт тәпиен күтәреп, аңа сиптереп җибәрде.

Шуның белән трагедия тәмам булды.

— Браво, Бабаянц! — дип шау килде балконнар.

— Браво, Отелло! — дип шаулашты верандалар.

— Браво, Мария! — дип бөтен өй шау-гөр килде.

— Браво, Дездемона! — дип хатын-кыз халкы чәрелдәде.

— Браво, Стелла! Браво, Яго! — дип бала-чага чырчу купты...

Аш бүлмәсендә ут яна. Анда, кемнедер, дүртенче берәүне уятырга курыккандай, әкрен генә, шыпыртлап диярлек, өч кеше сөйләшә иде. Стена сәгате төнге икене сукты.

— Зинһар, ашыга төшегез, безнең әле тагын да керәсе җиребез бар...— диде ир кеше.

Калтыранган куллары белән чемоданга кием-салым тутырып азапланган хатын почмакта елап торган икенче бер ханымга инәлеп карады:

— Оля, бар өметем синдә... Баланы әни янына, Хонига [1] кайтарып куярсың...

— Борчылма, Анико! — диде тегесе сулкылдап.

— Иртәгә үк, яме!

— Андый васыять сүзләре әйтү кирәкми, калбатоно [2],— дип, сүзгә ир кеше кушылды.— Әйттем ич мин сезгә: ирегез хакында берничә сорау бирерләр дә кайтарып җибәрерләр. Никадәр җәһәтрәк җыенсагыз, шул кадәр тизрәк кайтырсыз...

— Нигә дип җаныңа гөнаһ аласың?! — диде хатын инәлеп.— Ичмасам, шул бичара баланы кызганыр идең! — Аның куллары калтырый, шуңа ул чемоданын яба алмый азаплана иде. Ир кеше ярдәмгә килде, чемоданны бикләп, хатынга бирде.

— Тизрәк кыймылдагыз, зинһар, калбатоно! Яктырып бетте бит инде!

— Нинди калбатоно булыйм мин сиңа?.. Җаныңда тузан бөртеге кадәр миһербаның калса, кызганыр идең мине... «Өендә туры китерә алмадым» дип әйтә аласың ич... Мин бүген үк юкка чыгам, дөнья күзеннән юк булам...— Хатынның тавышында сизелер-сизелмәс кенә өмет чаткысы ишетелеп киткәндәй булды.

---

[1] *Хони* — Цулукидзе шәһәренең элекке исеме.

[2] *Калбатоно* — Грузиядә хатын-кызга ихтирам белән эндәшү сүзе.

— Юк, бу мөмкин түгел!

— Алайса бер генә минут сабыр ит, улым белән хушлашыйм,— дип үтенде хатын.

— Өч мәртәбә хушлаштыгыз бит инде!

Хатын йокы бүлмәсенә таба атлады, әмма ир кеше өлгеррәк булып чыкты — аркасы белән ишеккә килеп сөялде.

— Җитәр, булды! Һәр нәрсәнең тәртибе бар!

— Бер генә минутка!

— Юк, житте!

— Үзеңнең дә хатының, балаң бардыр лабаса?!

— Юк, берсе дә юк һәм булмас та. Мин иректә кеше,— дип елмайгандай итте ир кеше.

— Ирекле тагын, кол син! Бичара кол, шамакай, кабахәт бәндә син! — диде хатын ачуыннан ярсып.

Ир кешенең йөзе агарынып китте:

— Кайсыбызның кол һәм кабахәт булуы тегендә баргач ачыкланыр. Ә хәзер, әйдә, җәһәтрәк кыймылда, югыйсә...

— Нәрсә — югыйсә?

— Ватанны сатучылар белән башкача сөйләшү мөмкин түгел!

— Син дә Ватан дип сөйләнгән буласыңмы?! Йолкыш!

— Бу сүзләреңне онытма!

— Онытмам!

Ир кеше хатынны, беләгеннән тотып, ишеккә таба алып китте.

— Оля! — дип кычкырды хатын.

— Анико! Кадерлем!

Ниндидер бер мизгелгә бүлмәдә тынлык урнашты һәм шунда кинәт ике хатын да берьюлы кычкырып елап җибәрделәр.

— Уф, бөтен дөньясының асты өскә килгере! Ни дип монда җибәргәннәрдер мине! — диде ир кеше тешләрен шыкырдатып.— Житте диләр сезгә! Мин дә кеше ләбаса! — Ул тамагына килеп утырган төерне көч-хәл белән йотып җибәрде.— Җитәр! Киттек әйдә!

Шапылдап ябылган ишек тавышына йокысыннан бала уянып китте. Ул тиз генә урыныннан күтәрелде, әнисенең караватына үрелеп карады. Караватбуш иде.

— Әни! — дип эндәште бала, әмма җавап кайтаручы булмады.

— Әни! — дип кабатлады бала әкрен генә. Аннары, әнисенең караватына килеп, юрганны күтәреп карады — әнисенең урыны җылы иде әле.

Табан асларын чымырдатып кузгалган курку тойгысы аның тезләренә үрмәләде, аннары эченә үтте, тынын буып, үпкәсенә сарылды һәм, ниһаять, күз бәбәкләренә чыгып, катып калды. Ялан аякларына чаклы төшеп торган озын итәкле ак күлмәген җилфердәтеп бала ишеккә ташланды.

Аш бүлмәсендә, тәбәнәк сәке өстендә башы белән кулларына капланып, Оля апасы утыра, аның җилкәләре калтырана иде. Бала апасының каршына килеп басты да әкрен генә:

— Оля апа, әни кайда? — дип сорады.

Апасы җавап бирмәде.

— Оля апа, әнием кайда минем? — дип, бала үзенең салкын, ябык куллары белән хатынның җилкәсенә кагылды.

— Әниең, Бачана...— Хатын ярты сүздә төртелеп калды.

— Әнием кая китте минем?!

Хатын баланы кочагына алып, башын күкрәгенә кысты, йөрәк өшеткеч әлеге сорауны ишетмәс өчен, кулы белән аның авызын каплады. Бала тынды, әммә иреннәре кыймылдавыннан хатын аның һаман да әле шул сорауны кабатлаганын тойды.

Менә бала туңып калтырый башлады, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты, зәңгәрләнеп калган иреннәре инде хәрәкәтсез иде.

— Раббым, ходаем, син дә күрмисеңмени соң шушы хәлне? Күреп торсаң, кайда синең илаһи кодрәтең?

Хатын, тәмам хәлсезләнеп, идәнгә, бала алдына төшеп тезләнде...

— Малайның йөрәге авыру ...һәм нервлары какшаган.

— Каян килеп? Ничек алай, доктор? — диде Оля апасы гаҗәпләнеп.

— Йөрәгендәге чирне тумыштан дип әйтмәс идем... Берәр зур кайгы-тетрәнү кичермәгәндер бит?

— Юк кебек!..

— Ничә яшь аңа?

— Тугыз.

— Ала-а-ай... гаҗәп... Бик гаҗәп...

Поезд, зур бер яшел корт сыман әкрен генә кыймылдап, Тбилиси вокзалыннан кузгалып китте. Оля апасы Бачананың өстен чишендереп, йоклаганда кия торган озын итәкле ак күлмәген кидертте, баш астына зур күн чемоданны салып, өске сәндерәгә яткырды.

— Йокла! — диде ул малайга, үзе тәрәзә буена барып утырды. Бачана стенага таба борылып ятты.

Халык белән шыгрым тулы вагонда бөркү иде.

— Ә йоклар алдыннан нәрсә дип әйтергә кирәк? — диде апасы малайга төбәлеп.

Малай елмаеп юлчыларга:

— Тыныч йокы! — диде дә тагын стенага таба борылып ятты.

— Күр син аны, нинди тәрбияле бала! — дип гаҗәпләнде чандыр гәүдәле бер пассажир.— Минекеләр берберсенә «эттән туган» дип кенә җибәрәләр, мин ишетер дип тә тартынып тормыйлар! Бу бала сезнең кемегез була инде? Улыгызмы?

— Улым...

— Ала-а-ай... Тик ул сезгә тамчы да охшамаган. Әтисенә тарткандыр, күрәсең.

— Әйе.

— Ала-а-ай... Алма агачыннан ерак төшми дип белми әйтмиләр шул...

Шулвакыт проводникның:

— Тәрәзә пәрдәләрен төшерегез!— дигән боерыгы яңгырады.

— Ни булды? — дип сорады Оля апасы.

— ЗАГЭС [1],— диде кайсысыдыр.

— Шуннан ни булган?

— Берәр диверсия эшләмәгәйләре дип куркалар,— диде шул ук тавыш.

— Диверсия... диверсия...— дип кабатлап куйды Бачана йокыга китеп барганда.— Нәрсә дигән сүз икән ул? Ярар, иртәгә иртән Оляападан сорармын әле...

Һәм шуннан соң озакламый аның күзләрен йокы басты...

...Төнлә аның янына әнисе килде. Ул, Бачананың баш астындагы чемоданны сак кына алып, аның урынына йомшак мамык мендәр салды. Малай талгын гына кыймылдап куйды. Әнисе аның, төнлә торып, бик еш шулай

---

[1] *ЗАГЭС* — Тбилиси тирәсендәге Земо-Авчал гидроэлектростанциясе.

мендәрен рәтли иде, шуңа күрә Бачана күзен дә ачып тормады, одеялына тәренебрәк кенә ятты.

Әнисенең:

— Башыңны мендәргә куй, улым...— дип пышылдавын ишетте, битләреннән иркәләп сыйпавын тойды ул... Тик нишләп соң бу куллар шулай кытыршы икән? Әнисенең куллары йомшаграк иде бит... Бәлки, әтиседер бу? Мөгаен, әтиседер, мендәр астына берәр бүләк куеп калдыргандыр әле.

— Гу-у-у-у...— дип кычкырта поезд.

...Бачана исә татлы йокыга талган. Ул гаҗәеп матур төш күрә... Имеш, Тбилиси пионерлар сараеның көзгеле зур залында малайлар, кызлар сафка тезелеп басканнар... Барысы да ап-ак күлмәк, кызыл галстуклардан... Бачана да шунда, пионерлар арасында. Бүген биредә бәйрәм көн: Хосе Диас белән Долорес Ибаррури Тбилиси пионерларына Испания республикасы балалары бүләк итеп җибәргән чуклы башлыкларны өләшә... Долорес Ибаррури — зифа буйлы, кара тут йөзле чибәр хатын — Бачанага баск малае исеменнән башлык тапшыра.

— Һәрвакыт әзер бул! — ди Ибаррури.

— Һәрвакыт әзер! — дип җавап кайтара Бачана салют биреп.

— Салют! — ди Долорес Ибаррури баш өстенә йодрыгын күтәргән килеш һәм, мөлаем елмаеп, Бачананың битеннән сөя...

Поезд, җилләр уйнатып, Ципи тоннеленнән килеп чыкты һәм Марелиси станциясендә туктап тормыйча, гудогын кычкырта-кычкырта (перронда торучы кешеләр куркышып, кайсы кая читкә тайпылыштылар), юлын дәвам итте.

— Һи, болай барсак, бер сәгать дигәндә без Самтредиага килеп тә җитәрбез! — диде муенына керләнгән бинт чорнаган карлыккан тавышлы пассажир.

Оля апасы борчыла калды:

— Самтредиада туктый микән соң ул? — дип сорады.

— Мцхетада безнең поездга ниндидер бер сәер вагон тактылар,— дип, бая Бачананы мактаган арык гәүдәле пассажир да сүзгә кушылды.— Баскычында хәрби кешеләр басып тора иде. Су алырга төшкәч күрдем...

Поезд, кечкенә станцияләрдә туктап тормыйча, һаман алга таба чабуында булды.

— Тагын ярты сәгатьтән — Самтредиа! Тукталыш —

өч минут! — Кулындагы ачкычы белән койка башларына суга-суга, вагон буйлап проводник узды.

— Бигрәк тиз җилдертә бүген сезнең поезд,— диде аңа ябык пассажир,— өстәп акча түлисе булмас микән?

— Барып җиткәч, станция начальнигыннан сорарсың! — дип мыгырданды проводник.

— Мине каршы алырга чыгар микән соң ул? — дип юри беркатлыланып шаяртуында булды ябык пассажир.

— Хөкүмәт башлыгы алдан хәбәр итеп куярга онытмаган булса, әлбәттә, каршы алыр!

— Хөкүмәтнең хәтеренә алай, минемчә, бик зарланырлык түгел... Мең тугыз йөз бишенче елны Илори чиркәве ишегалдында митингта кем өчен тавыш биргәнемне әле дә булса онытмый...

— Әй, син! Телеңне бик озайтма! Ходайга рәхмәт әйт: әле ярый минем колагым катырак...— дип кычкыра төшеп әйтте аңа проводник.

Чандыр юлчы шым булды. Ул арада поезд да әкренәя төште.

— Калбатоно, сез Самтредиада төшмәкче идегез бугай,— дип яшьрәк пассажир йокымсырап киткән Оля апага кулы белән кагылды.

Оля апа, сискәнеп китеп, күзен ачты:

— Нәрсә дисез?

— Самтредиага җитәбез дим. Сез төшәсез түгелме?

— Әйе.

Апасы, сикереп торып, Бачанага ташланды.

— Бачана, тор, үскәнем! Килеп җиттек!

Бачана койкасына торып утырды.

— Тизрәк, акыллым! — диде Оля апасы сумкалар белән кайнаша-кайнаша.

Малай баш очына кулын сузды һәм... сискәнеп китте:

— Оля апа, эни кайда?

— Ни сөйлисең син, Бачана? — Оля апасының тавышы калтыранып куйды.

Пассажирлар, гаҗәпсенеп, әле малайга, әле кинәт йөзе агарып киткән хатынга карап алдылар.

— Оля апа, төнлә белән, эни килеп, чемоданны алды! Кая китте ул?

Апасы шунда кечәге хәлнең яңадан кабатланачагын аңлады һәм тиз генә үрелеп баланы идәнгә төшерде, күкрәгенә кысты, учы белән авызын томалады.

— Зинһар, ярдәм итә күрегез!

Поезд туктады.

Самтредиа станциясенең дежурные өч тапкыр рәттән чаңга сукты. Икенче юлга килеп туктаган поезд акрын гына кузгалып китеп баргач, дежурный тораташтай булып басып калды: буп-буш перронда тузгыган чәчле, йөзе-кашы җыерылган, пальтосыз бер хатын белән аяк йөзенә җиткән озын итәкле ак күлмәктән, яланаяклы бер малай басып торалар иде. Бер-берсенең кулларына тотынышкан килеш алар хәрәкәтсез калганнар. Дежурный, беркавым һушсыз булып, шулай карап торды-торды да, үзе дә искәрмәстән, чаңның бавын тартып куйды. Төнге тирән тынлыкта ямансу-моңсу булып чаң авазы яңгырады.

Чаң... чаң... чаң...

— Зосим,— диде станция начальнигы үзенең ярдәмчесенә,— теге юньсезнең арт сабагын укытып кил әле! Эшкә тагын исереп килгән!

Бала белән хатын буш перронда һаман шулай кымшанмыйча басып тора бирделәр.

Ә чаң һаман үзенең моңсу җырын дәвам итте:

Чаң... чаң... чаң...

3

Өч койкалы палатада, йодоформ, спирт, камфара белән аралашып, яңа юылган дымлы идән исе аңкый иде. Бачана, әлеге исләрдән буыла язып, кулын сак кына хәрәкәтләндереп одеял читен борынына тартып куйды, аннары шулай ук сакланып кына пульсын капшап тапты. Йөрәге Бачананың кечкенә чагында, күзен йомган килеш, башын стенага терәп: «Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сиге-е-ез, сиге-е-ез я-я-рым, ту-гы-ы-ыз, ту-гы-ы-ыз я-я-рым, ун!» дип санагандагы кебек итеп тибә иде.

Бачана, кулын беләгеннән алып, йөрәк турысына куйды. Әмма йөрәгенең тибүен тоймады. Коты алынып, ул шунда ук яңадан пульсын капшап тапты. Пульсы элеккечә үк иде. Шуннан соң Бачана акрын гына одеял астыннан борынын чыгарды. Борынга тагын әче исләр ярып керде.

— Тәрәзә...— дип пышылдады Бачана ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Нәрсә? — дип телгә килде янәшәдәге койка.

— Оһо! Исәнмени әле ул? — дип сорады койканың икенчесе.

— Тапканнар монда мәет китерер урын! Палатамы

бу, әллә моргмы? — диде беренче койка хәтере калган тавыш белән.

— Әйтүләренә караганда, язучы кеше, имеш...— дип җавап кайтарды икенче койка.

— Язучының урыны Мтацминдада [1], монда түгел!

Бачана күрше койкаларның әңгәмәсен ишетеп ята иде, әлбәттә, әмма бу минутта аңа барыннан бигрәк саф һава кирәк иде.

— Тәрәзә! — дип кабатлады ул.

— Аңа монда нәрсәдер ошап җитми бугай, белмәссең, әллә һава, әллә тәрәзә шунда,— дип куйды беренче койка.

— Һава,— диде Бачана.

— Бөтен хикмәт тә шунда, хөрмәтлем, безгә урыннан тору түгел, хәтта кыймылдарга да ярамый,— диде икенче койка,— димәк ки, сестра килгәнче сезгә дә хөрмәтле Булика белән мин сулаган һавага риза-канәгать булып торырга туры килер.

Бачананың аңлавынча, беренче койканың исеме Булика икән. Хәзер инде икенче койкада ятучысының кем икәнлеген ачыкларга кирәк иде.

— Вакыт күпме? — дип сорады ул.

— Минемчә, изге атакайга хәзер ходай тәгаләгә рәхмәтләр укып, гыйбадәт кылып алырга нәкъ вакыты,— дип җавап кайтарды беренче койка.

Бачана күз кырые белән икенче койкага карап алды һәм анда чалара башлаган кара сакаллы берәүне күрде. «Әллә поп инде?» — дип уйлап алды ул һәм яңадан соравын кабатлады:

— Вакыт күпме?

— Сәгать ун,— диде сакаллы.

— Ә ничәнче гасыр икәне сезне кызыксындырмыймыни? — дип гаҗәпләнгән булды Булика.

Авырулар, гадәттә, әҗәлләре якынайгач, яисә каты чирдән котылып, терелә башлагач, шаярталар. Ничәнче гасыр икәнлеген Бачана, әлбәттә, хәтерли, әмма аны хәзер башка нәрсә — әлеге савыгып килүченең йөзе кызыксындыра иде. Әмма башы белән Бачананың аяк очына карап ятканлыктан, Буликаның ялтырап торган пеләше генә күренә иде.

Бачана ирексездән елмаеп куйды һәм, күршесенең хәтерен калдырмас өчен:

---

[1] *Мтацминда (грузинча: Изге тау)* — Тбилисидә күренекле җәмагать эшлеклеләрен күмә торган урын.

— Ничәнче гасыр соң хәзер? — дип сорады.

— Алай-а-ай, атакай, чыннан да бу әллә кай тарафлардан кайтып килә бугай,— дип эндәште Булика икенче койкага.— Мин алай ук ерак китмәгән идем шикелле.

— Бит синең йөрәктә арткы стена ишемиясе генә иде, ә моның бит стена түгел, Баграти[1] хәрабәләре!

— Ул чагында инде, хөрмәтлем, сезнең өчен хәзер яңача ел исәбе белән нәкъ беренче гасыр була! — дип ачыклый төште Булика.

Бачана кайтарып сүз дәшмәде. Ул палата белән танышырга кереште.

Ишек. Койка. Койка. Тәбәнәк кенә ике шкаф, алар өстендә — оеган сөт салынган банкалар, дарулы шешәләр, салфетка белән капланган җиләк-җимеш. Ап-ак стеналар. Зур тәрәзә. Сулы графин һәм шиңгән роза чәчәкләре торган уртак өстәл. Беренче койка астында — ак тәрәт чүлмәге, икенчесе астында нәрсә барлыгы Бачанага күренми. Ул үзе — өченче номерлы булып чыкты бугай. Беренче күршесенең пеләшен ул инде яхшы ук үзләштереп өлгерде. Икенче койкада ятучы сакаллының йөзе яннан караганда ярыйсы ук сөйкемле тоелды: киң маңгай, туры борын, чалара башлаган куе сакал... Шулай да ничәнче число икән бүген? Кайсы ай?

Бачананың башында сораулар бер-бер артлы туа торды, тик ул аларның берсенә дә җавап таба алмый иде. Ярар, сораулары чәнчелеп китсен, ичмасам, кайсы ел икәнен беләсе иде бит!

— Ә ничәнче ел хәзер? — дип сорап куйды ул искәрмәстән.

— Йә саташа бу, йә безне ахмакка санап шаярта!— диде Булика.

— Юк, аңа саф һава җитми, шуңа хәтере ялгыша. Үзем белән дә нәкъ шулай булды,— дип җавап кайтарды сакаллы,— ничек тә тәрәзәне ачарга иде бит...

Бүлмә эче кабат баягы алсу томанга күмелә башлады, һәм Бачана яңадан әүвәлге текә баскыч янына килеп чыкты.

Бик ерактан Буликаның:

— Исемегез ничек сезнең, хөрмәтлем? — дигән тавышы ишетелде.

«Исемем — Бачана, фамилиям — Рамишвили!» — дип

[1] *Баграти* — Кутаиси шәһәре янындагы Баграти храмы (X—XI гасырлар).

җавап кайтарырга теләде Бачана, әмма дәшмәде — чөнки Булика аңардан бик-бик еракта иде.

— Аптыратма син аны, йокыга китеп бара бугай ул! — диде сакаллы ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

«Юк ла, мин йокламыйм, мине баскыч буйлап нидер аска таба сөйри! Зинһар, ярдәм итегез, югарыга алып менегезче мине!» — дип кычкырасы килде Бачананың, ләкин бер сүз дә әйтә алмады. Бөтен дөнья алсу томанга уралды, теле инде аңа һич буйсынмый иде. Шулай да күршеләрен бөтенләйгә югалтудан куркып, Бачана баскыч басмасына килеп утырды.

— Йоклап китте! — диде Булика.

Әмма Бачана йокламый, ул барын да ишетеп ята иде.

Буликаның караваты астыннан бер күсе килеп чыкты, борынын күтәреп иснәнеп алды, мыекларын селкетеп куйды.

— Килеп җитте! — дип хәбәр салды икенче номерлы авыру.

— Ялгызымы, әллә ыруы беләнме? — дип сорады Булика.

— Хәзергә үзе генә.

— Күз сал әле: алай-болай безнең язучы үлеп китмәгәнме? Күсеਲәр, гадәттә, мәет исен сизеп җыела торган була,— диде Булика һәм, күсегә карамакчы булып, сак кына башын күтәрде, ләкин берни күрә алмады. Койка шыгырдавы күсене куркытты: ул яшен тизлеге белән оясына атылды. Булика аның койрык очын гына күреп калды.— Китте! — диде ул үкенечле тавыш белән.

— Килер әле,— дип өметләндерде аны икенче номерлы авыру һәм, шкафыннан бер шакмак шикәр алып, идәнгә ыргытты.— Көт тә тор, хәзер үк бөтен гаиләсен җыеп килеп җитәчәк.

— Шулай да күз сал әле: язучы исән микән?

Сакал Бачананың койкасына таба башын борды. Әмма тегесе, агарынып калган кулларын күкрәгенә салып, кымшанмыйча ята иде.

— Одеялы кыймылдый, керфекләре дә дерелди.

— Одеялы селкенә икән — сулый дигән сүз; сулый икән — димәк, йөрәге эшли; керфекләре дерелди икән — димәк, ул уяу; уяу икән — димәк, безне ишетә; ишетә икән — җавап бирергә тиеш; җавап бирми икән — димәк, эшләре хөрти...— дигән нәтиҗә ясады Булика.— Хөрмәтле язучыбыз, сез исәнме?

«Исән, мине кайчан югары күтәрерсез икән дип, бас-

кычта көтеп утырам»,— дип җавап бирәсе килде Бачананың. Кызганычка каршы, бу теләк кенә иде шул... Әчит кешеләрнең теләгән укый белү сәләте Буликада юк иде.

— Тернәкләнеп чыга калса — ходайның барлыгына чыннан да ышаныр идем! — дип куйды Булика сакалга.

— Әнә, чыгып та җитте! — дип сөенде сакал.— Өстәвенә бөтен ыруын ияртнән.

Бу юлы күсе үзенең хәләл җефете һәм ике баласы белән килгән иде. Башта ул тәрәт чүлмәге тирәли әйләнеп чыкты, аннары тәкәллефсез генә шикәр янына килде. Аны оясына сөйрәп мәшәкатьләнмәстән, үз янына гаилә әгъзаларын чакырып алды. Алар чиратлашып шикәр кимерергә тотындылар.

— Безнең урыннан тора алмаганны сизә бит, хәшәрәт! Югыйсә кеше күз алдында шулай әрсезләнергә юлбарысның да кыюлыгы җитмәс иде.— Булика ачу белән башын чайкап куйды. Күсе башын борды һәм, арт тәпиләренә басып, зур кызыксыну белән сөйләүчегә текәлде.

— Безнең нәрсә сөйләшкәнебезгә кадәр төшенә бит, хәерсез! — дип гаҗәпләнде Булика.

Юк, аңламый адәм балалары
Яшерен телен җансыз дигәннәрнең.
Ул дөньяда күптән мәгълүм серне
Бер ачармы акыл ияләре?

— Нәрсә, «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»данмы бу? — дип сорады Булика.

— Юк, «Батыр»дан менә монысы була:

Бар җанварны үзенә тартты Автандилның тавышы,
Хәйран калып тыңладылар олы йөрәк сагышын.

— Һм-м, кара әле, моның тормышы кешеләрнекеннән күп тапкыр шәбрәк ләбаса. Бушлай шикәр ашый, инфаркт, стенокардия, тахикардия дигәннәренең ни икәнен дә белми... Җитмәсә әле без аңа шигырь укып ятабыз!.. Күр син аны, ничек түгәрәкләнгән, дуңгыз баласы бер читтә торсын!

— Күрәсең, яшәү өчен шартлар менә дигән бирелә...

— Ә нәрсә? Мәсьәләгә тарихи-социаль аспекттан чыгып караганда, санитария таләпләрен искә алмый гына эзлекле, объектив фикер йөрткәндә шуны танырга кирәк: күселәр азык-төлек мул булган очракта гына барлыкка киләләр. Шулай булгач, мин монда бер дә гайре табигый нәрсә күрмим... Ахыр чиктә, күсе дә бит аллаһе

тәгалә тарафыннан яратылган... Чума авыруы тарата инде таратуын, анысы һичшиксез начар, әлбәттә...

— Син артык тавышланмый гына һәм мине алласыз дип атамый гына, зинһар, менә шуны төшендереп бир: нәрсәгә дип синең ходай тәгаләңә күсене яратырга кирәк булган, ә? Һич югы инде аңа тиешле инструкциясен дә бирсен иде ул! Йә, шушы якты дөнья йөзенә нәрсәгә дип килгән ул җан иясе? Музыка уйныймы? Юк! Шәраб эчәме? Юк! Башмак төзәтә беләме? Юк! Толма[1] пешерәме? Юк! Нәрсә генә эшли соң ул? Шикәр кимерә, идән сайгагын кимерә, балчык кимерә, тимер кимерә, холера, чума ише җыен шакшыны тарата! Менә нинди җанвар яраткан ул синең аллаң! Тьфү, анасын сатыйм!..— дип төкерде дә Булика стенага таба әйләнеп ятты.

— Томана да кеше син! Бит аллаһе тәгалә ул күсене синең ише миңгерәүләргә үзенең кодрәтен күрсәтер өчен яраткан! Һәм, гомумән дә, телеңне тыеп торсаң шәбрәк булмасмы, тегендә баргач синең җаныңны да ходай тәгалә әнә шул күсегә күчереп куймагае! — дип кисәтте аны сакаллы.

— Минем җанымны күчерер өчен аңа бер күсе дә бик җиткән,— диде Булика суына төшеп.

— Ташла әле шул күсегә бер шикәр, минеке бетте! — диде икенче номерлы авыру.

— Бәлки, аңа «кысла муены» дигән кәнфит бирергәдер? Тик менә кәнфиттән тәне чабырып чыкмас микән? — диде Булика нәфрәтләнеп һәм кабат күршесенә таба борылды.

— Дөнья йөзендәге барча җан иясе дә аллаһе тәгалә тарафыннан яратылган,— дип дәвам итте тегесе вәгазь укыган сыман,— шул сәбәпле алар бер-берсе белән килешеп-ярашып яшәргә тиешле...

Күселәр, шикәр белән эшне төгәлләгәч, Бачана шкафы тирәсендә иснәнергә тотындылар, әмма анда ашарга яраклы нәрсә табылмады,— Бачана әле азык-төлек ягын кайгыртырга өлгермәгән иде — шуннан алар икенче номерлы авыру биләмәсенә күчтеләр. Биредә дә әллә ни яраклы нәрсә күренмәде булса кирәк: күселәр шкаф аягын кимерергә керештеләр.

Шулчак гел көтмәгәндә икенче номерлы авыру:

— Ух, башыгыз беткерләре! — дип, яшелле-зәңгәрле тавыш белән чинап җибәрде дә, бар көченә селтәнеп,

---

[1] *Толма* — Кавказ халкының иттән, кәбестәдән әзерләнгән ашы.

күселәргә башмагын томырды. Булика, куркудан сискәнеп китеп, йөрәгенә ябышты.

— Табигать тәңгәллеген бозасың, атакай! — диде ул мыскыллы елмаеп һәм, андый-мондый хәл килеп чыкмагае дип, тел астына бер төймә нитроглицерин салды.

Бүлмәдәге тавышка фельдшер хатын кереп җитте:

— Нәрсә булды? — дип сорады ул.

— Хөрмәтле Женя,— дип дулкынланып сүзен башлады икенче номерлы авыру.— Йә бу хәшәрәт җан ияләреннән аралагыз безне, йә булмаса тычкан тәбесе куегыз!

— Аңлатыбрак сөйләгезче, ни димәкче буласыз сез?

— Һәрхәлдә, сүз Важа Пшавеланың[1] «Тычкан тәбесе» китабы турында түгел! Коткарыгыз безне бу күселәрдән, башкача түзәрлек чама калмады монда!

— Сез нәрсә, батоно, мин биредә утыз ел эшлим, шул гомер эчендә ник бер тычкан баласы күрим!

— Мин дә бит тычкан баласы димим, сүз күселәр турында бара! — дип ачыклык кертте Булика.

— Анысы турында инде гомумән сүз дә булуы мөмкин түгел!

— Ә мин сезгә әйтәм, биредә күселәр тулып ята! — дип катгый төстә кабатлады икенче номерлы авыру.

— Кайсыгызның башмагы бу?— диде фельдшер хатын сүзне икенчегә борып.

— Минеке ул, хөрмәтле Женя, минем башмак. Шуның белән күсене бәреп үтермәкче идем!

— Ә «җан кыймау» турындагы тәгълиматыгыз, атакай?

— Әлеге дини канун, хөрмәтле Женя, сезнең тәфтишләвегезгә мохтаҗ түгел. Һәм, гомумән, сезнең яшьтәге хатынга кешене күседән аера башларга бик вакыт инде! — дип үпкәсен белдерде икенче номерлы авыру.

— Минем ничә яшьтә булуымны тикшерү сезнең эш түгел! — дип ярсып китте Женя.— Аннары, мин сезгә монда күсе фельдшеры да түгел! Дару кирәк икән — сорагыз, ә тычкан тәбесе һәм стрихнин хакында әнә склад мөдиренә мөрәҗәгать итегез!

— Безнең палатада хәзер язучы ята. Тиздән, мөгаен, аның хәле аруланыр, һәм бөтенесен үз күзе белән күргәч, шәт сезнең турыда да газетага язмый калмас,— дип янады аңа Булика.

Фельдшер хатын Бачана койкасы янына килде һәм,

---

[1] *Важа Пшавела* — грузин әдәбияты классигы.

аның ятагы кырыена утырып, җансыз беләзегеннән тотып карады.

— И-и-и, кая инде хәзер аңа...— дип авыр сулады ул.

— Зинһар, тәрәзәне ачыгыз әле, баярак ул, аңына килеп, һава җитмәвен әйткән иде,— дип исенә төшерде икенче номерлы авыру.

Женя җәһәт кенә койкадан торды да, тәрәзәгә килеп, аны төбенә кадәр ачып җибәрде.

Бүлмәгә сәрби чәчәге исенә туенган сихәтле саф һава бөркелде. Палатага яз исе керде.

Бик тә таныш тавышлы берәү:

— Әйдә тор, кузгал урыныңнан!— дип эндәште шулчак баскыч басмасында утырган Бачанага, һәм Бачана шул чакыру авазы килгән якка таба кузгалып китте. Баскыч аны шау чәчәкле сәрви куаклары белән әйләндереп алынган кечерәк бер аланлыкка алып чыкты. Аланны тутырып, җете кызыл мәкләр чәчәк атып утыра иде. Шул мәкләр арасында, тузган ялын җилпеп, ап-ак колынчак басып тора. Ул, Бачананы үз янына чакырган сыман, түземсезләнеп тоягы белән җиргә кага иде.

— Йә, кил, атлан миңа! — дигән тавыш ишетелде шунда Бачанага, һәм ул колынчак өстенә менеп утырды, куллары белән аның муеныннан кочып, башын муенына салды. Колын томырылып алып китте. Тирә-юньгә чакы-чокы килеп дагасыз тояк тавышлары яңгырады. Менә ул җан-фәрманга чаптырып Бачананы ап-ак бер храм каршына китереп җиткерде һәм эреле-ваклы меңләгән кыңгырау чыңлаткандай, миһаһайлап кешнәп җибәрде. Шул вакыт храм ишекләре шар ачылып, бусагада кулына бала күтәргән Гайса анасы күренде. «Изге аллам» дип уйлады Бачана һәм тезләренә чүкте...

...Аңына килгәч, Бачана үзенең пульсын санап торучы ак халатлы фельдшер хатынны күрде. Шул ук вакытта ул үзенең тамырлары буйлап кан агылуын һәм, каядыр йөрәк турысына җиткәч, аның, ниндидер тоткарлыкка очрап, әкренәеп калуын тойды. Тамырларга сыеша алмагандай, кан үзенә тырыша-тырыша юл яра иде. Аның агышы торган саен көчәя, кызулана барды. Хәзер инде ул акмый, бәлки томырылып йөгерә, ургыла, кайный иде. Бачананың хәтта чигәләре кыса башлады. Ләкин монысы инде башка, бөтенләй икенче төрле сызлау иде. Шунда Бачана үзен ташлап киткән тормышның кабат әйләнеп кайтуын, аның бүлмәгә килеп кереп, янына койкага утыруын, күкрәгенә килеп орыну-

ын аңлап алды. Моны ул башта тойды, аннары ишеткәндәй булды, шуннан соң инде күзләре белән күрде.

— Исәнме! — дип елмайды ул кабат әйләнеп кайткан тормышка.

— Исәнмесез! — дип, үзләре дә сизмәстән, фельдшер хатын белән ике күршесе кабатлап куйдылар. Аларның «исәнмесез» диюләрендә көтмәгәнлекләре дә, шатлану-сөенү дә, гаҗәпләнү дә — барсы да бар иде.

— Исәнмесез! — дип елмайды Бачана аларга.

— Кайтты бит! — дип куйды Булика.

— Кайттым шул! — дип җөпләде Бачана.

— Кайларда булдыгыз инде сез? — дип кызыксынды Булика.

— Вифлеемда булса кирәк! — дип елмайды Бачана.

— Ул әле һаман да шунда бугай! — дип көнелсезләнгәндәй итте Булика.

— Юк, мин чыннан да кайттым инде! — дип тынычландырды аны Бачана һәм фельдшерга мөрәҗәгать итеп: — Күптәннәнме инде мин биредә? — дип сорады.

— Бер көн дә бер төн,— диде ул, Бачананың мендәрен төзәткәләп.

— Рәхмәт...

— Кәефегез ничек?

Бачана беркавым уйланып торды: йөрәге әлегә тигезсез тибә тибүен, әмма баягыча ук хәлсез түгел инде — үзенең йөрәк тибешен хәзер ишетә иде ул. Бачана аяк-кулларын кыймылдатып карады, ләкин тәне-гәүдәсе барлыгы бөтенләй тоелмый иде кебек. Ул үзен иркен, рәхәт бер бушлыкта очкан төсле хис итте. «Гәүдәң авырлыгын тоймау шушыдыр инде»,— дип уйлады ул.

— Кәефегез ничек?

— Нәкъ космонавтныкы кебек! — дип җавап бирде Бачана тәҗрибәле галәм очучысы шикелле нык ышаныч белән.

— Йөрәк бик борчымыймы?

— Бераз авырта авыртуын, ләкин инде теге вакыттагы кебек түгел...

— Әйе, шулайдыр,— дип бүлдерде аны фельдшер хатын,— хәзер мин сезгә гепарин белән пантопон уколы кадармын. Йоклагыз, ял итегез, сөйләшмәгез һәм кыймылдамагыз...

— Бөтенләй кыймылдамаскамы?

— Әйе, бөтенләй!

— Әгәр аз гына кыймылдасам?

Фельдшер хатын бер мәл уйланып торды, аннары әкрен, әмма нык һәм ышанычлы тавыш белән:

— Үләчәксез! — дип җавап бирде.

Бачана авызына җыелган төкереген көч-хәл белән йотып җибәрде. Аннары бик күндәм кыяфәт белән ике укол кадатты да тынып калды (фельдшер хатын укол салган урынга шундук җылы грелка куйды).

— Йомышыгыз чыкса, чакырырсыз,— диде аңа фельдшер.— Ә сез,— дип, башкаларга таба борылды ул,— седуксен эчегез дә — йоклагыз. Башка палаталарда да күзләләр ята, тик берсе дә сезнең кебек дөньяга шаулатып шәрран ярмый!

Шулай дип, фельдшер хатын бүлмәдән чыгып китте.

— Барысын да профессорга сөйләп бирәчәкмен! — дип кычкырып калды Булика аның артыннан, ләкин фельдшер хатын аны ишетмәде.

— Безнең монда, әле сез бу дөньяга әйләнеп кайтканчы, күселәр хакында кичерәк бер бәхәс чыккан иде,— дип аңлатты Бачанага икенче номерлы авыру.

— Нинди күсе?

— Бераздан килеп җитәр әле, күрерсез... Ә хәзер танышырга рөхсәт итегез: Ортачала изге троица чиркәве башлыгы Иорам Канделаки, икенче күршегез — Ваке [1] итекчесе — Автандил, икенче төрле итеп әйткәндә — Булика, Гогилашвили.

— Ә нигә Булика?

— Кечкенә чагымда мин «булка»ны «булика» дип әйтә торган булганмын. Шуңа күрә Булика дигән кушамат такканнар. Теләсәгез, сез дә мине шулай дип йөртә аласыз,— диде Булика.

— Бик шатмын. Ә мин — Бачана Рамишвили, язучы.

— Анысы безгә мәгълүм инде. Ә менә инфаркт нәрсәдән булды сезгә?

— Валлаһи, ул кадәресен әйтә алмыйм! — диде Бачана көрсенеп.

— Бәлки, сез теге нидер...— дип, Булика бик мәгънәле итеп тамак астына чиртеп куйды.— Язучы халкын аңа бик хирыс диләр бит...

— Юк-юк, сез нәрсә! — дип елмайды Бачана.

— Бөтенләймени? — дип гаҗәпләнде Булика.

— Ничек инде «бөтенләй»? — дип, гаҗәпләнде үз чиратында Бачана.

---

[1] *Ортачала, Ваке* — Тбилиси шәһәрендәге районнарның элеккеге исемнәре.

— Шул шул! Югыйсә бик сәер килеп чыга бит: эчмәгәч ничек язсын ди инде кеше! Шулай да ни чамадарак?
— Әйтик... бер, ике, өч...
— Рюмкамы?
— Шешә, әлбәттә!
— Менә монысы ярый! Егет икәнсез!.. Тик хәзер инде сезгә вакытлыча компотка күчәргә туры килер.
— Юк инде, вакытлыча түгел, бөтенләйгә! — диде Иорам-атакай.
— Әйтерең бармы! Алай үзең теләп дөньядан китүең хәерлерәк! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды Булика.
— Әйе, компотка күчәргә... Әгәр син моңарчы компот кына эчкән булсаң, биредә аунап та ятмас идең! — дип вәгазьгә күчте Иорам-ата.
— Ә үзең соң? Син бит әнә шәраб та эчмәгән, ни өчен әле минем янда ятасың? — диде Булика зәһәр елмаеп.
— Әйе, эшләр шуңа таба китте... Компотка таба...— диде Бачана.
— Бер караганда, бәлки алай яхшырактыр да... Менә минем, сезнең кебек, бер таныш язучым бар иде. Мин аның туфлиләрен төзәткәли идем. Ныграк салган чагыма туры килгән саен, ул һаман карга сыман каркылдый иде:

Булик дустым, эчмә шәраб,
Бел, эшләрең булыр харап.

Ә мин аңа ышанмый идем, башка шагыйрьләр кебек моның да акыл ягы чамалыдыр дип уйлый идем... Менә, сала торгач, барып чыктым! Утыз да тулмаган бит әле миңа, инде инвалид булып йөр менә... Ярый, шәраблары кадалып китсен,— дип, көрсенеп куйды Булика,— аның бит әле папирослары һәр төнне, сылу кызлар төсле, төшкә кереп аптырата! Кыскасы, бу инфаркт дигән нәрсәдән соң, дөньядан бөтенләй ваз кичәрдәй булырсың!..
— Инфаркт кичергәннән соң кешенең күңеленә курку төшә, һәммә нәрсәдән аның коты алына башлый. Ә сез куркасызмы?— дип сорады Иорам-ата Бачанадан.
— Куркам, бик куркам! — диде тегесе ихлас күңелдән.
— Юкка куркасыз! — дип әңгәмәгә катнашты Булика.— Хәзергә әле сез наркоз тәэсирендә, тора-бара барысы да үтәчәк... Карагыз әле, сез нәрсәләрдер күргән кебек булмыйсызмы? Күз алдына беркем дә килмиме?

— Әйе, кемнәрнедер күргән кебек булам,— дип җавап бирде Бачана бермәл уйланып торганнан соң.

— Булгалый... Кайвакыт әле төшләнеп сөйләнерсез дә... Бөтен серегезне ачып ташларсыз! Карагыз аны, әгәр сөяркәгез булса, саграк кыланыгыз, хатыныгыз алдында ялгыш аның исемен ычкындыра күрмәгез!

— Рәхмәт, истә тотармын! — диде Бачана елмаеп.

— Дөресен әйткәндә,— дип дәвам итте Булика,— акыллы кешеләрнең сөяркәләре хатыны белән бер үк исемле була. Мәсәлән, менә мин үзем дә сезнең кебек, әйтик, космонавт хәлендә ятканда, гел сөяркәм Светаны искә төшергәнмен, аңа матур-матур иркәләү сүзләре сөйләгәнмен... Шул вакыт караватым янында утырган үз хатыным Света: «Һай, Буликҗан, мине шул хәтле дә яратасыңдыр дип башыма да китерми идем»,— дип үкереп җылый икән. Ә мин, бернигә исем китми, һаман сөяркәм турында такылдыйм икән... Әгәр дә инде хатынкайларның аталары исеме дә туры килсә, ирнең тормышы, гомумән, тоташ бер җәннәт булыр иде!.. Тик шулай да берсендә ялгышлык җибәргәнмен менә. Әнә, Иорамата шаһит...

— Ничек итеп? — Бачана җанланып китте.

— Саташып ятканда баш җитмәслек ахмак сүз ычкындырганмын: имеш, сөяркәмә: «Светаҗан, агачтан өзелеп төшкән беренче җимешнең дуңгыз авызына эләккәнен беләсең бит,— дуңгыз дигәнем, янәсе, үземнең хатын була инде,— әгәр, ходай кушып, шушыннан исәнсау котылып чыга алсам, шул көнне үк синә өйләнәм», дип әйтәм икән. Шулай дип сөйләнгәнемне ишетүгә, хатыным, сезнең караватка башын бәрә-бәрә — ул чагында әле карават буш иде — «Һай, Буликам җаным тәмам акылга җиңеләйгән ләбаса, туебыз булганны да оныткан!» дип, үкереп еларга тотынган. Нәкъ менә шул чакта иң аек акыл белән сөйләгәнемне хатыным белсә иде әгәр!.. Менә шулай...— диде дә Булика, кинәт сүзен өзеп, Бачанага текәлде.

Бачана, күзен йомып, хозурлыкның иң югары ноктасына җиткән бер кыяфәттә, тигез сулап, тыныч кына ята иде...

— И-и-и, бигрәк әкәмәт кеше булып чыкты бу. Әле генә монда иде, шул арада тагын тегендә китеп барган! — диде Булика хәтере калгансымак итеп.

— Борчыма инде син аны, пантопон шулай тәэсир итә... Бераз черем итеп алсын...

Бачана исә, алсу томанны аралап, әүвәлге таныш

текә баскычлар буйлап түбән таба төшеп бара, әмма бу юлы инде ул үзенең һаман саен югарырак, биеккәрәк күтәрелүен ачык тоя иде...

4

— Менә, улым, сиңа направление. Чохатаурига [1] барып, рентгеннан күренеп кайт... Синең бу ялтырап торган күзләрең, алсу яңакларың нигәдер бер дә ошамый миңа!

Бачана, кәгазь битен дүрткә бөкләп, кесәсенә салды.

— Минем кай җирем авыру соң, Евгений абый? — дип сорады ул тыныч кына.

— Температураң күптән шулай югарымы?

— Берәр ай чамасыдыр.

— Тирлисең дәме?

— Көндезләрен учым гына тирли, төнлә менә бөтен тәнем манма су була! — Бачана юеш кулларын чалбарына ышкып алды.

— Йөткертәме?

— Сирәк-мирәк, әмма эт өргән кебек яман итеп,— диде Бачана күңелсез генә шаяртып.

— Кан төкергәнең юктыр бит?

— Узган атнаны бераз күренгән иде, менә моның кадәр генә,— Бачана чәнти бармагының очын күрсәтте.

— Нигә аны шушы гомер әйтми торасың, улым? — Врачның тавышы калтыранып китте.

— Ни булган соң миңа? — диде Бачана хәвефләнеп.

— Рентгенга күренеп кайт, шуннан соң әйтермен.

— Ә ул авыруның исеме ничек?

— Инфильтрат... Аза төшкәне — бронхоаденит дип атала.

— Грузинча ничек була? — дип төпченә бирде Бачана.

Врач җавап кайтармады. Ул өстәле артына кереп утырды да бер кирәксезгә кәгазьләрен актарырга тотынды.

— Ул авырудан берәр дару бардыр бит? — дип янадан сорау бирде Бачана.

— Пенициллин һәм сульфидин,— дип җавап бирде врач, өстәлдән башын күтәрмичә генә.

— Табып буламы аларны?

---

[1] *Чохатаури* — Көнбатыш Грузиядәге район үзәге.

— Була! Ун мең сумга, Тбилисидә! — Врач Бачананың гаҗәпләнүдән шар булып ачылган күзләренә карады.

— Ул хәтле акчаны каян табарга соң?

Врач, анысын менә белмим дигәндәй, җилкәсен сикертеп, кулларын җәеп куйды.

— Тагын нинди дарулары бар аның, Евгений абый?

— Тагынмы? Атланмай, сөт, балык мае, икра, йомырка, шикәр, бал, җылы һава һәм Бахморо[1]! Менә шул даруы!

Бачананың теле аңкавына ябышты... Врач санаган әйберләр теге даруларга караганда ике өлеш кыйбатрак иде. Ул, баскан җирендә кыймылдамыйча, сүзсез озак басып торды, аннары, кесәсеннән направление кәгазен чыгарып, аны пөхтә итеп җәеп тигезләде дә өстәл өстенә куйды һәм шулай ук дәшми генә ишеккә таба юнәлде.

— Кая киттең әле син болай, егет? — дип туктатты аны врач.

— Киттем мин, Евгений абый, үз авыруымны ничек тә үзем җиңәрмен,— диде Бачана төксе генә.

— Ашыкма әле! Аптекага кереп гематоген ал, бал кашыгы белән көнгә өч тапкыр эчәрсең. Файдалы ул...— Врач, кесәсеннән ун сумлык акча чыгарып, Бачанага сузды.— Мә, тот...

Бачана акчаны алды да направление янына өстәлгә куйды.

— Акчаны бабай бирер... Ә сезгә бик зур рәхмәт, Евгений абый! — дип, Бачана ишекне ачты.

— Бабаңа әйт, минем янга сугылсын әле.

— Авырый ул, Евгений абый, йөрүе читен аңа,— дип алдашты Бачана.

— Алайса әйт аңа...— Врачның сүзе шунда төртелеп калды.

— Нәрсә дип әйтим?

— Син аңа әйт...— Врачның тавышы сөрлегеп китте.— Син алай курыкма, яме, балакай! Әле соң түгел! Син нык егет, авыруга бирешә торган түгел!

— Бабайга ни дип әйтим, Евгений абый?

— Нәрсә әйтергә дисеңме?— Врач кинәт чыгырыннан чыккандай булды.— Ул, бичара җан, бүген үк, хәзер үк бар нәрсәсен: йортын, хуҗалыгын, җанын-тәнен сатсын да сиңа пенициллин алсын! Ишетәсеңме? Хәзер үк!

---

[1] *Бахморо* — Грузиядә таулар арасындагы бер курорт.

Врач өстәлгә таба ташланды, направление белән акчаны алды да ерткалап-теткәләп, югары чөйде, аннары, чырайсызланып калган йөзен Бачанага таба борып, кычкырып җибәрде:

— Шушыннан соң да кеше дип, врач дип аталаммы инде мин?!

Бачана, врачның карашын күтәрә алмыйча, бүлмәдән чыгып китте.

— Аграфена апа, миңа ике шешә гематоген бир әле. Якшәмбе көн Чохатаурида шәфталу саткач акчасын китерермен,— диде Бачана аптекада провизор белән икәүдән-икәү калгач.

— Гематоген нәрсәгә ул сиңа? Аны бит чахоткалы кешеләр генә эчә.

Бачананың кинәт тез буыннары йомшап, бөтен тәнен калтырау алды, уч төпләре тирләп чыкты. Моңарчы әле берәүнең дә аңа бу куркыныч авыру турында шулай авыз тутырып әйткәне юк иде.

— Бабайга кирәк... Евгений кушты... Хәлсезлектән файдалы ди...

— Мә, улым, ал, ал... Тик шулай да... Шәфталу дигәнеңә бик үк ышанып җитмим җитүен...

— Нәрсә, бик кыйбатлы дарумыни?

— Шешәсе тугыз сум алтмыш тиен...

— Алайса бер генә шешә бир. Акчасын якшәмбе китерермен.

— Ни булды сиңа, улым? Тәмам төсең киткән ләбаса! — диде Аграфена аның хәленә кереп.

— Юк, берни дә булмады, мин үзем шундый аксыл чырайлы.— Бачана, шешәне алып, аптекадан чыкты һәм, авып китмәс өчен, черек баскыч басмасына килеп утырды.

— Исәнме, Глахуна абый!

— Саумы! Тик танып ук җиткермим үзеңне...— дип, ферма мөдире күзләрен кыскалап алды.

— Бачана мин, Ломкаца Рамишвилиның оныгы.

— Кара әле син аны! Үсеп тә куйгансың, егет, үзең!— дип гаҗәпләнде Глахуна.— Бабаң ни хәлдә яшәп ята?

— Ярыйсы...

— Әйе-е-е... Нинди асыл улларын югалтты бит... Әле дә ничек җаны түзә... Син кайсысыныкы?

— Өлкәненеке.

— Акакий малаемы?

— Әйе.

— Их, әтиең нинди кеше иде бит! Синең яшеңдә берьялгызы коралсыз-нисез аю ауларга йөри иде!.. Йә, шуннан, Ломкацаның ни йомышы төште миңа? Мөгаен, бер дә сәбәпсезгә йөрмисеңдер...

— Глахуна абый, фермага көтүче итеп ал әле мине...

— Яшьрәк шул син, улым, кәҗә-бозаулар артыннан җитә алмассың.

— Ә үзең, минем яшьтә инде әти аюга йөрде, дисең.

— Әтиең бит үгез кебек таза иде, ә син? Катырак өрсәң очып китәргә торасың. Ничә яшь сиңа?

— Унбиш.

— Ә бабаң? Җибәрәме соң ул сине?

— Син риза булсаң, җибәрә!

— Ничек итеп ризалык бирим ди инде мин?! Тауларда сарык көтүнең нәрсә икәнен бабаң үзе миннән яхшырак белә ләбаса!

— Үтенеп сорыйм, Глахуна абый!

— Юк, улым, булмый!

Бачананың иреннәре чалшайды, күзенә яшь килде.

— Үтенечемне кире какмагыз инде, Глахуна абый!

— Нәрсәгә дип шулай өтәләнәсең соң әле син?

— Чахотка миндә, Глахуна абый,— диде Бачана, күз яшьләрен йотып.

— Ни сөйлисең син, тиле! Шулай шаярырга ярыймыни? — диде Глахуна, ачуы чыгып.

— Евгений абый әйтте... Күп итеп май ашасаң, сөт эчсәң, тау һавасы суласаң, авыруыңны җиңәрсең, диде...

— Ай алла гынам! — дип ыңгырашты Глахуна Керкадзе, Бачананы кочагына алып.— Кар-яңгыр астында йөреп тауларда салкын тидерсәң? Үлсәң? Ул чагында, бичара бабаңның күзенә ничек күренермен? Сиңа бит, балакаем, урман-таулар түгел, түшәк-ястык кирәк!

— Үтенечемне кире какмагыз инде, Глахуна абый! — Бачана, Глахунаны кочаклап, елап җибәрде.

— Ярар, кадерлем, ярар! Алам мин сине үз яныма. Кәҗә сөте генә түгел, күгәрчен сөте эчертермен! Күз карасыдай саклап-багармын үзеңне! Ике ай дигәндә мин сине сыңар кул белән өч яшьлек үгезне егып салырлык итеп тазартырмын! Булды, булды, кадерлем, елама! Нәрсә ул безгә авыру? Төкереп тә бирмибез без аңа! Туктыйсыңмы син, юкмы, эттән туган малай!

Бачана инде күптән елавыннан туктаган, тик менә хәзер, сабый бала сыман, Глахуна Керкадзе елый һәм аны гына юатырдай кеше күренми иде...

Егерме өч сыер, ике үгез, егерме җиде кәҗә, өч ат һәм бер иркәк дуңгыз —1943 ел җәендә Қведобани колхозының сөт һәм ит бирергә тиеш булган терлек саны әнә шундый иде. Колхоз фермасы Бахморо тирәсендәге Чхакоури тау битендәге көтүлеккә урнашкан иде. Җәйләрен колхозчылар җәмәгать терлеге белән бергә үз хуҗалыкларындагы мал-туарны да шул көтүлеккә куа. Алар арасында күбесе бозау һәм башмак тана. Чөнки шушындый кытлык, авыр сугыш елларында авыл халкы савым сыерны өч-дүрт айга өеннән чыгарып җибәрә алмый иде.

Йөз егерме хуҗалыктан җыелган шушы барлы-юклы мөлкәтне ике эт һәм өч ир кеше — ферма мөдире Глахуна Керкадзе, Сипито Гудавадзе һәм Иона Орагвелидзе саклый. Бачана дүртенчесе булды, ләкин аны берсе дә көтүче исәбенә кертми иде.

Көтүдәге бердәнбер ата дуңгыз — Глахунаныкы иде. Һәм менә бүген әлеге бичара хайванны, печтерелгән башка кардәшләре кебек үк, ачы язмыш көтә. Бу — ике яшьлек таза-көр нәселле дуңгыз, хәзергә, әлбәттә, бернинди хәвеф-хәтәр сизмичә, чүп-чар өемендә казынып кәефләнә. Аның көчле, кыска танавы җирне трактор сабанының төрәне шикелле ярып бара. Дуңгыз, шулай бар нәрсәдән хәбәрсез булып, үз эше белән кайнашкан арада, Глахуна, лапас астында кадакка элгән йөгән каешына янап, пәкесен үткенләде.

— Бик кызганыч бит, Глахуна абый! Печтермәгез инде! — диде аңа Бачана.

— Бөтен урманны бер итеп, кияү булып ялгызы чабалап йөрмәсен әле! Хәзер монда, тоташтан җиде көн чапсаң да, бер ана дуңгыз очрата алмыйсың! Инде менә печтергәч, тамак ягын кайгыртудан гайре, башкада гаме калмас үзенең. Күр дә тор менә: акылына утырыр, көрәеп китәр,— дип тынычландырды Глахуна абыйсы Бачананы.

— Алайга китсә, безнең Сипито да берьялгызы урманда йөри, аңа карап, бер дә печтермибез бит әле,— дип, дуңгызны яклаган булды Иона Орагвелидзе.

— Әй син, әрәмтамак, әгәр синең үзеңне вакытында печтергән булсалар, хәзер менә синең теге даһи варисың дөньяда яшәп азапланмас иде! Унҗиде яшь бит инде ул күсәккә, ә үзе һаман алманы грушадан аера белми! — дип тезеп китте Сипито, лапас астыннан чыга-чыга.

— Үзең син күсәк! Минем малайның кечкенә чакта агач башыннан егылып төшүен һәммә кеше дә белә! Ә

менә син, үзең? Гомереңдә бер таеп та егылганың юк, шулай да беренче класста тугыз ел утырдың. Әллә оныттыңдамы?

— Глахуна,— диде Сипито, ферма мөдиренә эндәшеп,— әйдә эшкә тотыныйк булмаса, югыйсә бу эттән туган нәрсә дөньяда яшәрлегеңне калдырмас! Теленең нинди икәнен үзең беләсең — сыер тизәге ялаган!

— Глахуна, дөресен генә әйт әле, кайсыбыз хаклы безнең? — дип, Иона ферма мөдирен шаһитлыкка тартмакчы булды.

— Һәр икегезнең телен тартып өзәсе иде сезнең! Дуңгыз белән эшне төгәлләүгә, сезгә тотынам,— диде Глахуна һәм, баш бармагының тырнагына пәкесенең йөзен тидереп алып, дәвам итте:— Җүләр сатып йөрмәгез әйдә, дуңгызны тотыгыз! — диде.

— Ничек итеп җиңәсең аны! Әнә, кара әле, җирне үтәли казып чыгарга да күп сорамас бу! — диде Иона.

— Корсагын кашы әле син аның! — диде Глахуна Бачанага.

Бачана, сарайдан бер уч кукуруз орлыгы алып чыгып, дуңгызга таба атлады:

— Мырык... мырык... мырык!..

Дуңгыз танавын күтәрде һәм, кукурузны күрүгә, колакларын мәзәк кенә селкә-селкә, Бачанага таба йөгерде.

— Менә тиле, үз аягы белән әҗәленә бара бит! — дип, дуңгызны кызгана калды Иона.

Сипито җылы су белән көл әзерләде, Иона бау алып килде, Глахуна пәкесен ябып билбавына кыстырды да ияр асты киезеннән, ефәк җеп сапланган, иләмсез зур итек безе алды һәм җиңнәрен сызганырга тотынды.

— Кашы, кашы! — дип кычкырды ул Бачанага.

Бачана, дуңгызның каршысына чүгәләп, аның корсагын кашырга керешге. Дуңгыз исә, Бачанага илтифат итмичә, шытыр-шытыр кукуруз чәйнәвендә булды. Кукурузны ашап бетергәч, ул кинәт тынып калып күзләрен йомды һәм, корсагын кашыганга рәхәтләнеп, мыркылдарга ук тотынды. Башта ул баскан килеш шулай рәхәтләнеп торды, аннары алгы тәпиләренә тезләнде дә тора-бара бөтенләй авып ук китте һәм тынып калды.

— Әй, мәхлук җан, ике бөртек кукурузга алданып нәрсәдән колак какканыңны белмисең шул син! — дип сөйләнде Иона, дуңгызның арткы тәпиенә элмәк салаcала. Дуңгыз исә кымшанмады да: күзен йомып, мыр-

кылдый-мыркылдый ята бирде. Бачана аның корсагын ике куллап кашый иде.

Иона дуңгызның икенче тәпиен дә бәйләгәч кенә, мәхлук хайван ниндидер шикле эш барлыгын сизенде булса кирәк: талпынып-тыпырчынып куйды, әмма соң иде инде. Сипито дуңгызның өстенә менеп атланган, Иона колакларына ябышкан иде. Бачана да, бу эшнең ни рәвешле дәвам итәчәген көтеп, борчылып шул тирәдә таптанды. Операция ясаласы урынны Глахуна җылы су белән юып маташкан чакта дуңгыз әле тыелыгып кына чинады. Менә Глахуна пәкесен ачты һәм... бичара хайванның үзәк өзгеч әче тавышыннан дөньялар җимерелгәндәй булды.

— Авызыңны томаласаң иде син, ачык ярага бер-бер төрле чир йоктыруың бар! — диде Сипито Глахунага.

— Тик кенә торсаңчы! — диде аңа Глахуна.

Операция дәвам итте. Дуңгызның яман да ачы тавышыннан күк гөмбәзе урталай ярылып, таулар ишелеп төшәр сыман иде.

— Муркыргыры, бигрәк каты чиный! — диде Сипито.

— Күрер идем: аның урынында булса, үзең ничегрәк чинар идең икән?— дип телләште Иона.

— Тагын тотындыңмы? — дип кисәтте аны Сипито.

— Ярый, бетте. Шулай да мин Сталин урынында булсам, сугыш беткәч, Глахунаны чакыртып алып Гитлерга һәм аның шайкасындагы һәркемгә нәкъ менә шушындый операция ясарга кушар идем! — диде Иона.

— Башкалары ничектер, анысын белмим, ә менә Гитлерга операция ясап мәшәкатьләнәсе дә түгел, минемчә... Ни хатыны, ни балалары юк, һәм теләге дә күренми диләр аның...— дип, Сипито империя канцеляриясенең серен фаш итте.

— Дөресен әйткәндә, андыйларның барсы да кеше ашаучылар алар... Ага-Мөхәммәт-ханны[1] хәтерлисезме? Теге... Тифлисне яндырып бетерүче... Ул да бит шундыйрак булган ди... Күкертле мунчаның файдасы тимәсме дип өметләнгән дә бит... Ярдәме тимәгәч, ачуыннан шәһәрне көлгә әйләндерергә боерык биргән,— дип, үз нәүбәтендә Иона да шаһ сараеның серен ачып салды.

— И-и, күкертле су гына ярдәм итсә, безнең Ефросинья әллә кайчан дөньядагы иң бай хатыннарның берсенә әверелгән булыр иде — аның ишегалдында андый

---

[1] *Ага-Мөхәммәт-хан* — Иран шаһы, 1795 елны Грузиягә басып керә, Тбилиси шәһәрен талап, яндырып бетерә.

күкертле су чишмә булып бәреп тора бит! — дип, Глахуна соңгы җөйне төенләп, җепне өзде дә, канга буялган кулының аркасы белән маңгаендагы тирне сөртә-сөртә, аһ-уһ итеп аягына басты.— Җибәрегез дуңгызны!

Сипито белән Иона, бәйләнгән хайванны чишеп, читкә тайпылдылар. Дуңгыз баштарак әлеге тәмуг газапларының бетүенә ышанмады булса кирәк, һаман чиный бирде. Аннары, хәленең бераз җиңеләюен чамалап, аягүрә сикереп торды, баскан җирендә бераз таптангалап алды да кинәт томырылып урманга таба йөгерде.

— Их, кеше түгел, ерткычлар без! Операция алдыннан аңа аракы эчертергә була иде бит!— диде Бачана.

— Кул юарга су сал әле! — диде аңа Глахуна.

— Җаныңа гөнаһ алдың син, Глахуна Керкадзе! — дип ферма мөдиренә шелтәсен белдерде Сипито.— Менә хәзер урманда берәр ана дуңгызга юлыкса, хур була бит бичара малкай! — Сипито, кәефе китеп, дуңгыз йөгергән якка карады.

— Ярар, җитте, шаярдык-көлдек! Савардай сөтләре булса, мал-туарны савыгыз да бире алып кайтыгыз! — дип иптәшләренә әмер бирде Глахуна.— Ә син? Нәрсә дип әле шул дуңгызга карап каттың?— диде ул Бачанага таба борылып.— Бар, Геноларның кәҗәсен сау бүген, сезнеке иртәгә бәрәнләр, мөгаен. Тик кара аны, чүлмәге белән эчеп бетерәсе, тамчысына кадәр! Югыйсә, соңгы вакытта хәйләли башладың! Батыраеп киттең, ахры! Кара аны! Шул чүлмәкне акылсыз башыңа бәреп ватарга да күп сорамам мин!

Бачана, бер сүз дәшмичә, кәҗә саварга китте.

— Аллаһе тәгалә исәнлек-саулык һәм йөз ел гомер бирсен сиңа, Глахуна! — диде Иона, Бачана китеп күздән югалгач.— Тәки баланы кеше иттең бит! Таныйрлык түгел! Чиртсәң — каны чәчрәп чыгарлык.

Глахуна, Ионаның сүзләренә илтифат итмичә, кулына чиләген алды да сыерлар янына китеп барды.

Берәр сәгатьтән Кведобани колхозының ферма терлекләре, мөгрәп һәм бәэлдәп, Чхакоура тавының сөзәк яшел битләве буйлап сибелеште.

Кичен, халык ополчениесеннән автоматлы ике сугышчы ияртеп, фермага колхоз председателе Герваси Пацация күтәрелде.

Салкынча иде. Хуҗалар да, кунаклар да учак тирәли утырыштылар. Учакта, тәмле чәер исе аңкытып, на-

рат утыны чытырдап яна. Казанда кәҗә бәрәне ите кайный. Учак тирәли, тугры хезмәт итүләре өчен тәмле сөяк өмет итеп, өрә-өрә этләр чабалап йөри.

— Тагын нинди яңалыклар бар? — дип сорады Глахуна, дүрткә бөкләнгән газетаны председательгә кайтарып.

— Сине нәрсәләр кызыксындыра соң тагын? — диде Герваси, башын күтәреп һәм тезе өстендә яткан маузерының кобурасын сыпыргалап куйды.

— Авылда калган байлык белән кызыксынуыбыз түгел, булганына өстәп, әллә ни арттыра алмагансыңдыр,— дип сүзгә кушылды Иона.— Фронтта ни хәлләр бар?

— Фронттамы?.. Германиянең эшләре хөрти! — Герваси тагын маузерын сыпыргалады.

— Алып куй әле шуны, билләһи, йә атып җибәрерсең! — дип сукрана-сукрана Сипито читкә тайпылды.— Йә, ничек, нәрсә булган Германиягә?

— Нәрсә булсын?! Смоленск янында хур булды, Мәскәү тирәсендә адәм мәсхәрәсенә калды,— дип, бармагын бөгә-бөгә санап китте Герваси,— тагын кайда рисвай ителде әле? — дип, исенә төшерергә азапланды ул һәм, хәтеренә китерә алмагач, кулын селтәде.— Нәрсәсен сөйләп торырга — шыр җибәрде Германия, менә шул! Румыния, Чехословакия, Италияне дә көч-хәл белән генә тотып тора...

— Сугыш кайчан бетәр икән? Сталин нәрсә ди?

— Тиздән ди, әмма кайчан икәнен тәгаен генә әйткәне юк! — диде Герваси кулларын җәеп.

— Әйтсен иде, аның өчен кыенмыни ул?! — дип гаҗәпләнде Йона.

— Сез нәрсә? Германия белән сугышу бит дуңгыз печү түгел ул сезгә! — дип, Сталинны якламакчы булды Герваси.

— Дуңгыз печү дә алай бик җиңел эш түгел, Герваси туган! — дип, үз профессиясенең абруен саклап калырга ашыкты Глахуна.

Сипито казанны уттан алды һәм гөбердәп кайнап торган шулпадан, бер аягыннан эләктереп, кәҗә бәтиен тартып чыгарды. Әйләнә-тирәгә пешкән ит, суган, лавр яфрагының хуш исе таралды.

— Кая әле, егетләр, теге нәрсәне китерегез әле монда! — дип боерды Герваси.

Батальон сугышчылары, тәгәрәтеп, учак янына турсыкны алып килделәр. Глахуна һәммәсенә балчык касәләр таратып чыкты. Учак тирәсендәгеләр касәләре белән

бер-бер артлы Герваси янына килә һәм, шәраб салдырып, урыннарына кире әйләнеп кайта тордылар. Касәсен тотып Бачана да килде. Герваси сораулы карашын Глахунага төбәде, тегесе рөхсәт биреп баш какты.

Беренче булып касәсеннән Герваси йотып куйды һәм, кәефе килеп:

— Менә, ичмасам, йөзем бу! Тамырыңа бәрәкәт бирсен ходай! — дип куйды.

Гервасиның сүзләре беренче тост итеп кабул ителде.

— Бәрәкәт бирсен! — дип кабатлады бөтенесе, бер сулуда касәләрен бушатып.

Герваси касәләрне икенче кабат тутырды. Бу юлы да ул, Бачанага салганчы, күз карашы белән Глахунадан рөхсәт сорады. Тегесе рөхсәтен бирде.

— Күп булмасмы? — дип сорады Герваси.

— Тагын өч тапкыр,— диде Глахуна.

— Үзең беләсеңдер!— дип ризалашты председатель.

— Бу касәне,— дип сүзен башлады ул,— партиябезнең һәм бөек Сталин җитәкләгән Политбюроның иминлеге өчен күтәрәбез! — Герваси шунда ук касәсен төбенә кадәр бушатты.

— Партия өчен, Сталин өчен! — дип кабатладылар барысы да һәм ит капкалап куйдылар.

— Икенче тост — бөек Сталин җитәкләгән хөкүмәтебезнең исәнлеге өчен!

Бердәм эчеп җибәрделәр.

Берәр минут чамасы үткә, Герваси өченче тостны әйтте.

— Бөек Сталин җитәкләгән Кызыл Армиябез өчен!

Әлеге тостны да бердәм хуплап каршы алдылар, әмма һәркайсы аны үзенчә дәвам итте:

— Армиябезнең иминлеге өчен!

— Кызыл Армиянең җиңүе өчен!

— Солдатларын ходай тәгалә саклый күрсен!

— Безнең кызылармеецләрнең һәр ядрәсе дошманга барып тисен!

— Җир йөзендә тынычлык урнашсын өчен!

Герваси кабат касәсен күтәрде:

— Ә хәзер бөек Сталин җитәкләгән...

— Герваси,—диде Иона аның сүзен бүлдереп.—Мин инде булып беттем ахрысы, тәмам аяктан егылганчы, менә шушы бала өчен дә эчик әле! Сталинга болай да тост һәм рәхмәтне җитәрлек әйтәләр... Эшен дә ул, аллага шөкер, син ярдәм итмәсәң дә бик әйбәт башкара кебек...

— Хата сүз сөйлисең, Иона Орагвелидзе!— диде председатель хәтере калып.— Әгәр без булышлык күрсәтмәсәк...

— Безнең иң зур ярдәмебез — хөкүмәтебезгә таза, нык егетләр үстерү, кадерлем!

— Әйе, сүзең хак синең, хак!— дип ризалашты председатель.— Бачана Рамишвили өчен эчәбез! Тыңлап тор, Бачана!.. Бүгенге көнне һәм менә бу кешене хәтереңнән чыгарма,— Герваси янәшәсендә утырган Глахуна Керкадзеның җилкәсенә кулын салды.— Аның аяк эзләрен ятып үбәргә тиешсең син, балакай! Аның тегендә, сугыш кырында ятып калган улын алмаштырырга тиешсең... Безнең Глахунага беркем һәйкәл дә куймас, орден да такмас... Ә син аның ордены да, һәйкәле дә булырга тиешсең!.. Әйләнә-тирәңә күз сал, уйлан һәм аң бул, балакай, бу дөньяда, күзең күргән һәрбер нәрсә барысы да синеке! Дошман ядрәсеннән хәзер миллионлаган кеше һәлак була һәм аларның берсе дә үзе белән бер нәрсә дә алып китми. Бөтенесе дә сиңа, синең яшьтәшләреңә кала... Һәр йортта күпме яшь түгелә бүген... Күпме ятимнәр, толлар зар елый... Караучысыз калган кырлар ыңгыраша... Хуҗасын җуйган җир елый... Кеше ашаучы вәхшиләр тартып алганның барысын да бүген без яңадан кайтарып алабыз... Әмма таланган-бөлдерелгән илне аякка бастырырга безнең кайбер карт-корының хәленнән килерме? Анысын әйтә алмыйм... Бу эшне син һәм синең иптәшләрең башкарып чыгарга тиеш... Илне аякка сез бастырырга тиеш!.. Сезгә булган зур үтенечебез шул: «элеккеге авыл», «элеккеге шәһәр» дигән сүзләрнең дөньяда барлыгын онытсагыз иде... Сездән соң яшисе буынга сугыш турында бары сез сөйләгәннәрдән чыгып кына белергә калсын иде.— Герваси кулларын күккә таба күтәрде, көмештәй ай нурларына чумган тауларны күздән кичерде.— Туган илебезнең матурлыгын яратыгыз, саклагыз... Бөек, саф, якты сөю белән яратыгыз! Ватан — изге храм кебек ул, аның түре каршында тез чүгеп гыйбадәт кылырга кирәк. Хәер, гыйбадәт кылырга гына түгел, ул иблис токымы мөкатдәс йортыбызны нәҗесләмәсен өчен кулга корал тотып аны сакларга да тиешбез. Өстәп тагын шуны әйтәсем килә: Ватан өчен җаннарын бирергә әзер торучылар арасында һәрвакыт беренчеләрдән булыгыз! Башка минем бернинди гозерем дә, теләгем дә юк! Әйдәгез, эчеп куйыйк! — Герваси мәһабәт бер олылык белән касәсен авызына китерде.

— Герваси Пацация!— дип, шулчак Иона сокланып кычкырып җибәрде.— Әгәр бу сүзләреңне каяндыр укып кына әйтмисең икән, йөрәгеңнән кайнап чыккан икән, сине тагын да колхоз председателе итеп сайламасам, менә шушы кулым корысын!

— Мин монда председательлеккә сайланырга дип килмәдем,— диде Герваси,— әнә бу ике егет тә тикмәгә йөрми.

— Ни булды соң, Герваси? Безне кулга алырга җыенмыйсыздыр бит?— дип көлде Сипито.

— Эш менә нәрсәдә... Теге кабахәтҗан азуның чигенә чыкты бит!

— Кемне әйтәсең син, Герваси? — дип сорады Глахуна.

— Манучар Киквадзены, кем булсын тагын!

— Шулай кыенмыни соң ул явызны тотуы? Армиядән качып кайтканына өч ел булды түгелме инде, шул гомердән бирле тота алмыйсызмы? — дип, Иона сугышчыларга төбәлде.

— Урман кадәр урман эчендә кешене табып кара син! — диде сугышчыларның берсе акланып.

— Җитмәсә ул хәзер иблис кебек хәйләкәр,— дип сүзгә икенчесе кушылды,— көн саен диярлек урынын алыштыра... Әүвәлрәк ул үзенә сыенып урын таба иде, кем куркып, кем элекке танышлык хакына аңа ярдәм күрсәтә иде... Хәзер аннан барысы да ваз кичте, Суреби авылына да юлы киселде. Анда ул ике сабыйны көчләгән, җитмәсә тагын ниндидер яман чир йоктырган аларга... Шул хәлләрдән соң бер кызның анасы акылыннан язган, бичара.

— Ә аталары нәрсә карый?! — дип әйтеп куйды Сипито.

— Аталары фронтта...— диде сугышчыларның берсе кулын җәеп.

— Шул да булдымы җавап?!

— Теге юлы ул Квемо-Чалада бездән көч-хәл белән качып котылды, ә бер атнадан кире шунда әйләнеп кайткан да, аның өстеннән барып чаккан дип шикләнеп, бер гаепсез Бондо Цкипурашвилиның телен кискән. Амаглеби авылыннан Карцивадзеның тол хатыны аны куна кертмәгән өчен, шул төнне үк өенә ут төрткән... Котырган бүре кебек бик хәтәр ул хәзер...

— Ходай шаһит булсын — ул бәндә үләргә тиеш! Әгәр инде шуны дөмектерергә хәлегездән килми икән — безгә бирегез корал, үзебез башкарабыз! — диде Глаху-

на Керкадзе һич көтмәгәндә һәм ни өчендер Бачанага карап алды. Учактан төшкән ялкын шәүләсеннән Глахунаның күзләре ничектер дәһшәтле бер төстә ялтырап китте, һәм Бачананың йөрәге куркудан чемердәп куйды.

— Шушы арада гына Кыквадзе Набеглави фермасын баскан, әллә никадәр сыйр талап алып киткән. Аның бирегә килеп чыгуы да ихтимал, шунлыктан, әгәр хөкүмәткә тапшырасы азык-төлегегез булса, иртәгә үк авылга алып кайтыгыз,— диде Герваси урыныннан кузгала башлап.

— Шул кирәк сезгә! Нәрсәгә дип безнең мылтыкларны алдыгыз соң? — дип мыгырданды Сипито.

— Ярар, телгә салынып торыр вакыт түгел! Егерме баш сыйр белән ике кәҗә бәтиен без алып китик, шуннан артыгын күтәрә алмабыз! — диде Герваси һәм сугышчыларга таба борылып: — Әйдә, җыеныгыз, таң атканчы авылга кайтып җитәргә кирәк,— диде дә аты янына юнәлде.

— И-и, сез шулай бар нәрсәне төяп алып китәсезмени? Манучар Кыквадзега нәрсә калыр соң? — дип төрттереп куйды Иона.

— Телеңә тилчә чыккыры,— диде председатель хәтере калып,— кайчан минем колхоз малына кул озайтканым бар? Балалар бакчасына дип алып кайтам ич, синең оныгыңа дип! Әллә ышанмыйсың?

— Шаяртып кына әйтүем инде! — дип, Иона уңайсызлана калды.— Хәер, синнән алда эшләгән председатель дә шулай дип әйтә торган иде, ә соңыннан әлеге кәҗә бәтиләре аның ишек алдында чабышып йөрер иде. Менә шулай!

— Һм-м, бәлки, миңа да юлбасарлыкка чыгып, синең бу ләгънәт төшкән телеңне тартып өзәргәдер? Их, син!..— Герваси кулын селтәде дә ияр бавын кысыбрак бәйләргә кереште.

— Булды, әзерләдек! — диде Глахуна аның янына килеп.— Бүген атларны көтүлектән алып кайтабыз да калган азык-төлекне авылга иртәгә төшерербез.

— Бик әйбәт! Тик, карагыз аны, саграк булыгыз! Ярый, исәнлектә! — дип, Герваси атына менеп атланды.

— Герваси! — дип туктатты аны Глахуна.

— Нәрсә бар?

— Маузерыңны калдыр әле безгә.

— Коралсыз нишләрмен соң мин?

— Сезгә әнә шул ике автомат җитеп торыр. Маузерыңны якшәмбе көн кире кайтарырмын.

Герваси икеләнә калды.

— Нәрсәсен уйлап торасың инде аның? Йә, әйдә, тизрәк хәл ит!

Герваси, теләр-теләмәс кенә иңбашыннан каешын салып, маузерын Глахунага сузды.

— Кара аны, бүләк итеп бирүем түгел! Кайтарырсың!

— Кайтарырмын! Ләкин аңарчы син аның атканын ишетерсең! — дип, Глахуна Гервасиның кулыннан маузерны алып, Бачанага тоттырды: — Мә, куржынга салып куй.

Бачана маузерны лапас баганасындагы кадакта эленеп торган куржынның буш бүлеменә салып куйды, Герваси белән сугышчылар исә атларын бордылар да тау бите буйлап түбән таба чаптырып төшеп киттеләр.

Бераздан атлылар томан эчендә күмелеп күздән югалдылар. Алар артыннан әле берәр минут чамасы ат тояклары дөпелдәгәне ишетелеп торды, аннары ул тавышлар да тынды. Чхакоура тавы битләвендә басып калган кешеләрнең уйлары һәм борчу-мәшәкатьләре генә, атта җилдереп баручылар артыннан ияреп, үзәнлеккә таба омтылды.

— Ә хәзер, барыгыз, үзебезнең атларны алып кайтыгыз,— диде Глахуна көтүчеләргә,— иртәнге якта алар әнә тегендә, Зоти ягында утлап йөриләр иде,— диде ул кулы белән ишарәләп.— Ике сәгать эчендә, бәлки, әйләнеп кайта алырсыз әле. Егетне дә үзегез белән ияртегез... Чыралык алырга онытмагыз.

Сипито, җилкәсенә бау салып, биленә балтасын кыстырды да чырага ут элдерде. Глахуна лапаска таба атлады.

— Бераз сабыр итсәк тә ярар иде, нәрсәгә шулай ашыгыргадыр? — дип калды Сипито аның артыннан.— Сары таңнан кузгалыр идек... Мондый караңгы төндә кая бармак кирәк?

— Кушканны тыңлагыз, җыелыш җыеп торыр вакыт түгел! — дип кырт кисте Глахуна.

— Ичмасам, баланы жәлләр идең! — дип кызгандырмакчы булды Сипито.

— Берни дә булмас балага! Өйрәнә торсын!

Сипито белән Иона тау сукмагыннан сүзсез генә югарыга таба юл тоттылар. Бачана лерт-лерт атлап алар артыннан иярде.

Шул чакны ферма ягыннан кызганыч итеп мәэлдәгән

тавыш килде — Бачаналарның кәҗәләре бәрәнли башлаган иде...

Иртә таңда фермага әйләнеп кайткан көтүчеләр шаккаттылар: башлары канга буялган ике эт тә сүнгән учак янында аунап ята, абзарда савылмаган ач мал-туар акырыша, Глахуна исә бөтенләй күзгә-башка чалынмый иде. Көтүчеләр дөнья бетереп аны эзләргә тотындылар, әмма ферма мөдире суга төшкәндәй юкка чыккан иде. Шулчак Бачананың әүвәлгечә уч төпләре тирләп юпьюеш булды. Сипито Гудавадзе нидер әйтергә талпынган иде, әмма адәм рәтле сүз әйтә алмыйча, телсез кеше сыман нәрсәдер мөгрәде дә лап итеп җиргә утырды.

— Манучар Кикვадзе эше бу!— дип сөрәнләп кычкырды Иона Орагвелидзе, иярләнмәгән атка сикереп менеп.

Сипито көч-хәл белән телен әйләндереп:

— Кая барасың? — дип сорады аннан.

— Эзенә төшәргә кирәк! — диде Иона һәм атын чаптырып китеп тә барды.

Бачана лапас баганасында эленеп торган куржынга ташланды, капшап карады: маузер үз урынында иде. Шуннан ул Сипито янына килеп утырды, салкын учын аның тезенә салды.

— Йөрмә син, егет! — диде аңа Сипито тоныҡ тавыш белән һәм маңгаена бәреп чыккан тирне сөртеп куйды.

Бачана Сипитоның тезе дерелдәгәнне тойды һәм ул үзенә караганда да аның ныграк курыкканын аңлады.

— Син ни... Курыкма син, Сипито абый,— диде ул.

Сипито газапланып елмайган сыман итте, калтыранган аягын сузып җибәрде.

— Ничек курыкмыйсың ди инде, улым! — диде ул һәм шунда кинәт елап җибәрде.

Глахуна, сыйр белән шыплап тутырган кәрзинне аркасына асып, чайкала-чайкала алдан атлый. Аның артыннан, мылтыгын төбәгән килеш, Манучар Кикვадзе килә.

— Җәһәтрәк атла, Глахуна, җәһәтрәк! Ике сөйләшеп тормам мин! — дип, Манучар Глахунаның аркасына китереп төртте.

Глахуна гарьлегеннән иренен тешләде.

Аның ачуы эченә сыймый иде. Ничек итеп бу шакшы җан шулай сиздерми, капылт килеп чыга алды соң әле? Ничек итеп ул Глахунаның карап торган ике этен үте-

реп, ничек итеп аны үзе белән барырга, җитмәсә әле тагын сыртына сыйр төягән кәрзинне күтәртеп барырга мәҗбүр итә алды?

Әйе, кан күргәч, этләрнең ярасыннан аккан канны күргәч каушап калды бугай Глахуна! Үз гомерендә ул кан коелганны байтак күрде, әмма монысы — пуля тиеп акканы — бөтенләй башка, күрәсең!.. Адәм мәсхәрәсенә калдың лабаса, Глахуна! Ул маузерны ни пычагыма дип алып калдың алай булгач? Курҗынга салып куяр өченме? Нинди оят һәм хурлык! Нигә дип коралына ташланмады соң ул? Баш очында әнә шушы җан кыючы басып торды шул! Аннары, ничек итеп бу юлбасардан алдарак барып өлгерәсең? Тәмам адәм хурлыгына калдың, Глахуна!

Күз яшеннән, ачу-гарьлегеннән аның тыны кысылды. «Шартлап ярылсын иде шушында йөрәгем!» — дип ялварды ул. Әмма йөрәге шартлап ярылмады... Алай гына түгел — киресенчә, Глахуна тагын да кызурак атлый төште. Хурлык, адәм мәсхәрәсе!..

Алда, юл өстендә, су җыелып тора иде. Тулган ай, әлеге күлләвектә чагылып, каяндыр икенче яктан, җирдәге тишектән яктыртып тора кебек иде. Менә хәзер Глахуна җирдәге шул тишеккә килеп басар да, убылып, аска төшеп китәр. Әмма күлләвек төбендә бернинди дә тишек юк иде — Глахуна шып итеп суга килеп утырды.

— Тор әйдә, хөрәсән! — дип кычкырды аңа Манучар.

Глахуна аягына торып басты да Манучарга текәлде.

— Йә, нәрсә, Глахуна Керкадзе, камыт бавы кысамы әллә? — дип ыржайды Манучар.— Шулайдыр шул! Ә сезнең ул теләнче председателегез белән асларына җибәрергә торган батыр солдатларның ни хаҗәтләре калган? Мине эләктерергә йөриләрме? Соң, шунда идем бит мин! Әйе, якын гына идем, һәр өчесен чыпчык урынына мушкага алган идем. Ни өчен соң алар урманга аяк та атламадылар, ә? Гайрәтләре җитмәдеме? Шул шул менә! Үз автоматлары белән үзләрен дөмектерәсемне белеп торалар бит ул хәсрәт батырлар!— Манучар карлыккан тавыш белән буыла-буыла көләргә тотынды.

— Көлүен көләсең, Манучар Киквадзе, ләкин көннәрең барыбер санаулы бит!— дип сүз башлады Глахуна.

— Бу турыда сугыш беткәч сөйләшербез! Ә хәзер, әйдә, кәрзинеңне күтәр дә атлавыңны бел! Ләмдә быкырдап ятарга соңыннан да җитешерсең әле, больше-

виклар бушлай путевка биреп Цхалтубога [1] җибәрерләр үзеңне! Совет властена күрсәткән хезмәтләрең өчен!., Атла әйдә!..

— Сугыш беткәч, кабахәтҗан,— әгәр аңарчы башыңа җитмәсәләр,— мин сине Чохатауридагы иң биек чинарга үз кулым белән асачакмын. Асармын да, черек үләксәңне тураклап, учлап-учлап тоз сибәрмен! Тьфү! — дип, Глахуна Манучарның йөзенә төкерде.

Кикадзе өнсез калды. Аннары кинәт, бар көченә селтәнеп, Глахунаны бәреп екты.

Глахуна суга барып төште. Аягына торып баскач, битендәге канны кулы белән сөртеп алды да тонык бер тавыш белән:

— Үтерсәң — үтер, кабахәт, әмма синең белән бер адым да атламыйм,— диде һәм кире утырды.

— Юкны сөйләмә, Глахуна! Сыйрны урынына илтеп җиткермичә үлем турында уйлама да!

— Кем белән сугышасың син, адәм актыгы? Аңлат әле миңа шуны!

— Сезнең белән, хөрмәтле Глахуна, большевиклар белән! Егерме ике ел инде минем әтинең җирен таптыйсыз... Җитәр! Инде хәзер безнең чират!

— «Без» дигәнең кем инде ул?

— Мин һәм Германия!

— Германияң кайда соң?

— Килер ул, Глахуна, килер! Шул чагында инде син мине асасы чинарга җыеныгызны асып бетерәчәкбез! Иң алдан, кулына кызыл әләмен тотып, сезнең райком секретарегыз атлар! Ә хәзер тор әйдә!

— Тәнемдә җаным бар чакта урынымнан кузгалмаячакмын, үлгәч кая теләсәң, шунда алып барырсың! Моңарчы сиңа ияреп килгәнем өчен дә гарьләнеп үләрлек!

Киквадзе шунда тагын бер корбанының каны коеласын аңлап алды.

— Алайса, читкә борыл да, әгәр белсәң, догаларыңны укы... Ни дисәң дә, алла безне бер балчыктан яраткан бит...

Глахуна тезенә таянды да кулларын күккә таба сузды:

— И кодрәтле тәңрем! Бүген мин сиңа үз кулым белән шушы хәшәрәтне юк итәргә сүз биргән идем... Теләгем кабул булмады, инде менә үзем аның кулыннан

---

[1] *Цхалтубо* — Грузиядәге курорт.

үтәргә тиешмен... Мондый гаделсезлеккә юл куйма, ходаем! Миңа үзең җан биргәнсең, үзең үк алсаңчы аны! Әгәр син бар булсаң, тавышымны ишетсәң, ал минем җанымны! Инде мин дә, менә бу хайвани зат та бер балчыктан яратылганбыз икән, дөнья йөзендә яшәүнең ни мәгънәсе бар?..

...Чхакоури урманында кайтаваз булып рәттән өч тапкыр мылтык тавышы яңгырады. Глахуна әле бәярак кына җирнең теге ягыннан яктырып ай карап торган күлләвек эченә йөзтүбән капланды. Шунда ул, җирнең куены ачылып, аны үз кочагына алуын, аннары кабат ябылып, искиткеч зур учы белән иркәләп кенә аның күз кабакларыннан сыйпавын, күк йөзенең әкренләп кара чаршау белән томалана баруын гаҗәп ачык итеп тойды...

Сипито Гудавадзе, Иона Орагвелидзе, Герваси Пацация һәм халык ополчениесеннән ике сугышчы Глахунаның гәүдәсен фермага алып кайтканда таң беленеп килә иде инде. Бер сүз эндәшмичә, бер генә яшь бөртеге дә күрсәтмичә, биш ир-егет кояш чыгуын көтәләр иде.

Иртәнге эңгер таралып көн тәмам яктырып җиткәч, Иона кинәт Бачананың фермада юклыгын сизеп алды.

— Шул гына җитмәгән иде! — дип ачынып кычкырып җибәрде Сипито һәм куллары белән тезенә шапылдатып куйды.— Бачана! — дип эндәшеп карады.

— Бачана! — дип кабатлады Иона.

Әйләнә-тирәгә:

— Бачана-а-а-а!.. Бачана-а-а-а! — дигән борчулышомлы тавыш яңгырады.

Кайтаваз бер таудан икенче тауга ташланды, аннары тарлавыкка омтылды, барча кыяларны, ерымнарны урап узды, урманны айкап чыкты һәм, малайны таба алмыйча, кайгы-хәсрәт кичерүче ир-егетләр янына әйләнеп кайтты.

Кояшның беренче нурлары уянуга, урман ешлыгыннан сукмакка, җилкәсенә курҗынын асып, бер малай килеп чыкты. Чишмә янына җиткәч, ул утырып тишек чүәкләрен салды, кулында әйләндергәләп, аларны караштырды да читкә ташлады һәм кабарган аякларын салкын чишмә суына тыкты. Аннары малай бит-кулларын юды һәм, баш астына курҗынын салып, чыклы үлән өстенә сузылып ятты да тирән итеп бер тын алды. Би-

ектә-биектә, зәңгәр күк йөзендә салмак кына тирбәлеп карчыга әйләнә иде.

— Их, минем дә канатларым булса! — дип уйлады малай.— Югарыдан бөтен нәрсә уч төбендәге кебек күренәдер...

Малай күзен йомды, һәм берни уйламыйча, байтак шулай хәрәкәтсез ятты.

Шул чакны кинәт тау битеннән сукмакка шыбырдап таш коела башлады. Малай җәһәт кенә сикереп торып аягына басты, як-ягына каранды. Сукмак буенда, кулына мылтык тотып, битен сакал-мыек баскан, аскы ияге алгарак чыгып торган, какча гәүдәле бер ир кеше басып тора иде. Малайның йөрәге жу итеп китте.

— Кем син? — дип сорады ир кеше.

Малай эндәшмәде.

— Син нәрсә, телсезме әллә?

— Чхакоуридан мин! — диде малай көч-хәл белән телен әйләндереп.

— Кая барасың?

— Зотига.

— Кем янына барасың анда?

— Кардәшләребезгә.

Ир кеше бер мәлгә уйлана калды. Аннары, сынаулы карашын малайга текәп:

— Сезнең каршыда анда Кведобани фермасы бит. Син шул турыдан үтмәдеңме? — дип сорады.

— Юк, ферма бездән ерак ул. Мин урман аша, ферманы читләтеп үттем, алай якынрак..— дип, малай кипшенгән иреннәрен ялап куйды.— Ә сез кем буласыз, абый?

— Урман каравылчысы мин, фермага барышым, көтүчеләргә йомышым бар иде... Куржыныңда нәрсә ул синең?

Малай коелып төште: анданиләр барын белми иде ул. Малай, куржынына үрелеп, аның алгы бүлемтегенә кулын тыкты һәм, кәбестә күчәне белән бөкеләп куелган бер шешә чыгарып, үлән өстенә утыртты.

— Нәрсә ул? — дип сорады әлеге ир.

— Аракы.

— Авызыңнан сөтең кипмәгән нәрсә, әллә инде аракы да эчәсеңме?

— Бераз булгалый!— дип елмайды малай һәм куржыныннан абага яфрагына төргән бер түтәрәм сыйр, ярты сынык кукуруз көлчәсе, аннары, ниһаять, пешкән кәҗә ите чыгарды.

— Әһә, капкалап алырга да бар икән!— диде ир кеше һәм сөзәклек буйлап түбән төшә башлады.

— Рәхим итегез! — диде аңа малай һәм үзе куржыны өстенә утырды.

— Димәк, син фермада булмадың? — Ир кеше малай янына килеп утырды, мылтыгын тез өстенә куйды. Малай, «булмадым» дигәнне аңлатып, башын чайкады һәм, калтырануын сиздермәс өчен, кулларын астына яшерде. Ир кеше сүзсез генә ашарга кереште. Тамагы туя башлагач, ул малайга:

— Ә син нәрсә көтеп утырасың? Бер ялгызым ашап утырмам бит инде,— дип эндәште.

Ир кеше, кулына шешәне алып, болгатып куйды:

— Бик зәһәр, ахрысы!

— Әйе, яман да зәһәр! — дип җавап бирде малай.

Ир кеше, учы белән шешә авызын сөртеп, аны авызына аударды һәм ютәлләргә тотынды.

— Вәт шайтан! Аракы түгел, ут бу! — дип куйды ул, авыз-борыны белән сул беләгенә төртелеп.

«И алла, көч-гайрәт бирсәңче миңа хәзер, аннары үтерсәң дә ризамын!» — дип уйлады малай күңеленнән һәм кулын куржынына сузды. Аннары җәһәт кенә аягына торып басты.

Ир кеше, сулышын буган аракы әчесе басылгач, малайга күтәрелеп карады һәм имәнеп китте: малай, кулына маузер тотып, аңа төбәп тора иде.

— Торып бас, Манучар Ҡиквадзе!— диде малай, ирнең йөзеннән күзен алмыйча.

Ҡиквадзе урыныннан кузгалмакчы булып талпынып куйды, тик аягына баса алмады.

— Тор, адәм актыгы! — дип кабатлады малай.

— Ҡем син, егет, ни кирәк сиңа миннән? — диде Манучар исен җыеп.

— Глахуна Ҡеркадзе мин!

Манучар коелып төште.

— Глахуна Ҡеркадзе мин һәм син минем кулдан үтәчәксең!

Малайның кулындагы авыр маузер бөрөзлексез сикергәли иде, шуннан ул коралга ике куллап ябышты.

Манучар җиргә тезләнде дә, су коенып чыккан кеше сыман, кинәт шабыр тиргә баткан башын болгарга кереште:

— Тилермә, егет!.. Синең яшеңдә кеше үтерергә ярамый...— Манучарның тавышы калтыранып китте.— Ата

курмә!.. Кеше үтерүче дигән исем күтәреп, ни йөзең белән дөньяда яшәрсең, ничек җирдә йөрерсең?

— Ә син үзең? Ничек син дөньяда яши, сулый аласың соң?

— Яшим, сулыйм дип әйтә аламмыни мин?

— Яшисе көнең бетте синең Манучар!

— Исемеңне әйт, ичмасам, һәм ни өчен мине үтерергә җыенганыңны әйт,— дип инәлде Манучар иреннәрен тешләп.

— Әйттем бит инде: Глахуна Керкадзе!

Манучар әле һаман иреннәрен кыймыл-кыймыл китереп нидер сөйләнә, тик малай аны ишетми иде инде. Аның колаклары шаулый, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгып китәрдәй булып тибә, чигәләре коточкыч зур тимер чүкечләр белән бәргәндәй дөпелди иде. Колаклары томаланган малай үзен сукырая да башлаган кебек тойды, чөнки аңа таба шуыша башлаган Манучарның йөзе әле икегә, әле өчкә әйләнде, аннары бөтенләй эреп югалган кебек булды. Шул чакта малай курокка басты.

Ул мылтык тавышын да ишетмәде, ничә пуля атылганын да санамады. Көмеш суы йөгертелгән маузер сабына чытырдатып ябышкан кулларының дер-дер калтырануын, бармакларының тартышуын гына тойды. Бераздан, маузер дерелдәүдән туктагач, малай кинәт бердән хәлсезләнеп китте, куллары үзеннән-үзе язылды һәм маузер «дыңк» итеп Манучар Киквадзеның имгәнеп беткән башы янына килеп төште.

Малай, мәеттән читкә борылып, җиргә чүкте һәм йөзе белән тезләренә капланды да урманда адашып юлдан язган бүре баласы кебек улап җибәрде.

Төн уртасында Ломкаца Рамишвили шашынып ишек каккан тавышка уянып китте. Ул, торып, сукыр лампага ут алды да ишек катына килде, каты гына итеп:

— Кем бар анда?! — дип сорады.

— Мин бу, Бачана! — дип җавап бирде тыштагы кеше.

— Бачана түгел син! — Ломкаца оныгының тавышын танымады. Йөрәген кинәт нииндидер шом басты.

— Мин бу, бабай, мин, ач ишекне!

Ломкаца, бикне этеп, ишекне ачып җибәрде — каршысында, башын игән килеш, өс-башы таланып, аяклары канап беткән Бачана басып тора иде.

— Кер әйдә!

Бачана урыныннан кымшанмады. Шуннан Ломкаца, малайның иңеннән тотып, бүлмәгә алып керде. Лампасын өстәл өстенә куеп урындыкка утырды.

— Ни булды? — дип сорады ул калтыранган тавыш белән.

— Кеше үтердем мин! — диде Бачана. Аның ияге дерелдәп китте. Ломкацаның кинәт йөзе чалшайды, кулы белән ул йөрәген тотты. Икесе дә бик озак сүзсез калдылар. Ниһаять, Ломкаца исенә килде һәм көрмәкләнгән телен көчкә әйләндереп:

— Нәрсәгә дип мин сина биш ел буе инҗил китабын укыдым соң? — диде.

Бачана дәшмәде, тирләгән уч төпләрен чалбар балагына сөртә-сөртә, башын игән килеш басып тора бирде.

— Кемне үтердең? — дип тынлыкны бозды Ломкаца һәм, җавап көтеп, тынсыз калды.

— Глахуна Керкадзены үтергән кешенең башына җиттем мин, бабай!

Гаҗәпләнүдән бабасының күзләре түгәрәкләнде. Ул аягына торып басмакчы булды, тик тезләре аны тыңламады.

— Син... Манучар Киквадзены үтердеңме? — дип кабатлап сорады карт пышылдап кына.

— Әйе, Манучарны!

Ломкаца уһылдый-уһылдый көч-хәл белән урыныннан кутәрелде, ишек катына барып, аны әйбәтләп ябып куйды һәм, кабат оныгы янына килеп, малайның башын күкрәгенә кысты.

— Бу турыда кем дә булса беләме? — дип пышылдады ул.

Оныгы башын чайкады.

— Минем ике аллам бар иде,— диде карт басынкы тавыш белән,— син һәм Глахуна. Шуларның берсе Манучар кулыннан һәлак булды...— Бачана үзенең кайнар кулы белән бабасының сөялле кулына орынды. Бабасының кулы боз кебек салкын иде.

— Балам, зиһенеңне җыеп әйбәтләбрәк уйла әле... Башка берәү кылган эшне үз өстеңә алмыйсыңмы... Начар нәрсә ул кан кою...— диде Ломкаца уйланып һәм шул вакыт оныгының ут кебек кайнар кулыннан үзенең тузган, картайган кан тамырларына кайнап-ташып торган кайнар дулкын агыла башлап, әүвәл күкрәгенә, аннары чигәләренә барып җиткәнен тойды. Ломкаца карт озак, бик озак итеп оныгының күзләренә текәлеп карап торды һәм каршысында утырган Бачананың инде унбиш

нішьлек авыру бала түгел икәнлеген аңлады. Карт, оныгының утлы күмердәй янып торган карашын күтәрә алмыйча, читкә борылды. Танымаслык булып үзгәргән малайның очкынланып янган күзләре аннан нидер көтәиде. Шулчак карт әлеге сорауга үзенең ничек җавап бирүеннән оныгының бөтен киләчәк тормышы бәйле булуын аңлады.— Дөрес эшләгәнсең, улым! Синең урыныңда булсам, мин дә нәкъ шулай итәр идем! — диде һәм оныгын күкрәгенә кысты. Бачананың кинәт буыннары таралып-йомшап китте һәм ул, бабасының кочагыннан шуып төшеп, идәнгә утырды.— И кодрәтле аллам, нишләп соң син үчеңне шушы бала кулы белән алдың?! — диде Ломкаца авыр ыңгырашып һәм оныгы янына идәнгә чүкте.

Таң алдыннан, дулкынланудан тәмам иләсләнгән Сипито Гудавадзе орыла-бәрелә Ломкаცаның өенә атылып кергәндә, карт белән малай әле һаман идәндә елашып утыралар. Бачана үкереп елый, ә Ломкаца — тавыш-тынсыз гына сыктый иде...

5

Дәвалаучы врач белән фельдшер хатынны ияртеп, палатага профессор Антелава килеп керде. Бачана, күзен йомган килеш, йөрәгенең тибешенә колак салып ята иде. Бүген аның кәефе шәп, чөнки йөрәге көчле тибә, хәзер ул бөтен гәүдә буйлап бертуктамый кан тарата. Бачана арган-талган йөрәгенең көннән-көн ныгый, зиһененең торган саен яхшыра баруын сизә иде. Менә ул профессорның кергәнен ишетте, әмма якты дөньяга әйләнеп кайту шатлыгыннан бүленергә теләмичә, йоклаганга салышты.

— Исәнмесез! — дип сәлам бирде профессор.

— Хөрмәтле профессорга олы ихтирамыбызны белдерәбез! — дип, урыныннан күтәрелә төште Булика.

— Сәламәтмесез!— дип җавап кайтарды Иорам-атакай.

— Йә, хәлләр ничек? — дип бөтенесенә берьюлы мөрәҗәгать итте профессор, авырулар тарихы теркәлгән кәгазьләрне игътибар белән күздән кичерә-кичерә.— Озакламый сезне реабилитация бүлегенә күчерергә мөмкин булыр,— диде ул аннары канәгать бер төс белән.

— Минем үземә амнистия ныграк ошый төшә! Кәефем менә дигән, өченче көн инде йомышымны үтәргә дә үз аягым белән йөрим, сез каршы килмәсәгез, бүген үк

өемә кайтып китәр идем!— диде Булика һәм, үзенең тәмам тазарып җитүен күрсәтергә теләгәндәй, одеял астыннан шәрә аякларын чыгарды.

— Мин бит кисәткән идем сезне! — диде профессор дәвалаучы врачка таба борылып.

— Караватка бәйләп куя алмыйм ич мин аны! — дип, кулларын җәеп җибәрде тегесе.

— Нәкъ менә бәйләп куярга кирәк иде! Сезгә урыныгыздан торырга ярамый, аңлыйсызмы шуны? Әллә соң тәрәт чүлмәге ошамыймы? — дип сүзне шаяртуга борды профессор һәм, җиңелчә генә төртеп, Буликаны урынына яткырды.

— Нишләп ошамасын, профессор! Шушындый мөхтәрәм кешеләрне бимазаларга яхшысынмыйм...— диде Булика авызын ерып.

— Анысына гына түзәрсез! — дип тынычландырды аны профессор.

— Аннары, минем аркада Ваке халкының яртысы яланаяк йөридер дип намусым талана.

— Ә сез Ваке халкының барсы да яланаяк йөрсен дип тырышасызмы?

— Һмм... Гафу итегез, хөрмәтле профессор, сүзем бетте!— Профессорның әйткәне, ниһаять, Буликаның аңына барып җитте булса кирәк, ул, Ваке халкының чыннан да үзенең савыкканын көтеп торуына ышангандай, ипле-салмак хәрәкәтләр белән урынына менеп ятты.

— Бүген католикос шылтыратып сезнең хәлегезне белеште. Нәрсә дип әйтергә аңа Иорам-атакай?— диде профессор, Ортачала изге троица чиркәвенең башлыгына мөрәҗәгать итеп.

Католикосның шулкадәр игътибар күрсәтүе руханиның күңелен йомшартып җибәрде булса кирәк, аның күзләрен яшь пәрдәсе элпәләп алды:

— Олуг затыбыз католикосның хәер-догасында торганга күрә генә аллаһе тәгалә минем гөнаһлы җанымны үзенә алырга кирәк тапмый, аңа да нәкъ шулай дип тапшырыгыз,— диде ул.

— Алайса, безнең бернинди катнашыбыз да юк инде? — дип кәефе киткәнгә салышты профессор.

— Сезгә, врачларга, тәмуг капкалары ышанып тапшырылган, ә католикос оҗмах капкаларын саклый,— дип акланды Иорам һәм төртенеп куйды.

— Юк, атакай, теге дөньяга алып бара торган юл шул бер үк уртак капкага илтә инде, ул капканың төбендә без, врачлар, басып торабыз. Тәмуг белән оҗмах

тege дөньяның бүлекләре генә ул. Кемне кайсы бүлеккә озату — анысы менә ходай кулында. Безгә исә әнә шул капканы кешеләргә вакытыннан элек ачмаска кушылган. Менә шулай!

Иорам дәшмәде, уңайсызланып тамагын гына кыргалап алды.

— Һаман йоклыймы? — дип сорады профессор, Бачананың пульсын капшап.

— Йоклый, егерме дүрт сәгать буе йоклый! — дип җавап бирде врач.

— Бик яхшы! — Профессор Бачананың баш очында эленеп торган авыру тарихын кулына алды.— РОЭ түбәнәя бара, холестерин да кими төшкән, анысы әйбәт!— диде ул канәгатьләнеп.— О, экстрасистолалар дәвам итәмени әле? Нинди чаралар күрдегез?

— Эральдин бирдек. Иң файдалысы шул...

— Һаман сызланамы?

— Алай бик зыянлы түгел.

— Еш кабатланамы?

— Уяу чакта ярты сәгать саен диярлек.

— Пантопон бирүне дәвам итегез!

Профессор иплап кенә Бачананың одеялын кайтарды һәм шактый вакыт игътибар белән аның күкрәгенә карап торды, аннары җиңел сулап:

— Безнең бәхеткә, кан тамырлары киңәюдән котыла алдык! — диде.

Бачана күзен ачты.

— Исәнмесез, хөрмәтле профессор!

— Сез йокламыйсызмыни? — дип гаҗәпләнде профессор.

— Мин, гомумән, йокламыйм.

— Ничек инде ул алай?

— Менә шулай... Уяу килеш төш күреп ятам.

— Нindирәк төшләр инде ул?

— Кайсылары әйбәт, кайсылары бигүк түгел.

— Йокыга китәр алдыннан җаныгызга рәхәт булган нәрсәләр турында гына уйларга тырышыгыз, шул чакта төшләрнең дә матурлары керер.

— Ничек уйлыйсыз, профессор, котылдым микән инде мин? — дип сорады Бачана.

— Нәкъ менә шул турыда мин сезнең үзегездән сорамакчы идем әле!

Бачана аптырап калды.

— Миңа калса... Ни... Минемчә, хәлем аруланды кебек...

— Шулай булгач — бик яхшы! — Профессор Бачананың йөрәк турысына фонендоскопын куйды.

— Йә, ничек? — дип сорады Бачана. Аның тавышы калтыранып китте.

— Ачык ишетелә. Кичә тоныграк иде.

Профессор китәргә җыена башлады.

— Әгәр исән-имин котылсам, алтыннан сезнең ике бюстыгызны койдыртып алачакмын,— диде Бачана елмаеп.

— Нигә икене?

— Берсен сезгә бүләк итәм, икенчесен үземнең язу өстәлемә куеп, гыйбадәт кылыр өчен.

— Гогилашвили сезгә караганда зирәгрәк булып чыкты, ул берне генә ясатырга вәгъдә итте!

— Аннан тыш, хатыныгызга бриллиант кашлы алка һәм гомерегез буена аяк киемегезне бушлай төзәтүямау,— дип өстәде Булика.

— Ходай сәламәтлек бирсен сезгә! Инде кайтып хатыныма әйтим: колагын тиштерә торсын... Ә сез нәрсә вәгъдә итәсез, Иорам-атакай?

— Үзегез буе шәм койдыртып, сезгә мәңге изге теләкләрдә булырмын.

— Тик менә инфаркттан соң хәтер ягы саега башлый, шулай булгач...— профессор көлеп җибәрде.— Йә, тагын нинди зарыгыз бар?

— Менә, күселәр турында әйтмәкче идек тә... Сезне күрү шатлыгыннан онытып җибәргәнбез...— дип, Булика күз кырые белән генә фельдшер хатынга карап алды.

— Нинди күселәр? — дип гаҗәпләнде профессор.

— Аның үше айнымас сәрхүшнең күзенә нәрсә күренмәс, хөрмәтле профессор! — дип авыз эченнән мыгырданды фельдшер.

— Ярар, минем күземә күренсен дә ди, нәрсә, аңа да күренгәнме?— дип, хәтере калган Булика Иорамга төртеп күрсәтте.

— Югыйсә, алай зыяннары тими дә тиюен...— диде изге ата басынкы гына итеп.— Соң, чыгып йөреп керәләр инде, шикәр кимергәлиләр...

— Хуҗалык мөдирен чакыртыгыз! — дип боерды профессор.

— Күсе шикәре алырга китте ул,— дип җавап бирде врач.

— Күсе шикәре? Анысы нинди галәмәт тагын? Республика шифаханәсендә шулай үз рационнарын төзерлек

булып күсе үрчедемени инде? — Профессор тәмам чыгырыннан чыкты.

— Күсе агуын шулай атыйлар! — дип аңлатты врач.

— Мышьяк! — дип төгәллек кертте фельдшер хатын.

— Нинди тәртипсезлек! — диде профессор ярсып һәм хушлашмыйча бүлмәдән чыгып китте.

— Бәлки, әйтергә кирәк булмагандыр,— диде Булика борчылып.

— Әйтсәң дә, әйтмәсәң дә — хакыйкать күз алдында бит. Бераз сабыр итсә, үзе дә күрер иде,— дип җавап бирде Иорам һәм:— Мә!— дип Буликаның караваты астыннан килеп чыккан күсегә шикәр шакмагы ыргытты.

Берәр сәгать чамасы үтүгә, бүлмәгә больницаның баш врачы, хуҗалык мөдире, дезинфекция ясаучы, ике санитар, палата врачы һәм фельдшер хатын Женя килеп керделәр.

— Кайда күсе? — дип төрпә генә итеп сорады дезинфекция ясаучы.

— Менә монда! — диде Булика һәм кулы белән уң күз кабагын әйләндереп күрсәтте.

— Нәрсә, коткы таратып ятасызмы монда?

— Әнә ул шикәрне мин кимереп ыргытканмыни? — дип, Булика идәндә аунап яткан, кимерелгән шикәр шакмагына күрсәтте.

Санитарлар карават асларын тикшерергә керештеләр, аннары бүлмәне айкап чыктылар, һәрбер ярыкйорыкка төйгечләп мышьяк тутырдылар.

— Мышьяк бераз искергән искерүен, тик зыян юк, иртәгәгә кадәр көтеп карыйк та, ярдәме тимәсә, песи алып килербез,— дип, авыруларны тынычландырды дезинфекция ясаучы һәм санитарларга таба борылды: — Минем бүлмәгә дә сибеп чыгыгыз, шкаф аякларын кимереп бетергәннәр, каһәр суккырлары! Тагын нинди зарыгыз бар?— диде ул янә авыруларга мөрәҗәгать итеп.

— Ни өчен Америка Көньяк Кореядан үзенең гаскәрләрен чыгармый? — диде кинәт Булика.

— Җәнҗалчы! Бичара анонимщик! — дип ярсыды дезинфекция ясаучы һәм, ачуыннан ишекне шап иттереп ябып, бүлмәдән чыгып китте.

Булика аның артыннан:

— Синең атаң ул җәнҗалчы һәм анонимщик, ә үзең син — күсе! — дип кычкырып калды.

Бераздан, кулына шприц тотып, палатага Женя әйләнеп керде. Ул Бачананың койкасы янына килде һәм, одеялын кайтарып, үзалдына сөйләнгән сыман:

— Бу пантопонны, артыгын такылдамасыннар өчен, кайберәүләрнең теленә кадыйсы иде дә бит!—дип куйды.

— Бу сүзегез минем колакка төбәп әйтелгән булса, пантопон салыр өчен минем башка урыным да бар! — дип җавап кайтарды Булика.

Женя аңа җавап бирүне кирәк дип тапмады ахрысы, Бачанага укол ясады да, кадаган урынны бераз ышкып торганнан соң, сүзсез генә чыгып китте.

Бераздан фельдшер хатын кабат әйләнеп керде:

— Сезне ниндидер бер ир кеше сорый,— диде ул Бачанага.

— Кем икән ул?

— Якын кардәшем,— ди.

— Әгәр сез каршы килмәсәгез — керсен.

Женя чыгып китте дә тәбәнәк буйлы, кыска куллы, аксыл чыраен сипкел баскан бер кешене ияртеп керде.

— Биш кенә минутка! — дип кисәтте Женя.

— Мин хәзер сүземне бетерәм! — диде ишектән керүче һәм, урын тәкъдим иткәнне дә көтеп тормастан, Бачананың караваты янындагы урындыкка килеп утырды.

— Исәнмесез, хөрмәтле Бачана! — Ул җиңелчә генә Бачананың ботына кагылып алды.

— Исәнмесез! — диде Бачана сәерсенеп.

— Танымыйсызмы әллә?

Бачана бар булган хәтерен эшкә җикте, әмма аксыл чырайлы кешенең кем икәнлеген исенә төшерә алмады.

— Ә болай? — дип, әлеге кеше аңа яны белән борылды. Бачана уңайсызланып елмаеп куйды.

— Исегезгә төшерегез әле: Сухуми, Чернявка, Венеция күпере, унөченче мәктәп, сезнең түтиләрегез — Маро, Нина, Тамара, туганнан туган апа-сеңелләрегез — Нелли, Зулейка, Додо, туганнан туган энегез Коко...— дип, бармакларын бөгә-бөгә санап китте ул.

— Үзегезнең кем булуыгызны искә төшерсәгез иде, туганнарымны болай да яхшы хәтерлим мин,— диде Бачана.

— Нугзар, Нугзар Дарахвелидзе мин! Хәтерлисезме, Нина апагыз минем сеңелемне чукындырган иде һәм аңа Луиза дип исем кушкан иде...

— Үтерсәгез дә хәтерләмим...

— Ә бит шуннан бирле аны гел Луиза дип йөртәләр...

— Бик әйбәт!

— Мин әнә шул Луизаның абыйсы, Нугзар Дарахвелидзе булам инде! — дип, аксыл чырайлы кеше соңгы ачыклыкны кертте.

— Ә миңа ни йомышыгыз төште соң? — дип сорады Бачана.

— Кәефегез ничек, хөрмәтле Бачана? Халык бик борчыла...

— Болай ярыйсы...

— Кыяфәтегез бик шәп күренә, ходай сәламәтлек бирсен үзегезгә! Төсегез дә менә дигән! Бераз ябыгыбрак киткәнсез китүен... Әле күптән түгел генә телевизордан сезнең чыгышыгызны караган идек... И-и, күрсәгез, безнең активтагы бар кеше тәгәрәп көлде!.. Сезнең бит телегезгә шайтан төкергән... Ха-ха! Бигрәк тә антиподлар турында сөйләгәндә!.. Әйе, ул чагында сез бераз тулырак идегез... Хәер, болай да — тфү, тфү, күз тия күрмәсен,— кыяфәтегез бер дигән, дусларны сөендереп, дошманнарга үч итеп, дигәндәй...— Ак чырайлы кеше тагын Бачананың тезеннән каккалап алды.

— Үзегезнең, сеңелегез Луизаның хәлләре ничегрәк? — дип кызыксынды Бачана әдәп йөзеннән.

— И-их, әйтәсегез бармы! Хәлләр начар, хөрмәтле Бачана, тагы да начаррак булуы мөмкин түгел! — Дарахвелидзе тирләгән маңгаен сөртеп алды.

— Ни булды соң? — дип борчыла калды Бачана.

— Ничек дип әйтим... Чит кешеләр алдында уңайсызрак бит...

— Аларга урыннарыннан кузгалырга ярамый, ә миңа бигрәк тә... Димәк, әйтер сүзегез булса, алар алдында сөйләргә туры килә инде...

— Ходай хакы өчен сөйли бирегез! Без — хәзер! — дип, Булика башыннан ук одеялын бөркәнде дә стенага таба борылып ятты. Иорам-атакай да шулай итте.

Дарахвелидзе бераз икеләнеп торды һәм, ниһаять, тәвәккәлләп сүзен башлады:

— Ул кадәр искитәрдәй нәрсә юк югын, хөрмәтле Бачана, матур итеп кул гына куеп җибәрсәгез...

— Беләсезме, миңа әле генә пантопон уколы ясадылар, йоклап киткәнче, тизрәк сөйләп калыгыз.

Дарахвелидзе одеялларын башларыннан ук бөркәнеп яткан күршеләргә тагын бер күз ташлады да сүзгә кереште:

— Сезгә, әлбәттә, мәгълүм инде... республикада хәлләр бераз теге ни... киеренкеләнебрәк китте бит... Әле опера театрының көлен күккә очыралар, әле универмагка ут төртәләр... Кайсыдыр берәве атылган диләр, икенчесе үзенең кан тамырларын кискән... Шул сәбәпле, бер сүз белән генә әйткәндә, хәлләр шәптән түгел... Кадрлар мәсьәләсендә дим... Аннары базарда... ит яклары да... ниерәк...

— Ә сыйр ничек? — дип елмайды Бачана.

— Сез һаман шаяртасыз, хөрмәтле Бачана, анысын мин аңлыйм, сезнең эшегез шул... Ә ит белән сыйрны безгә, үзегез дә аңлыйсыздыр, сыер бирә.

— Әллә яңа нәселле сыер китереп чыгардыгызмы? — дип җитди итеп сорады Бачана.

Дарахвелидзе «тагын нинди хәйлә кора икән бу?» дигән сымак, Бачанага текәлде, әмма тегесе күзен дә йоммый аңа карап тора иде. Ак чырайлы кеше, ниһаять, тынычланды.

— Юк, мин икенче бер мәсьәлә буенча килгән идем,— дип дәвам итте ул.

— Әллә утка чыдамлы опера театры бинасының проектын төзедегезме?

Дарахвелидзе тирләп чыкты. Ул кымшанмыйча бер хәрәкәтсез яткан Булика белән Иорам-ата ягына таба сагаеп кына карап алды да, бер мәл икеләнеп торганнан соң, ниһаять, ныклы фикергә килеп, кесәсеннән ике конверт чыгарды.

— Хөрмәтле Бачана, зинһарлап сорыйм, җитәкче оешмага яисә үзебезнең райком секретарена гозерләп хат язсагыз иде...

— Ә минем нинди катнашым бар соң әле биредә? — дип, чын-чыннан гаҗәпләнә калды Бачана.

— Нишләп булмасын ди! Сез — бик мәрхәмәтле язучы, депутат, Үзәк Комитет члены! Сезгә килеп егылмыйча, кемгә барыйм инде мин тагын? — дип, үз чиратында Дарахвелидзе да чын-чынлап гаҗәпләнә калды.

— Кайда эшлисез сез?

— Абхазиядә, тәмәке яфрагы хәзерләү буенча.

— Җитәкчеләргә нәрсә дип язарга тиеш инде мин?

— Һәркемгә мәгълүм ич: сез безнең секретарь белән аерылгысыз дуслар, мәктәптә дә бергә укыгансыз...

— Минем янга сезне кем җибәрде?

— Безнең секретарьга яхшылык теләүче кеше, әлбәттә... Конвертларның берсе сезнеке, икенчесен — үзегез кирәк санаган кешегә тапшырырсыз...— дип, Дарах-

велидзе ике конвертны да ялт кына итеп мендәр астына шудырды.

— Нәрсә, сезне эшегездән алдылармы әллә?

— Мине алай җиңел генә ала алмыйлар алуын, хөрмәтле Бачана... Тик шулай да бераз ярдәм итүнең зарары булмас иде... Хәтта бүгенге көндә мине төртеп төшерергә җыенган кешегә дә!

Әкренләп пантопонның тәэсире сизелә башлады: Бачананың күз кабаклары авырайды, аның күктән иңгән әлеге кардәшенә сораулар бирү түгел, тел әйләндереп сүз әйтерлек тә хәле калмады.

— Ни булганын рәтләбрәк аңлата аласызмы? — диде ул көч-хәл белән күз кабакларын кыймылдатып. Тегесе, ашыгырга кирәклеген аңлап, кабалана-кабалана сөйләргә тотынды:

— Ни булсын, ревизия җибәрде ул миңа!

Ишектән Женяның башы күренде.

— Беләсегез килсә, инде егерме минут узды!

— Хәзер, хәзер, кадерле Женя, бераз гына сабыр итегез, бик кызык нәрсәләр сөйли бит әле! — дип үтенде Бачана.

— Әйе...— дип сүзен дәвам итте Дарахвелидзе.— Ревизия җибәрде!.. Хәзерләү-саклау буенча егерме ел эшлим инде мин! Шул гомер эчендә беркайчан да берәүнең дә миңа ревизия җибәрергә җөрьәт иткәне булмады!.. Мин аны башта шаярта дип торам!..

— Ревизия ничегрәк үтте соң? — дип сорады Бачана.

— Ничек булсын ди! Грузия белән Абхазиядә ничә данә папирос һәм сигарет тартылганын берәмләп санарга тотындылар, адәм актыклары... Аннан килеп, имеш, без быел өч йөз тонна тәмәке яфрагына йөз тонна кипкән үлән кушканбыз дип әйтеп салмасыннармы? Кайсысы шулай сөйләнә диген син?! Кабинетларыннан беркая да чыкмый утыручылар шулай ди бит! Тәмәкенең кайда үскәнен беләмени алар? Тәмәке ул басуда үсә, әгәр аңа ияреп ике бөртек үлән йолкына икән, шуннан ни булган? Аннан килеп, үлән — агу түгел ләбаса. Үләннән берәүнең дә аяк сузганы юк әле. Шулай булгач, нинди корткычлык ди инде бу? Сыер энә гомере буе үлән ашый, үләме соң ул аннан? Алайса нәрсә ашатырга ди аңа — тәмәке яфрагымы? Сезнең кебек кешеләрне никотин белән тончыктыралар, агулыйлар, менә кайда ул корткычлык!.. Ул гына да түгел! Аннары алар, беләсегез килсә, әлеге үләнне тәмәке яфрагы бәясеннән тап-

шырып, миллионлаган сум акча ясыйсыз дип гаепләмәкчеләр!.. Печәннең тоннасы иң күп дигәндә ун тәңкә, кайдан килсен ди ул миллионнар?! Сөйләнә торгач әле, ул акыллы башлар «тәмәке яфрагын чылатасыз, юешләнгәч аның авырлыгы бермә-бер арта» дигән гаеп тә ташладылар.

— Шулай да бөтенесе ничә миллион була соң?

— Кайсысы: хөкүмәткә тапшырганымы, әллә арттырып язганымы?

— Бөтенесе бергә.

— Шактый...

— Шулай да?

— Әйтсәм дә барыбер ышанмассыз...— дип боргалана башлады Дарахвелидзе.

— Ревизия тагын нәрсәләр диде?

— Нәрсә димәс алар? Җитмәсә әле тагын өйгә килгәннәр... Имеш, нигә сезнең өегез ике катлы?! Бүлмә саен кереп, тыкшынып йөриләр! Ике катлы дигән булып соң инде! Норма буенча, түшәмнең биеклеге ике метр ярымнан артмаска тиеш, ә минем беренче катта нибарысы ике метр да кырык сигез сантиметр...

— Ә ул ике сантиметрның ни әһәмияте бар? — дип көлеп куйды Бачана.

— Нишләп инде, хөрмәтле Бачана. Пуля да ике генә сантиметр, ә үзе үгезне бәреп ега! Узган ел, исемен әйтеп тормыйм инде, берәүне еккан пуляның да озынлыгы ике генә сантиметр иде... Бу турыда дустыгызга сөйләп тормагыз, әлбәттә, болай сүз уңаеннан гына әйтүем... Аннан килеп, өске катта сигез бүлмә дип санап чыгардылар! Залны бүлмәгә чутлаган грузинны кешегә санамыйм, төкерәм мин аңа, тфү! Ярый әле лоджия белән биллиард бүлмәсен шул исәпкә кертмәделәр! Шунысына шөкер! Хөрмәтле Бачана, чык бөртегедәй саф кеше мин! Сезнең ул ахирәт дустыгыз секретарь бәйләнмәсен миңа... Сезнең сүздән чыкмый ул!.. Минем йөзгә шулай кара яккач, сезне дә мәсхәрәләгән кебек була бит инде...

— Ә нишләп мине? — дип, күзен ачты Бачана.

— Шулай булмыйча соң! Әгәр дә мәгәр кайсысыдыр сезне, ягъни минем якын туганымны яманлый икән, димәк, ул минем намусны да пычрата! — дип кычкыра төшеп әйтте Дарахвелидзе.

Бачана үзенең барча якын кардәшләрен күңеленнән кичереп чыкты һәм, алар арасында Дарахвелидзега охшаганы табылмагач, тынычланып калды.

— Эттән туган нәрсә! — дип кинәт кабынып китте өлеге кеше.— Ниндидер ун тәңкә өчен берәүләрне кулга ала, ә үзе минем урынны миллион сумга сатарга йөри!

— Күпмегә дисез? — дип кайтарып сорады Бачана.

— Ярты миллионга! — дип киметә төште Дарахвелидзе.

— Сез чыннан да шундый зур акча белән эш итәсезмени?

— Кая инде! Сез нәрсә!.. Безнең байлык юк инде ул...

Бачана мендәр астындагы конвертларны капшап карады. Дарахвелидзе күзен читкә алды.

— Менә терелеп чыгыйм да, шунда сөйләшербез! — диде Бачана.

— Әйе, көтеп тор! — дип ычкындырды Дарахвелидзе, тик шунда ук хатасын төзәтергә ашыкты.— Сез әле аякка тиз генә баса алмассыз дип әйтүем, ә мине берсекөнгә бюрода тикшермәкчеләр... Шуннан туп-туры алып китүләре дә ихтимал... Ике генә сүз!.. Сезнең кул белән язылган ике генә сүз!..

Бачана, мендәр астындагы конвертларны алып, күкрәгенә куйды.

— Күпме монда?

Дарахвелидзенең йөзе балкып китте.

— Бер ярым лимон! Саклык кенәгәсендә! Уртакка кермичә!

Бачана бермәл уйлана калды. Дарахвелидзе, түземсезләнеп, утырган җирендә кыбырсырга тотынды.

— Хөрмәтле Нугзар,— дип башлады Бачана байтак кына сүзсез ятканнан соң,— әнә шунда, караваг астында бер савыт бар. Авырсынмыйча гына алып бирегез әле шуны... Түзәрлегем калмады, гафу итегез инде...— Дарахвелидзе, нишләргә белмичә, аптырабрак калды.— Курыкмагыз, чиста ул...

Дарахвелидзе, күндәм генә иелеп, савытны алды да Бачанага сузды. Тегесе хәлсез уң кулы белән чүлмәкнең сабыннан тотты.

— Аз гына читкәрәк китегез әле, зинһар! — дип үтенде ул Дарахвелидзедан. Тегесе урындыгы белән бергә бер адым арткарак чигенде. Бачана кунак белән ике арадагы ераклыкны чамалады да селтәнеп торып чүлмәкне Дарахвелидзенең башына каплады.

Чүлмәк чылтырап идәнгә коелды. Дарахвелидзе, әкрен генә урындыгыннан шуып төшеп, йөзе белән идәнгә капланды...

— Чүлмәк буш идеме? — дип сорады Булика.

— Буш иде! — диде Бачана.

— Анысы менә кызганыч булган!— дип уфтанды Иорам-ата һәм: — Женя!.. Же-е-ня!..— дип фельдшерны чакырырга кереште.

6

Эсседән көйгән кола яланда Бачана җиде көн, җиде төн буена каңгырап йөрде. Беренче ике көнне ул җәяүләп барды, аннары тезләнеп үрмәләде, соңгы ике көндә инде корсагына ятып шуышты. Тәмам хәлдән таеп, газапланып, яргаланып беткән иреннәре белән капланып, йөзе кайнар сары ком эченә күмелгәч, әҗәле якынлашуын сизенеп, ул чалкан әйләнде һәм нурсызланган күзләрен кояшка төбәп, гомерендә беренче тапкыр аңа үзенең үпкәсен белдерде:

— И кояш, нигә син мине болай үлемгә дучар иттең?

Шул чакны кояш өслегендә кеше сурәте пәйда булды һәм аның күләгәсе Бачанага төште.

— Кем син? — дип сорады Бачана.

Аның каршында какча гәүдәле, яланаяклы, җете зәңгәр күзле бер үсмер егет басып тора иде. Кояш аны арткы яктан яктырта идеме, әллә аның башы очында торып, нурлы алка балкыта идеме — анысын Бачана аңлый алмады.

— Мин — синең тәңрең һәм хөкемдарың! — диде егет.

— Бу сүзләреңнең хаклыгын ничек исбатлый аласың?

— Синең катыңда пәйда булуым шуңа дәлил түгелмени?

— Юк! Комнар арасында юлдан язып, бер тамчы суга тилмергән кешенең саташуы гына син!

Бачана әлеге сәер затның күздән югалуын озак көтте. Әмма шәфкатьле һәм гаҗәеп дәрәҗәдә җанга якын тоелган әлеге егет, сабыр-тыныч бер кыяфәт белән елмаеп, каршында басып тора бирде. Шунда Бачана аңа якынрак шуышып килде һәм, кыяр-кыймас кына кулын сузып, егетнең яланаягындагы аксыл-кызгылт җәрәхәт эзенә кагылды.

— Шикләреңне ташла! — дип елмайды егет.

— Дингә ышанмаучы дәһри мин, шөбһәләнүем дә шул сәбәптән. Мин үз күзем белән күргән нәрсәгә үзем ышанып җитә алмыйм. Ничектер миннән читтә сыман бу хәл. Якынрак килеп, аңлат әле син миңа: синең җир йө-

зендә булганың бармы? Әгәр бар икән, кешеләрне ни сәбәпле ташлап киттең? — дип сорады Бачана.

— Адәм балалары үзләре миннән йөз чөерделәр, әмма минем кешене беркайчан да ташлап киткәнем юк...— диде егет әкрен генә.

— Ә син моны ничек дәлилли аласың?

— Минем биредә булуым үзе шуны раслый түгелме соң?

Бачана тагын бер тапкыр егетнең яланаякларын кулы белән сыйпап карады:

— Барлыгың ни синең, тәңрем?

— Инану-ышану, өметләнү, көч-куәт, мәрхәмәт, чын йөрәктән ярата белү һәм ирек мин!

— Ә нишләп соң, утыз тиен көмешкә кызыгып, Иуда сиңа хыянәт итте?

— Иуда тәңресенә хыянәт итмәде, ә бәлки ул утыз тиен көмешкә мөнафикъларга үзен-үзе сатты. Чөнки аның үз бәһасе нәкъ шуның кадәр иде, һәм шул бәһагә сатып алдылар да аны. Бүген менә синең ятагың астына кыстырылган акчалар синең бәһаң түгел иде, шул сәбәпле син сатылмадың. Ә инде бүген сатылмагач, иртәгәсе көнгә синең барлыгың, һичшиксез, кыйммәтрәк бәяләнәчәк.

— Әгәр мин иртәгә дә, аннан ары да сатылмасам?

— Ул чагында син дөнья бәһасе кешегә әвереләчәксең, һәм мин нәрсә хакына аяк-кулларым белән тәрегә кадакланган булсам, син шул максатны чынлыкка ашырачаксың.

— Иуданың үзеңә хыянәт итәсен син белә идеңме?

— Монысы иблискә мәгълүм иде. Ходай тәгалә кешене юлдан яздырмый, ул аны сыный гына. Иуданы, утыз көмешкә сатып алып, иблис юлдан яздырды. Мин исә, Иуданың кулына бау тоттырып, аны сынап кына карадым.

— Һәм син Иудага ләгънәтләмәдеңме?

— Юк.

— Ни өчен?

— Чөнки Иуда унбер кешене зур гөнаһтан коткарып калды.

— Шулай булгач, ни өчен син Иудадан мәңгелек хурлык тамгасын алып ташламыйсың?

— Чөнки Иуда ходай затыннан түгел, иблис токымыннан ул.

— Димәк, иблис сине җиңгән булып чыгамы?

— Әгәр Иуда үзенә кул салмаса, шулай килеп чыгасы иде.

— Голгофа тавына менгәндә, халыкның сине аяк-кулларыңнан тәрегә кадаклап куясына син инана идеңме?

— Юк!

— Нәрсәгә өметләндең соң?

— Халыкка.

— Шул халык сине ниндидер бер каракка алыштырды түгелме соң?

— Әйе, халык.

— Димәк, бу очракта да иблис сине җиңгән килеп чыга?

— Юк, чөнки бу — юлдан яздырырга маташу түгел, үзенә күрә бер сынап карау иде.

— Һәм халык әлеге сынауны күтәрә алмадымы?

— Әйе.

— Ни сәбәпле?

— Чөнки халык миннән могҗиза көтте, ә карактан нәрсә өмет итәсең? Шуңа күрә ул мине бер каракка алыштырды да... Бу минем Адәм балаларын икенче тапкыр, вакытыннан элегрәк, сынап каравым һәм минем икенче тапкыр ясаган хатам иде.

— Ә беренче ялгышлыгың нәрсәдә иде соң?

— Адәм баласына җәннәттә сыенып урын бирәсе түгел иде миңа. Кеше, башка берәүнең ихтыяры белән түгел, бәлки җәннәткә керү хокукын үзе тир-кан түгеп, иманы белән яулап алырга тиеш!

— Тәрегә кадаклануның котылгысыз булуына син кайчан инандың?

— Каршымда басып торган анамны һәм яраткан шәкертемне күреп алганнан соң. Шул чагында мин анама: «И ханым, менә бу синең улың!» — дип дәштем. Шунда мин шәкертемә: «И адәми зат, менә бу синең анаң!» — дип сүз каттым. Шуннан соң, анам белән минем урыныма ул калды, анам исә аның өчен изге рухка әйләнде...

— Ни боерасың син миңа?

— Аягыңа торып бас!

Бачана яткан урыныннан күтәрелде.

— Сусау газабы тоймыйм дип икърар ит!

— Сусау газабы тоймыйм мин,— дип кабатлады Бачана һәм тәнен әлсерәткән сусау шундук юкка чыкты.

— Кояш нурлары көйдерми мине дип икърар ит!

— Кояш нурлары көйдерми мине! — дип кабатлады

Бачана һәм шул мизгелдә үк, тәмам хәлне алган, кояш нурлары сүрелгән кебек булды.

— Яшәвемә һәм тәңремә ышанам дип икърар ит!

— Яшәвемә ышанам...— дип кабатлады Бачана, әмма «тәңремә» дигән сүзне йомып калды, чөнки бу хәл аңа һаман да әле ниндидер бер саташулы төш булып кына тоела иде.

Шулвакыт егет:

— Күңел төпкелегендә сакланган иң изге хыялыңны әйт! — диде.

— «Ни өчен мин кеше булып туганмын? Ник җиргә яңгыр булып яумаганмын?» — дип, Бачана шунда Важа Пшавеланың шигырь юллары белән җавап бирде һәм кинәт...

...Яңгырга әверелеп, җирне сугарды һәм эсседән көйгән кола ялан өсте ямь-яшел, сусыл, бала үлән белән капланды...

Бачана, яңгырга әверелеп, җирне сугарды, һәм эсседән көйгән кола ялан өстендә күз явын алырдай матур хуш исле чәчәкләр калкып чыкты...

Бачана, яңгырга әверелеп, җирне сугарды, һәм эсседән көйгән кола ялан өстендә, арган буыннарга көчсихәт бирә торган, саф сулы, салкын чишмә бәреп чыкты...

Бачана, яңгырга әверелеп, җирне сугарды, һәм эсседән көйгән кола ялан өсте, җан өргәндәй, ямь-яшел, шау чәчәкле үзәнлеккә әйләнде...

Бачана, яңгырга әверелеп, җирне сугарды һәм кинәт үзе дә шул гүзәл үзәнлектә үсеп утырган гаҗәеп биек, калын кәүсәле, тамырлары белән бөтен җир шарын урап торган һәм башы белән чиксез күккә ашкан баһадир бер имәнгә әйләнде... Шул чакны, төркем-төркем булып, дөньяның һәр тарафыннан исәпсез-хисапсыз сайрар кошлар очып килеп, әлеге имәннең ботакларына кундылар, яфрак араларында оя тибеп, бала чыгардылар, һәм бар галәмгә терәклеккә дан җырлаучы мәдхия авазлары яңгырады...

Шунда Бачана, егет катына килеп, җиргә тезләнде һәм башын түбән иеп:

— Мин сине үз күзем белән күрдем һәм бар булуыңа инандым,— диде.

Шулчак Гайсә пигамбәр әйтте:

— Син мине үз күзең белән күреп барлыгыма ышандың. Үз күзләре белән күрми торып та миңа инанганнар исә — чын мәгънәсендә бәхетле җаннар алар...

7

Бачана уянганда, Булика аякларын бөкләп урын өстенә менеп кунаклаган да, аркасын мендәренә терәп, Иорам-атаның, псалтырь сыман көйли-көйли, газета укыганын тыңлый иде.

— Хәерле көн, дуслар! — дип, күршеләренә сәлам бирде Бачана.

— Бәрәкалла, тупсабызны атлап керүчегә сәлам! — диде Булика сөенеп.

Иорам-ата да, газетасын читкә куеп, зур итагатьлек белән аның хәлен белеште:

— Кәефегез ничек, хөрмәтле Бачана?

— Хаува яратылганчы, җәннәттә яшәгән яшь Адәмнеке кебек!

— Ялгыз гына күңелсезрәк түгелме соң?

— Киресенчә, җәннәт тулаем үземнеке сыман тоела!

— Ә сез, хөрмәтле Бачана, менә дигән егет икәнсез ләбаса! — диде Булика, соклануын яшермичә.— Андый нокаутны әле минем моңарчы күргәнем юк иде: өч йөзгә кадәр санадым, ә ул, күзен йомып, һаман кымшанмый ята бирә!

— Кем ята бирә? — дип сорады Бачана.

— Менә монысы миңа ошый! Бәндә баласын үзе аздан гына тәүбәсез-нисез теге дөньяга олактырмый калдырды, ә үзе тагын «кем» дип сорап тора!— диде Иорам.

— Соң, сез бередә идегез ич, изге атакай,— дип шаяртты Бачана, әмма үзе эчтән ничектер уңайсызланып китте. Әлеге бәрелеш бөтенләй диярлек аның хәтереннән чыккан иде: күрәсең, пантопон тәэсиреннәндер. Һәм менә хәзер, шул авыр хәлне исенә төшергәч, күңелендә үкенүле бер гарьлек хисе кичерде.— Дөресен генә әйткәндә, бередә нәрсә булганын мин инде анык кына хәтеремә төшерә алмыйм, — диде ул, маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп.

— Борчылмагыз, хөрмәтле Бачана, без дә һични хәтерләмибез: мин йоклый идем, ә Иорам-ата гыйбадәт кыла иде. Шулай бит, изге атакай? — дип Иорамга мөрәҗәгать итте Булика.

— Хак сүз! — дип җөпләде аны тегесе.

— Димәк ки, без шаһит булып бармаячакбыз! — дип өстәде Булика.

— Шулай да, нәрсәләр булды соң? — диде Бачана ихлас күңелдән кызыксынып.

— Эш менә болайрак килеп чыкты: димәк ки, сез әлеге кешенең башына сугып тәрәт чүлмәген чәлпәрәмә китергәч, ул адәм идәнгә әйләнеп төште. Булмәгә шундук Женя атылып керде һәм аңа камфара уколы кадады, башына йод сөртте. Аннары кинәт теге кеше сикереп торды да кычкырырга тотынды.

— Нәрсә дип?..

— Нәрсә дипме? Имеш, сез акчаны азсынгансыз, югыйсә ни пычагыма дип башта ук тәкъдимен кире какмагансыз?

— Тагын нәрсәләр диде?

— Аннары ул ниндидер Бацалашвилины телгә алды, имеш, сез аны ресторан директоры итеп урнаштыргансыз һәм бу эш аңа шактый кыйммәткә төшкән...

— Ничек-ничек? — дип сорады Бачана аңышмыйча.

— Нәрсә «ничек»? Сез берәүне ресторан директоры итеп куйгансыз, һәм ул сезгә шуның өчен ярты миллион акча төрткән.

Бачана шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ә нәрсә? Нәкъ шулай дип кычкырды да ул.

— Юк, аннан көлмим мин... Дөрестән дә мин үзем белән эшләүче бер хезмәткәрнең туган тиешле кешесенә — әнә шул Бацалашвилига — эшкә урнашырга булыштым...

— Ала-а-ай...

— Димәк ки, хөрмәтле Бачана, кемдер чыннан да ришвәт алган түгелме соң? — дип сорады Иорам-ата.

— Шулайрак килеп чыга инде! — дип ризалашты Бачана.

— Минем дә нәкъ әнә шундый бер хәсис танышым бар! — дип сөйләргә кереште Булика.— Менә шул кеше бер ятим баланы, туганымның улын, сәүдә техникумына урнаштырды һәм миннән өч мең сум акча сорады: мең ярымы, имеш, директорга, бер меңе тагын кемгәдер, кайсынадыр өч йөзе, ә ике йөзе, имеш, хезмәте өчен, үзенә... Нишләмәк кирәк? Энекәшнең ниндиерәк малай икәнен мин биш бармагым кебек беләм... Әле күптән түгел генә сорыйм үзеннән: 55 тән 5 не алгач ничә кала дим? 5 дип җавап бирә миңа бу, күзле бүкән!

— Соң, дөрес бит инде! — диде Бачана көлеп.

— Бар хикмәт тә шунда, әлеге «дөрес» дигәнең өч мең сумга төште миңа! Адәм актыгы, акчаны алды да кесәсенә тыкты!

— Төп башына утырттымы? — дип кызыксынды Иорам-ата.

— Юк... Урнаштыруын урнаштырды ул аны, тик менә акчаны гына суга салдым!

— Шулай булгач, нәрсәдә гаепләмәкче соң син аны?

— Ничек инде «нәрсәдә»? Декабрь аенда мине шул техникумның директоры чакыртып алды да: гражданин Гогилашвили, сез гражданин Гваладзега өч мең сум акча бирдегезме? — дип сорый. Соң, мин инде, әлбәттә, әйе, бирдем, дим.— Кара әле син аны, әшәке җан! — дип акырып җибәрде директор һәм шап итеп өстәлгә китереп сукты.

— Сине шулай дип атавымы инде аның? — дип сорады Иорам-ата, бердән кәефе китеп.

— Нишләп мине булсын! Шул адәм актыгы Гваладзены инде!

— Яла яккан бит кешегә! — диде Иорам-ата ачуы килеп.

— Син нәрсә, атакай, әллә шуны да аңламыйсыңмы? Ул Гваладзе аңа акчаны бирмәгән бит! Менә шуннан соң директор мине боргычлап алмасынмы! Син мине кем дип беләсең? — ди бу миңа. Сәүдә техникумы ул сиңа әнә теге ни түгел... Ничек соң әле... Вакеда икмәк пешерү заводы янындагы техникум... Андагы студентлар көне-төне торбалардан карыйлар инде...

— Топография техникумы! — дип әйтеп җибәрде Бачана.

— Әйе, сәүдә техникумы ул сиңа топография техникумы түгел, ди! Хәзер — декабрь. Январь аенда миңа өч мең сум акча китерәсең, югыйсә, ди, синең аңгыра кардәшеңнең студент булып йөрисе юк, ди!

— Кем шулай дип әйтә? — диде Иорам-ата исе китеп.

— Ничек инде «кем»? Директор әйтә, тагын кем булсын?!

— Йә, шуннан?

— Шуннанмы? Светам белән киңәштек тә, әйтә ул миңа: тагын шуның кадәр өстик тә, бәлки, без аны, сәүдә министры итеп урнаштыра алырбыз, ди...

— Алайса директор да кеше талаучы булып чыкты инде? — Бачана борчылып урыны өстендә әйләнгәләп куйды.

— Булып чыкты шул менә, кадерлем! Сезгә чүлмәк кирәк түгелдер бит? Яңасын китергәнче, минекен алып тора аласыз...— диде Булика.

— Рәхмәт, кирәкми... Шуны уйлап ятам әле, бәлки, миңа ул акчаны алырга кирәк булгандыр?

— Белмим... Акча дигәнең, яман да шакшы нәрсә инде югыйсә...— диде Булика уйга калып.

— Кешелекне утыз тиен көмеш харап иткән! — диде Иорам-ата тавышын күтәрә төшеп.— Утыз тиен көмеш!

— Мин үзем, хөрмәтле Бачана, кешенең кем булуын теге ни... Ничек атала соң әле? Физ... Физи...— дип сүз башлады Булика.

— Физиономистлар.

— Менә, менә! Тик алар кешене йөзенә карап танып беләләр, ә мин — аяк киеменә карап... Аяк киеменнән кемнең нинди җан иясе икәнен төп-төгәл әйтеп бирәм. Баягынак әнә сезнең янга килгән бәндәнең, туфлиенә күз салуга, аның адәм актыгы һәм хәсис бер зат икәнен шундук аңлап алдым...

— Ничек итеп? — дип сорады Бачана.

— Беренчедән, аның туфлие ялтыравыклы иде...

— Ә мин, киресенчә, аны берәр профессордыр дип уйлаган идем,— диде Иорам-ата, Буликаның сүзен бүлдереп.

— Ишектән керүгә туфлиләрен чалбар балагына ышкып алды...— Булика күз кырые белән генә атакайга карап куйды.— Профессор кеше гомерендә дә алай итмәс... Икенчедән, туфлиләренең олтаны баш ягыннан ашалып беткән, ә үкчәләре өр-яңа. Димәк, ул аларны кешелеккә дип тота һәм башлык-түрәләр янына барганда гына кия. Алар каршында инде ул, анысы көн кебек ачык, әлбәттә, аяк очларына гына басып йөри, шул сәбәпле, туфлиенең башы гына ашалган да... Йә, кабахәт кеше түгел дип әйтегез инде шуны?! Әлбәттә,— кабахәт... Өченчедән, урындыкка килеп утыруга, аякларын туфлиеннән яртылаш чыгарып куйды. Ни өчен дисезме? Аяк киеме кысан аның, шуның өчен! Ә ни сәбәпле кеше кысан аяк киеме кияме? Йөзенә интеккән бер кыяфәт чыгару өчен! Менә, янәсе, күрегез, күпме җәфалар кичергән, нинди бичара кеше ул!.. Йә, адәм актыгы булмыйча, тагын кем инде ул? Дүртенчедән, үкчәләре дә гадәттәгедән өч-дүрт сантиметрга биегрәк иде. Ни өченме? Чөнки аның үз буеннан биегрәк булып күренәсе килә! Кабахәтме? Һичшиксез! Кабахәт булмыйча тагын нәрсә?! Әйе, иң мөһиме шул — монысы инде аяк киеменә карамый — иң мөһиме шул: әгәр берәүнең башына тәрәт чүлмәге китереп каплыйлар, ә ул үзен мәсхәрә итүченең бугазына килеп ябышмый икән — димәк, ул кеше түгел, кабахәтлекнең дә аръягына барып чыккан

бер хәшәрәт! — дип, Булика Дарахвелидзеның характеристикасын төгәлләде.

Иорам-ата, Буликаның фикер сөреше белән бик үк килешеп бетмәгәндәй:

— Яхшы кешенең аяк киеме ниндирәк була соң, алайса? — дип сорады.

— Адәм рәтле кешенең аяк киеме бар ягыннан да тигез ашала: алдан да, арттан да, яннан да... Алганда да ул аны бер үлчәмгә зурракны ала. Ни өчен дисезме? Рәхәтләнеп, иркенләп йөрер өчен, аякны кырмасын өчен... Аңлашылдымы? Тагын бер нәрсә: әгәр туфлинең арты тапталып-ашалып беткән икән — димәк, әлеге кеше йә башка берәүнең аяк киемен киеп йөри, яисә инде ул җыйнаксыз, оешмаган бер адәм...

— Ә балаларныкы ничегрәк? — дип кызыксынды Бачана.

— Балалар — бөтенләй башка нәрсә. Аларның әле сөякләре ныгып җитмәгән, аннан соң алар бик хәрәкәтчән... Аяк киеменә карап, баланың ниндилеген белүе кыен...

— Ә син үзең? Синең аяк киеме ничек ашала? — дип, Иорам-ата көтмәгәндә генә Буликаның үзенә карата сорау бирде.

Булика бермәлгә югалыбрак калды.

— Минме?

— Әйе-әйе, син!

Булика, иелеп, караватастыннан шактый таушалган, үкчәләре изелеп беткән туфлиен алды һәм гаҗәпләнеп бермәл кулында әйләндергәләп торды.

— Һм, бакчы, мин үзем дә ярыйсы ук әшәке бәндә икәнмен! — дип авыз эченнән мыгырданып куйды ул һәм, кәефе кырылып, туфлиен караватастына ташлады.

Бачана белән Иорам-ата пырхылдап көлеп җибәрделәр. Булика үзе дә көләргә тотынды.

— Хөрмәтле Иорам,— диде Бачана, кинәт кенә әңгәмәне икенчегә борып.— Сезнең төшегездә аллаһе тәгаләне күргәнегез юкмы?

Иорам-атаның күзләре шакмакланды. Ул, ачкан авызын яба алмыйча, бермәлгә өнсез калды. Аннары, ниһаять, тотлыга-тотлыга сөйләнә башлады:

— Хөрмәтле Бачана... Ходай-тәгаләнең төшкә керүе һич мөмкин түгел... Чөнки ул илаһи бер хәлдер... Миңа калса, хәзергә әле тәңренең мине андый бәхеткә лаек дип тапканы юк...

— Тавышын да ишеткәнегез юкмы?

— Анысы да илаһи бер хәл!..

— Алайса нәрсәгә максат баглап хезмәт итәсез соң сез?

— Нәкъ менә шуңа... Ходай-тәгаләгә якынаер өчен, аның тавышын ишетер, йөзен күрер өчен!

— Ул чагында безгә хезмәтләребезне алмаштырырга кирәк.

— Ни сәбәпле? — диде Иорам-ата сагая төшеп.

— Моннан бер сәгать элек мин төшемдә аны күрдем.

— Кемне?

— Тәңребез Гайса пигамбәрне!

Иорам-атаның тавышы калтыранып куйды:

— Углым, «Ялган сүз сөйләмә!» дигән васыятьне исеңнән чыгарма.

— Кеше сиңа күрдем дип әйтеп тора бит. Ышансаң — ышанасың, ышанмасаң — юк, анысы инде синең эш! — дип сүзгә Булика килеп кушылды, һәм «әйдә, сайрый бирсен, комачаулама», дигән сымак, Иорам-атага күз кысты.

Бачана сүзсез генә ята бирде.

— Йә, шуннан? — дип сорады Булика түземсезләнеп.

— Ул мине терелтте, мине яңгырга әйләндереп җиргә яудырды. Шул яңгырдан соң көеп саргайган чүлләргә җан керде. Аннары мин бик зур имәнгә әйләндем, үзәнлекне яшеллеккә күмеп, яфрак ярдым, һәм кошлар, агач ботагына кунып, яшәү ямен мактап мәдхия җырладылар.

— И кодрәтле тәңрем! — дип куйды Иорам-ата үзе дә сизмәстән.

— Үз күзем белән күргәннән соң, мин дә шулай дип әйтә яздым,— диде Бачана елмаеп.

— Үз күзең белән күрә торып та шөбһәләндеңме? И әкәмәт бәндә! — дип, Иорам-ата яткан җиреннән күтәрелде.

— Төшемдә мин, аның аягына егылып, баш ордым... Ә инде соңыннан, йокыдан уянып, сезне һәм Буликаны күргәч, дөресен әйтергә кирәк, күңелгә шик керде...

— Үзегезнең тәңре каршына барганыгызны сизмисезмени? — Иорам-ата дулкынлануыннан хәтта агарынып китте.

— Беләсезме, атакай, сезнең динегез кирәгеннән артык мистикага бирелгән һәм тормыштан аерылган, чын түгел... Менә минем төшемнән күзгә күренердәй, тоеп булырдай реаль бер нәрсә калса икән...

— Гөнаһ сүз сөйлисез! Ул сезне шушы тормышка кайтарган, моннан да тоемлырак тагын ни кирәк сезгә?!

— Яңадан терелүемнең максатын күрмим. Иртәгә барсы да яңадан кабатлансын өчен генә дөньяга кире кайттыммыни мин? Иртәгә яңадан үләр өченме? Үлем барыбер котылгысыз бит!

— Ә вакыт!— дип кычкырып әйтеп куйды Иорам-ата.

— Нинди вакыт? — диде Бачана аңышып җитмичә.

— Гомер озынлыгы! Ходай-тәгалә сезнең гомерне озайткан лабаса!

— Кайчан үлсәң дә — бүгенме, иртәгәме — барыбер түгелмени?

— Сезнең үзегез өчен, бәлки, барыбердер, әмма башкалар өчен алай түгел!

— Кемнәр өчен?

— Гомерләре сезнең яшәү-яшәмәүгә бәйле кешеләр өчен!

— Анысы кечкенә нәрсә... Бик күп кешеләр япь-яшь көе үлеп киткән, әмма җирдә тереклек барыбер дәвам итә...

— Нәрсә сөйлисез сез! Ничек инде кечкенә нәрсә булсын! — дип ярсып китте Иорам-ата.— Әгәр менә Руставели бишектә чакта ук үлгән булса?

— Башкасы туар иде.

— Кайчан?

— Кайчан да булса.

— Әнә шул шул! Кайчан да булса! Әмма аңа кадәр күпме еллар үтәр иде! Әгәр даһи Руставели дөньяга килмәгән булса, шул ерак заманнардан алып, бүгенге көнгә кадәрге җәмгыятебезнең нинди булуын күз алдына китерә аласызмы сез?

— Нишләмәк кирәк, Руставелига кадәр дә яшәгәннәр бит кешеләр...

— Алласыз яшәгәннәр алар! — Иорам-ата, кувшиннан сөт эчеп, кипшенеп киткән тамагын чылатты.— Вакыт — алла дигән сүз ул! Аңлагыз шуны! Сез, коммунистлар, аллага ышанмыйсыз, шуңа күрә дә вакытның кадерен белмисез! Сез вакытны юкка әрәм итәсез! Вакытка баш иегез, кадерен белегез аның! Әгәр инде сез ниндидер яңа бер иман, яңа дин уйлап табарга җыенасыз икән, эшне иң әүвәл вакыттан башлагыз. Югыйсә бер нәрсәгә дә ирешә алмассыз, чөнки, кабатлап әйтәм, алла — вакыт ул!

— Ә бит, алла — сүз ул, дип әйтәләр иде түгелме соң?

— Сүз, гамәл һәм вакыт — аерылгысыз, бер бөтен булып берекккән өч нәрсә ул! — диде Иорам-ата йөзенә тирән хөрмәт галәмәте чыгарып.

— Алай булганда, без дә моңа кушылабыз, изге ата! Без вакытның да, гамәлнең дә, сүзнең дә кадерен беләбез һәм, әйтергә кирәк, ул яктан чиркәүдән һич тә калышмыйбыз.

— Һи-и, моңарчы әле, беләсегез килсә, кичектерелгән эшләрнең һәм аларны кичектерергә яратучыларның, сездәге сыман, болай беркайчан да күп булганы юк иде! — дип, көлеп җибәрде Иорам-ата.

— Ә-ә, юк инде, атакай, сезнең белән килешмәскә рөхсәт итегез! — дип аның сүзенә каршы төште Бачана.— Кичектерергә дигәндә сездән дә остарагы юк инде! Ходай-тәгалә бит әнә үзе дә кешегә җәннәтне кайчан вәгъдә итә? Үлгәннән соң гына! Әллә анысын оныттыгызмы?

— Ахирәттә җаның җәннәттән урын алсын өчен, шушы фани дөньяда гадел, хыянәтсез тормыш көтәргә кирәк. Башкача булуы да мөмкин түгел!

— Әйе шул, кеше үзенең хезмәт көче белән, тир түгеп яулап алган нәрсәне сез алланың рәхим-шәфкать күрсәтүе дип аңлатмакчы буласыз... Күрәләтә гаделсезлек бит бу, атакай! Сезнең динегез кешедән кирәгеннән артык зур корбаннар сорый түгелме?!

— Гөнаһ сүз сөйлисез, хөрмәтле Бачана, гөнаһ сүз! — диде Иорам, хәтере калып.— Безнең диннең төп кануны — үзеңә йолку түгел, башкаларга бирү, хакимлек итү түгел, хезмәт күрсәтү!

— Болар барсы да купшы сүзләр генә шул, атакай... Исегезгә төшерегез әле: караңгылык, дини фанатизм, догматизм, тәре походлары, инквизиторларның аяусыз каты җәзалары... һәм болар барсы да алла исеме белән, ходай-тәгалә хакына дип эшләнгән бит...

— Динебез камиллеккә җиткән дип әйтмим бит мин...— диде изге ата икеләнеп калган сыман.

— Афәрин, изге ата! — дип, Бачана шаркылдап көлеп җибәрде.— Үз гомеремдә беренче тапкыр рухани затлардан шундый сүз ишетәм. Шул рәвешле фикер йөртү ничегрәк дип атала инде сездә? Уңга тайпылыш дипме? Әллә сулгамы?

— Христиан динендә тайпылыш яисә үзәк кебек төшенчәләрнең булганы юк. Анда бары бөеклек, зенит кына бар! — диде Иорам-ата вәгазь-нәсихәт укыган сыман итеп һәм күзләрен түшәмгә текәде.

— Кайда соң ул бөеклек-зенит дигәнегез? — дип, Бачана да ирексездән түшәмгә төбәлде.

— Зенит — яктылык дигән сүз ул. Кеше, шул илаһи яктылык дөньясына аяк баскач, һәртөрле чик-киртәләрдән арынып, ирек һәм хөрлек юлына чыгачак. Әмма бу хөрлеккә кешеләрнең җаннары камилләшеп җиткәч кенә ирешеп була. Шунлыктан фаниларның ахирәткә күчүләре тәңребез катына якынлашу дип кабул ителә...— Иорам-ата, гыйбадәт кылгандай, кулларын күкрәгенә китереп кушырды.

— Соң, синең үзеңне, күгәреп каткан килеш, ни үле, ни тере хәлеңдә шушы йортка китереп ташлагач, ярдәм сорап кемнәргә ялвардың икән, хәтерләмисеңме? Ходайтәгаләгә түгел, врачларга ялвардың бит! — дип әңгәмәгә кушылды Булика.

— Әҗәлдән курку — аллаһе тәгалә катына ирешүдән туган курку ул,— дип куйды Иорам, Буликага карамыйча гына.

— Хәйләлисең бит, атакай! Бәлки әле синең инфарктың да шул куркудандыр? — дип, Булика Бачанага күз кысып куйды.

Изге ата, өтеп алырдай итеп, Буликага карап алды:

— Синең иманың, бичара җан, ашказаныңда башланып, бәдрәфтә тәмамлана. Синең ише гөнаһлы бәндәгә хәтта тәмуг капкасы да ачылмас!

— Син биргән рекомендация белән барсаң, әлбәттә ачылмас! Хәер, тәмугын да, оҗмахын да сиңа калдырам. Минем коммунизмны күрәсем килә... Анысы инде сезнең җәннәт, шулаймы, хөрмәтле Бачана? Дөрес, мин үзем партиядә тормыйм, тик шулай да мине үзегезнең канат астыгызга алырсыз дип өметләнәм...

— Рәхим ит, Булика! — диде Бачана, итекчене коммунизмга чакырып.— Без киң күңелле кешеләр, сине генә түгел, Иорам-атаны да кабул итәрбез.

— Җәннәткә охшатып ясарга маташкан ул җәмгыятегезгә үзегез генә кирәгез,— дип, изге ата чакыруны кире какты,— мин тәкъдиремдә язылганны көтеп алырмын... Сезнең зенитыгыз артык гади, гадәти... Шунысы кызык, шул коммунизм дигән җәмгыятегезгә ирешкәч, нәрсә эшләрсез икән сез?

— Барып җитик әле, аннан күз күрер.

— Әгәр күрердәй нәрсә булмаса? — дип чәнчеп алды Иорам-ата.

— Хөрмәтле Иорам, сезнең динегезгә ничә ел? — дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Бачана.

— Ике мең! — Иорам-атаның тавышы горур яңгырады.

Бачана ихлас күңелдән көлеп җибәрде:

— Ә безнекенә әле йөз дә тулмаган... Шулай булса да аның тарафдарлары исәпсез-хисапсыз, сезнең динегез андыйны төшендә дә күргәне юк. Һәм әле шул көенчә, ике меңгә җиткән башыгызга, безнең белән, йөз яшьлек үсмерләр белән булышып ятасызмы? Оялыр идегез ичмасам! Ашыкмагыз, менә безгә дә ике мең яшь тулсын әле, шул чагында сез үзегезнең зенитыгыз югарылыгыннан безгә карарсыз. Шул чагында инде кайсыбызның югарырак күтәрелүе турында хөкемен дә чыгарырбыз.

— Бу дөньяда бер генә нәрсәгә дә ышанмый торган кешеләр белән бәхәс кылуы авыр! — дип, Иорам-ата стенага таба әйләнеп ятты.

— Сезнең динегез халыкка ни бирә? — дип, үзенекен тукый бирде Бачана.

— Рухи азык! — диде Иорам-ата борылмыйча гына.— Ә сезнеке?

— Ә безнеке рухи азык та һәм матди азык та бирә. Әмма иң беренче чиратта матди яктан тәэмин итүне кайгырта. Чөнки зенитына баручы халыкка икмәк, сыйр, май, бәрәңге, помидор һәм ит кирәк. Дөресме?

— Ул ит дигәнең кайда соң әле?— дип, Иорам-ата ялт кына йөзен Бачанага таба борды.

— Монысы инде бәхәскә кагылмый, изге атакай!.. Бүген юк икән, иртәгә булыр!

— Безнең динебез, әйтергә кирәк, ит ашауны да, аны җитештерүне дә чикләми. Бу турыда әйтүе уңайсызрак, шулай да... Әүвәле, хәзергегә караганда, ит күбрәк иде бездә...

— Элек җир йөзендә ярты миллиард халык яшәгән, ә хәзер — дүрт миллиардка якын!

— Ала-а-ай... Кеше ашаудан иртәрәк туктаганбыз икән,— дип моңарчы мыштым гына яткан Булика тавыш бирде,— хәзер менә халык та азрак булыр иде, туйганчы ит тә ашар идек!

— Сезнең иманыгыз адәм балаларын менә шушындый, әхлаксызлыгын да яшерми торган циник затка әйләндерде! — дип Иорам-ата кулы белән Буликага таба ишарә ясады. Тегесе, нидер җавап бирмәкче булып, авызын ачкан иде, әмма әйтәсе сүзе ярты юлда киселеп калды: карават астыннан бөтен ыруын ияртеп күсе

килеп чыкты да бүлмәнең урта бер җиренә килеп, туктап калды.

— Менә сиңа мышьяк! — диде Булика тынлыкны бозып.

Күсене күргәч, Бачананың күңелендә җирәнүдән бигрәк кызыксыну уянды. Ана күсе, нәрсәдер эзләнгән сыман, бер-бер артлы һәр өч шкафны әйләнеп чыкты һәм, берни тапмагач, берәм-берәм авыруларны күздән кичерде. Әмма Булика бер шакмак шикәр ыргыткач, күсе шикәргә борылып та карамады.

— Һич төшенә алмыйм, ни булган боларга? — диде Иорам-ата,— әллә инде бик каты сыйланып килгән, әллә ризыктан баш тартып ач торырга карар иткәнме?

— Женяны дәшәргә кирәк. Теге дезинфектор аламасын чакырсын. Дуңгыз баласыдай симерешкән күселәрне үз күзе белән күрсен! — диде Булика.

Күсе янә шкафларны караштырып-иснәштереп чыкты да гаиләсе янына кире әйләнеп кайтты һәм алгы тәпиләрен, мыегын мәзәк кенә кыймылдатып тегеләргә нидер хәбәр итте. Ата күсе һәм ике бала аналарын зур дикъкать белән тыңлап тордылар. Аннары ана күсе, балаларны ияртеп, Буликаның караваты астына юнәлде: күрәсең, шундагы ярыктан ояларына кайтарып җибәрүе булгандыр. Шуннан соң кабат ата күсе янына әйләнеп килде һәм алар арасында шактый кызу әңгәмә башланды.

— Гаилә җәнҗалы. Андый чакта бала-чаганың читтәрәк булуы хәерле,— дип, әлеге тамашага үзенчә аңлатма бирде Булика.

Шулчакны кинәт ана күсе, нәрсәдәндер коты алынган сыман, читкә ташланды һәм шашынып бүлмә буйлап бөтерелергә тотынды. Аннары мыш-мыш сулап, ата күсе каршына килеп туктады да тораташтай катып калды. Хәзер инде бүлмә бетереп вәхшиләр биюен ата күсе башкарырга кереште. Бер минуттан ул ана күсе янына чабып килде дә, күзләрен аңа төбәп, терәлеп катты. Шул рәвешле, күселәр, бер-берсенә текәлгән килеш, кымшанмыйча байтак вакыт тынып тордылар.

Бачананың йөрәге, ниндидер бер яман хәл буласын сизенгәндәй, борчылып тибәргә тотынды... Шул вакыт каравататыннан ике күсе баласы килеп чыкты. Алар тәгәрәшеп ата-аналары янына йөгереп килделәр, әмма тегеләре балаларын, әйтерсең лә бөтенләй күрмиләр иде... Шуннан соң күсе балалары ата-аналарына борыннары белән килеп төртелделәр. Тегеләре исә кымшанып та карамады. Күсе балалары тәпиләре белән әле берсе-

нә, әле икенчесенә тәрткәләргә тотындылар. Ул да булмады, күселәр өерләре белән капылт кына урыннарыннан куптылар да шкафларга, стеналарга, бер-берсенә орыла-бәрелә, егыла-тора бүлмә буйлап томырылып чабышырга керештеләр.

— Ни булган боларга? Котырганнармы әллә?— дип Иорам-ата тәртенеп куйды.— Булика, ходай хакы өчен, Женяны дәш әле!

Ә Булика, чырае агарынган бер хәлдә, күселәрнең бу әкәмәт тамаша кылануларына шаккатып карап утыра бирде.

— Мышьяк тәэсире бу... Мышьяк ашаганнар да эчәргә су эзлиләр. Әмма су аларның үлемен тизләтәчәк кенә,— диде Бачана.

— Ә сөт?— дип сорады Иорам-ата калтыранган тавыш белән.

— Салып бирегез, атакай!— дип үтенде Бачана.

Иорам-ата, калтыранган куллары белән җамаякка сөт салып, идәнгә куйды. Ләкин инде соң иде: тәмам шашынып киткән күселәр тәлинкәгә илтифат та итмәделәр.

— Гаҗәп, балалары бирешми әле,— диде Бачана һәм шундук, аның сүзенең киресен раслагандай, күсе балаларының берсе, тәпиләрен югары күтәреп, аркан әйләнеп тә төште. Беренчесе артыннан ук икенчесе дә ауды.

— Башкача карап тора алмыйм мин боларга! — дип ыңгырашты Булика һәм, тел астына бер таблетка нитроглицерин салып, кулы белән йөзен каплады.

— Йа хода, үзең ярлыка! — дип куйды Иорам-ата үзе дә искәрмәстән.

Күселәр, ниндидер куркыныч барлыгын сизенеп, айнып киткән кебек булдылар, әүмән-тәүмән атлап, балаларының мәетләре янына килделәр дә аларның гәүдәләре катына килеп тубыкландылар.

— Женя!— дип акырып җибәрде Бачана һәм ирексездән урыныннан күтәрелде. Күселәр башларын калкыттылар, һәм Бачана аларның сәйлән бөртеге сыман түгәрәк кара күзләрендә әйтеп бетергесез сызлану-әрнү, аптырау, ачыргалану галәмәте күреп, йөрәге сыкрап, өшеп киткәндәй булды.

— Женя! — дип кычкырды ул тагын бер тапкыр һәм мендәренә авып төште.

— Хөрмәтле Бачана! Бачана! Углым! — дип каравытында бөргаланды Иорам-ата.— Булика! Күз сал әле, зинһар, ни булды аңа?!

Әмма колакларын мендәр белән томалап яткан Булика берни ишетми иде.

— Әй, кайсыгыз бар анда?! Ярдәм итегез! — дип сөрәнләп кычкырды Иорам-ата һәм урыныннан тормакчы булды, әмма йөрәгенә килеп кадалган коточкыч авырту картны урынына кире екты...

Палатада авыр тынлык урнашты. Идәндә тынсыз калган күсе гәүдәләре аунап ята, көч-хәл белән сулыш алган кешеләрнең караваты янында исә, аларның җанына комсыз күзләрен чекрәйтеп, әҗәл посып тора иде.

Дөбердәп ишек ачылганны да, палатага котлары алынган фельдшер Женя белән врачның атылып кергәнен дә берсе-бер ишетмәде.

— Йә, нәрсә, күңелегез булдымы инде? — диде Женя, җансыз күселәрне күреп. Шундук врачның хәвефле тавышы яңгырады:

— Пантопон! Хәзер үк! Өчесенә дә!

8

Ласа Басилия Тамарага Озургети [1] станциясендә килеп юлыкты. Кыз, баш астына кечерәк сумкасын салып, эскәмиядә йоклап ята иде. Ул, үзенә текәлгән күз карашын тоеп, уянып китте. Зур зәңгәр күзле, киндердәй ак йөзле, кабарынкы кызыл иренле, салам төсле сап-сары толымнарын тыгыз күкрәкләре өстенә салындырып куйган бу кызның ачлыктан интеккәнлеге күренеп тора иде. Ул җитез генә аягына торып басты. Ласа аның таза бәдәнле сылу-зифа гәүдәсен күздән кичерде дә... телсез калды...

...Шул көннән Ласа Басилиянең ашханәсендә яңа официант кыз барлыкка килде, һәм шул көннән башлап ашханәгә ашарга йөрүчеләрнең саны бермә-бер артып китте. Авыл халкының ир затыннан булган һәммәсе шунда килеп җыела да, әчеп-күпчеп беткән «изабелла» [1] шәрабын су урынына чөмерә-чөмерә, мәзәк сүз сөйләп, әңгәмә куертып утыра. Тәмам иләсләнгән ир-атны хатыннары, ата-аналары урындыкларыннан көч-хәл белән генә куптарып алып кайтып китәләр иде.

---

[1] *Озургети* — Махарадзе шәһәренең элекке исеме. Хәзер дә халык телендә еш кулланыла.

[1] *«Изабелла»* — шул исемдәге йөзем җимешеннән эшләнә торган шәраб.

— Тамара, фәрештәкәй, тагын ун шешә китер әле!

— Тамара, кем сине шундый матур итеп дөньяга тудырган, шайтан алгыры!

— Ни пычагыма ул сдачаң, синең бер күз сирпеп алуың да миллион сум тора бит!

— Тамара, бер генә елмаеп карачы, аннары — Ласайяның[1] пычагын бәгыремә батырсаң да, һич сүз әйтмәс идем!

— Ласайя, бу кызның аякларын үп син, югыйсә сасып беткән ашханәңнең эшләре бик хөрти иде!

— Үкертеп тә уңдың бит, Ласайя! Эт ите пешереп ашатсаң да утәр иде, шәт!

— Бер генә үпче мине, Тамара, аннан инде Супса[2] суына ташласаң да сүзем юк!

— Янбашларына гына күз сал әле син аның!

— Шушы гомергә тикле ничек урлап китмәделәр икән моны?!

— Хәзер, бер генә минут сабыр итегез!

— Белмим шул, егет!

— Миллион күбрәк булыр! Аның кадәр акча миңа нәрсәгә?

— Синең хатының миннән матуррак бит, егет!

— Айныгач үбәрмен!

— Мин башка берәүне яратам, кадерлем!

— Кулыңны кыскарак тот! Ласа, тый әле бу сәрхүшне!

— Ласа, ашханәне ябарга вакыт!..

Бу хәл көн дә шулай кабатлана тора иде...

Бачана, ашханәгә кереп, почмактагы өстәл артына барып утырды.

Урамда эсседә кызган җирдән бөркү пар күтәрелә, ә биредә яңа гына юылган идәннән рәхәт бер салкынлык бөркелә иде. Ласайя күренми, ул кухня ягында, кайнап утырган казаннар тирәсендә əвәрә килә, Тамара исә, Бачанага аркасы белән борылган килеш, стойка янында стаканнар сөртеп тора иде.

Бу иртәнге сәгатьтә ашханә эче буш иде. Гадәттә халык бирегә төштән соң җыела башлый. Бачана моны белә иде, шуңа күрә кешесез чакны туры китереп килде дә ул... Бачана беравык тыныч кына көтеп утырды, аннары кыюсыз гына тамак кырып куйды. Тамара, ялт

[1] *Ласайя* — Ласа исемен кечерәйтеп, шаяртып әйтүләре.

[2] *Супса* — елга исеме.

борылып, тавыш килгән якка карады, һәм Бачананың йөрәге жу-у-у итеп китте. Ул, башын иеп, йөткерергә тотынды — әмма бу юлы инде ютәле каушаудан кузгалды булса кирәк. Тамара, стойка өстеннән тәлинкә, пычак, чәнечке алып, Бачана янына килде. Бачана аның кайнар судан кызарып-кабарып киткән озынча, матур бармакларын гына күрә алды. Кыз, егетне гаҗәпсенү катыш кызыксыну белән күздән кичереп, өстәлгә тәлинкә китереп куйды. Бачананы аның беренче күрүе иде.

— Нәрсәләр китерергә сезгә? — дип сорады кыз.

Егет башын күтәрде.

— Ипи! — диде Бачана ишетелер-ишетелмәс тавыш белән һәм көчкә төкереген йотып куйды.

— Ипи генәмени?

— Аннары — сыйр.

— Ит кирәкме?

— Юк.

— Шәраб китерергәме?

— Ярамый. Иртәгә имтихан бирәсем бар.

— Нәрсәдән?

— Физикадан.

— Ә ничәнче класста син?

— Быел бетә.

— Ә-ә-ә... Харчо кирәк түгелме?

— Харчога акчам җитми.— Бачана кызарынып куйды.

Тамара китеп барды. Бераздан ул, кулына поднос тотып, кабат әйләнеп килде һәм Бачана алдына икмәк, сыйр, харчо салынган тәлинкә, бер стакан шәраб китереп куйды.

— Бер генә стакан ярый ул! — дип елмайды кыз һәм Бачананың каршысына килеп утырды.— Исемең ничек синең?

— Бачана.

— Фамилияң?

— Рамишвили.

— Ә минем исемем Тамара.

— Беләм! — Бачана стаканны кулына алды.

— Нишләп минем моңарчы сине күргәнем булмады икән?

Бачана оялып китте. Ул, күкрәк авызына килеп тыгылган йөрәген урынына утыртырга теләгәндәй, шәрабын йотып куйды.

— Минем яшьтә ашханәгә йөрмиләр әле.

— Алайса бүген ник килдең соң?

— Тамагым бик ачты, шуңа күрә килдем.— Бачана тагын бер йотып куйды.
— Әчеме? — дип сорады Тамара, борынын мәзәк кенә җыерып.
— Синең исәнлеккә! — диде Бачана һәм стаканын төбенә кадәр эчеп бетерде.— Күпме тиеш мин, исәпләче!
— Физикаңны тапшыр әле, шуннан соң исәплəрмен!
— Тамара! — дип дәштеләр шулчак кухня яктан.
— Хәзер киләм, Ласа,— дип кычкырды Тамара.— Аз гына көтеп тор! — диде ул Бачанага һәм йөгереп китеп барды.
Тамара, әйләнеп килгәч, аптырап китте — Бачана ашханәдә юк иде инде. Өстәлдәге ризыкка ул кагылып та карамаган иде.

— Исәнме!— дип сәлам бирде Тамара, өстәл янына утыра-утыра.
— Исәнме! — диде Бачана.
— Тапшырдыңмы?
— Тапшырдым.
— Йә, ничек соң?
— Өчлегә,— диде Бачана теләр-теләмәс кенә елмаеп,— анысын да әле Ломкаца бабама хөрмәт йөзеннән генә куйдылар.— Ул, кесәсеннән биш сумлык акча чыгарып, өстәл өстенә куйды.— Кичәге аш өчен.
Тамара акчага күзен дә салмады.
— Тагын ничә имтихан бирәсең калды әле?
— Тамара! Нәрсә дип шул авызыннан сөте кипмәгән малай белән маташасың һаман! Кил әле монда! — дип кычкырды шунда Дуту Центерадзе. Ул үзенең шешәдәш дүрт дусты белән ашханәнең аргы почмагында утыра һәм ярыйсы ук кәефләнеп алганга охшый иде.
Тамара аның сүзен игътибарсыз калдырды.
— Тагын ничә имтихан бирәсең бар әле?
— Бер.
— Анысы кайчан?
— Берсекөнгә.
— Ул чагында берсекөнгә кил.
— Иртәгә дә киләм әле мин.
— Ярый, кил. Ә хәзер нәрсә китерим?
— Тамара-а! Сабый бала да анасының күкрәген ташлый ала, ә син шул маңка малайдан аерыла алмыйсыңмы? — дип кычкырды Дуту яңадан.
Тамара аның янына барды.
— Нәрсә телисез?

— Синең матурлыктан башка тагын ни кирәк булсын инде миңа?! Безнең янда утырып торчы бераз!

— Вакытым юк! Кирәкле әйберегезне әйтегез!

— Тагын ун шешә китер дә яныма утыр! Синең саулыкка эчәргә телим мин! — дип, Дуту Тамараның кулыннан эләктереп алды. Тамара исә, ычкынып, стойкага таба атлады.

— Ласа, ун шешә шәраб бир әле.

Ласа шешәләрне чыгарып тезә башлады. Дуту стойка янына таба юнәлде. Аның күзләре ялтырый, шактый ук төшереп алганлыгы әллә каян сизелеп тора иде.

Дуту Центерадзе — авылның милиционеры иде. Базык гәүдәле, киң җилкәле, озын беләкле, ачык кобурасыннан наганы күренеп торган бу кеше үзен бик иркен һәм дорфа тота иде. Стойка янына килеп җитүгә, ул Тамараны кочаклап алды.

— Бәйләнмә әле син кызга, Дутуйя, бар әнә үзеңнең өстәлең янына! — диде аңа Ласа, кашларын җимереп.

— Кыз үзе каршы килмәгәндә, нәрсә дип кысыласың әле син? — дип ырылдады Дуту һәм, алты шешәне уенчык сыман гына эләктереп алып, үз урынына китте.— Дөресен генә әйткәндә, өстәлгә шәраб китерү синең вазифаң керә! — дип кычкырды ул Ласага, аннары һәммәсенә ишетелерлек итеп: — Кемнең дә булса шушы кызга бәйләнгәнен күрәсәм — үзенә үпкәләсен! Ул кешенең табутын Гавриил чиркәвенең ишегалдына үз кулларым белән илтеп куячакмын! Шуны колагыгызга киртләп куегыз! — дип хәбәр салды.

Тамара, калган дүрт шешәне алып, Дутуның өстәленә китерде. Милиционер ирексезләп аны үз янына утыртты.— Утыр, кызыкай, синең исәнлегең өчен эчәргә телим мин! — дип, Дуту кулына стаканын тотты да аягүрә торып басты һәм, Ласага мөрәҗәгать итеп, сүзен башлады: — Ласайя Басилия! Шундый гүзәлдән тәлинкә юдырырга ничек оялмыйсың син, ә? Бир әле миңа Тамараны, мин аны алтын тәхеткә менгереп утыртачакмын, миндә ул Тамар патша кебек яшәячәк!

— Нинди алтын тәхеткә ул тагын? Берсендә хатының Талико утыра түгелме соң инде? Эш турында уйлар идең бераз, җилкуар! Йортыңда ни каккан казыгың, ни утырткан сыңар агачың күренми! Төнгелеккә тавык кунакларга куначаң да юк бит!.. Егетләнеп маташкан буласың тагын!

Ашханә халкы дәррәү күтәрелеп шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ласайя, телеңне кыскарта төш, яме, югыйсә, алай-болай өстенә китереп басмагаем! — дип кисәтте аны Дуту һәм кулын револьверына салды.

Бачана урыныннан торып ишеккә юнәлде.

— Әй, тукта әле, егет! — дип эндәште аңа Дуту.— Нишләп әле син бу тирәдә буталып йөрисең, ә? Як-ягыңа күз сал әле, синең тиңнәрең бармы биредә?

— Мин ашарга кердем,— диде Бачана сабыр гына.

— Нәрсәгә кергәнеңне беләм мин! Мә, тот, эч тә өеңә ычкын! — диде Дуту, Бачанага бер стакан шәраб һәм тавык боты сузып. Бачана Дуту янына килде, аның кулыннан стакан белән ит кисәген алды да аларны кабат өстәл өстенә куйды.

— Эчмим мин.

— Алайса бар, юлыңда бул!

— Китәргәме, юкмы — анысы синең эш түгел! — Бачананың яңаклары алланып чыкты. Дуту, аны колагыннан эләктереп алмакчы булып, кулын сузган иде, ләкин Бачана тиз генә читкә тайпылып өлгерде, һәм Дутуның кулы һавада асылынып калды.— Исерек син, Центерадзе! — диде Бачана милиционерның йөзенә бәреп һәм ишеккә таба атлады.

— Кайсысының көчеге бу? — дип сорады каушап калган Дуту.

— Ломкаца Рамишвилиның оныгы ул! — дип җавап бирде аңа янәшәсендә утырган Ушанги Каландадзе. Дуту иренен тешләде.— Манучар Киквадзены юк иткән өчен синең начальнигың орден алды булса кирәк, ә бит аны атып үтергән кеше шушы егет үзе... Шулай булгач, аңа бәйләнмәвең хәерлерәк...— дип, милиционерның колагына пышылдады Каландадзе.

— Ялган сүз,— диде тешен кысып Дуту.— Ул операциядә мин үзем катнаштым! — Центерадзеның йөзе бурлаттай кызарып чыкты.— Елан баласы һәм троцкист калдыгы ул!

— Ул малайның сиңа нинди начарлыгы тиде? Йә, ашханәгә кергән ди, тамагына да ашамады әнә, үз юлы белән йөри бирсен шунда... Алай ярамый, Дуту... Хатын-кыз өчен акылдан язарга...— диде Афанасий Лория ризасызлыгын сиздереп.

— Кем ул хатын-кыз дигәнең, эттән туган нәрсә?! Хатын-кыз түгел, фәрештә ул! Каршысына тезләнеп дә башыңны и!— дип, Дуту үзенең аю табаны кадәр учы белән Афанасийның җилкәсенә шапылдатып сукты.

Афанасий чайкалып китте. Ашханә эчендә киеренке бер тынлык урнашты.

— Дутуйя, әллә син ул Тамараны заемга оттыңмы? Безнең янга да килсен әле, туйганчы бер карап калыйк хет! — дип әйтеп куйды Мамука Яшвили, әлеге дәһшәтле тынлыкны бозмакчы булып.

— Ярар, бүген тел озайтуыңны гафу итәм, ә иртәгәдән ашханәдә эзең булмасын! — дип янады аңа Центерадзе.

— Алай бик батыр булгач, сугышка китәсең калган! — дип, елмаеп җавап кайтарды Мамука.— Бәлки, шунда Гитлерның арт сабагын укытып кайтыр идең...

— Ә монда кем тәртип саклар? Синең ише дезертирларга кем күз-колак булыр?

— Минме ул дезертир? Ни гомердән бирле күкрәгемдә килосы белән снаряд кыйпылчыгы асрыйм! — Мамука изүен чишеп ташлады.— Шул хәлемдә дә син мине дезертир дип атамакчы буласыңмы?! Синме ул монда тәртип урнаштырырга җыенучы? Барып чыккан хөрәсән ялкавы һәм дезертир башың белән?! — Мамука, өстәл өстендәге шешәне эләктереп, Центерадзега таба атлады. Тегесе наганын тартып чыгарды.

Бачана ашханәдән чыгып китте.

Тамараның ашханәдә эшли башлавына өч айлап вакыт үтәргә өлгермәде, авыл буйлап төрле гайбәт тарала башлады. Яман сүз, язгы карлыгач сыман, һәр йортны, һәр ишегалдын очып әйләнде. Һәммә җирдә — чәй плантациясендә, басу-кырларда, йөзем, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларында, базарда, конторда, мунчада, парикмахерскида, китапханәдә бөтен сүз, чыш-пыш һаман да шул яшь официантка хакында гына булды.

— Ишеттеңме, өченче көн Мамука Яшвили белән Дутуйя Центерадзе теге шайтан кызы аркасында ашханәдә аздан гына бер-берсен суешмый калганнар ди...

— Теге хөрәсән Дутуйя хатынын тотып кыйнаган да Мелекедурига, атасы өенә куып җибәргән, имеш...

— Башы беткере Ласайя, каян табып алгандыр шул җен затын... Корсаклы да ди әле ул Ласайядан... Әнә ич, ни рәвешле аркылыга үсә башлады...

— Аңардан түгел лә инде, әлеге дә баягы шул Дутуйя-милиционердан ди...

— Ул кызый әле Мамука Яшвили тирәсендә дә күз уйнаткалап ярамсакланып йөргән икән дә, тегенең ха-

тыны Дареджан барып, күрмәгәнен күрсәтеп кайткан дүзенә!..

— Гитлер ни, шул кызый ни — икесе дә бер иш! Бөтен авылның астын-өскә китерделәр!..

— Бар дөнья шул өстерәлчеккә терәлеп калды микәнни соң инде?..

— Терәлеп калган инде, күрәсең! Торнике Кинцурашвили Ардалион Гваладзега пычак күтәргән ди бит әнә...

— Ул Дутуйя-милиционер нәрсә карый икән соң?

— Дутуйя үзе башлап аның белән өстерәлгәчме?!

— Һи, Дутуйя имеш, ул әле теге егетнең дә башын тәмам әйләндергән бит!

— Кайсы егетнең тагын?

— Ломкаца Рамишвилиның оныгы... Бачананың... Үсмер яшьтәге бала-чаганы аздырырга маташканы өчен генә дә төрмәгә илтеп утыртырлык бит аны... Өченче көн шул малайны ашханә янында очраткан идем — бичараның күзләре нәкъ шашкан кешенеке шикелле...

Тамара фатирга Зосим Хинтибидзеларга урнашкан иде. Ул, тәрәзәсе юл ягына караган, кечерәк кенә кырый бүлмәдә яши иде.

...Авыл тирән йокыда иде. Бачана әкрен генә тәрәзәгә чиртте. Бераздан тәрәзәдә Тамараның куркынган йөзе күренде. Бачананы күрүгә аның күзендә шелтә төсмере чагылып үтте. Кыз, иренен тешләп, гаҗәпләнүдән кулларын җәеп җибәрде, аннары сакланып кына тәрәзәне ачты да уңайсызлана калган Бачанага:

— Инде син дә килдеңмени, егет? — дип пышылдады.

— Бер генә минутка керимче! — дип ялварды Бачана.

— Минем башка син генә кирәк идең! — Тамараның тавышы калтыранып китте.

— Керт инде! — диде Бачана.

— Андый пычрак эшләрдәнераграк тор, Бачана! Бар, өеңә кайт! Ни кирәк сезгә миннән? Ник болай мәсхәрә итәсез мине? Ни гаебем бар минем? Җитәр... Бәйләнмәгез миңа...— дип Тамара елап җибәрде.

Бачана тәрәзәдән бүлмәгә керде, Тамараны әйләнеп үтеп, өстәл янына барып утырды. Кыз да, сукыр лампага ут алып, Бачана каршына килеп утырды.

— Нәрсә кирәк сиңа? — диде ул кызганыч бер тавыш белән.

Бачана дәшмәде.

— Ник килдең?

— Авылда синең турыда сөйләнгән сүзләр дөресме? — дип сорады Бачана, калтыранган кулы белән лампа филтәсенең янып күмерләнгән очын каккалап.

— Нинди сүзләр? — диде Тамара көрсенеп.

— Төрле... начар сүзләр...

— Син шуларга ышанасыңмы?

Бачана җилкәсен җыерып куйды.

— Синең янга килүем шуның өчен...

— Нәрсә өчен?..

— Синең янга мин шуның өчен дип килдем...

— Кирәкми, әйтмә!.. Бөтен авылда мин бер сине генә саф, чиста кешегә санап йөрим! Бер сүз дә әйтмә!

Бачана тамагына килеп тыгылган күз яшьләрен йотып җибәрде һәм һич көтелмәгәндә:

— Әйдә, өстеңә киен! — дип әйтеп салды.

— Нәрсә?!

— Өстеңә киен дә киттек әйдә!

— Кая?

— Белмим...

— Кая барыйм мин?

— Син авылдан китәргә тиеш!

— Шулай яман атым таралган килешме?

— Син китәргә тиеш! Чөнки алар һәрберсе сиңа хатын-кыз итеп кенә карый, ә мин...

— Ә син?

— Киен дидем бит! Кием-салымыңны, тагын нәрсәләрең бар — әйдә җыештыр да киттек! — Бачананың тавышы шундый нык, ышанычлы яңгырады, егет хәтта үз тавышын үзе танымады.

Тамара урыныннан сикереп торды, карават астыннан тиз генә чемоданын өстерәп чыгарды да, карап-нитеп тормыйча, бар булган мөлкәтен тутырырга тотынды. Бачана исә балконга чыкты һәм Зосимнарның ишеген дөбердәтә башлады.

Эчке яктан Зосимның:

— Кем бар анда? — дигән йокылы-уяулы тавышы ишетелде.

— Мин бу — Бачана, Ломкаца Рамишвили онытгы.

— Син, егет, ишекләрне бутагансың!

— Юк, Зосим абзый, бутамыйм! Чыгыгыз әле, зинһар, Маро түти, син дә чык!

— Инде эчкәнсең икән, бар, өеңә кайт! — диде Зосим ачуланып.

— Юк ла, аек мин! Бер генә минутка чыгыгызчы! — дип үтенде Бачана.

Ишек ачылып китте, бусагада эчке киемнән килеш Зосим күренде. Аның артында коты алынган Маро түти басып тора иде.

— Мин Тамараны алып китәм, Зосим абзый. Син дә, Маро түти дә белеп торыгыз дим...

— Соң, алай икән, алып китә бир... Шуның өчен кеше уятып торасыңмы? Аның миңа бер тиен бурычы юк, бүлмә өчен алдан түләп куелган, шулай булгач...

— Зосим абзый, синең берәр вакыт аның бүлмәсеннән Мамука Яшвили, яки Дутуйя Центерадзе, яисә Ласайя Басилия, йә булмаса Торнике Кинцурашвилиның чыкканын күргәнең булдымы?

— Нәрсә бәйләнәсең әле син миңа, егет, ә? Әллә мин аңа каравылга куелган дип беләсеңме?

— Юк, Зосим абзый, син намуслы кеше! Дөресен әйт миңа!

Зосим, ни әйтергә белмичә, бермәлгә сүзсез калды, баш чүмечен кашып куйды.

— Ялган сөйләр хәлем юк, улым... Берәүнең дә аның бүлмәсеннән чыгып килгәнен күргәнем булмады! Өч тапкыр, лаякыл исереп, Дутуйя Центерадзе килде, әмма күпме генә ишеген төйсә дә, ул аны кертмәде. Торнике Кинцурашвили килде ике тапкыр, ул да салмыш иде, анысы да тәртәләрен кире борды... Аның бүлмәсендә төнлә синнән гайре берәүне дә күргәнем булмады...— дип, Зосим кулына чемоданын тотып басып торган Тамараның күзләренә карады.

— Нәрсә өчен шулай мәсхәрә ягалар соң аңа?— дип сорады Бачана.

— Тамара турында, балам, безнең авыздан берәүнең дә начар сүз ишеткәне булмады! — диде Маро түти алга чыгып.— Киресенчә, без аның турында гел яхшыны гына сөйләдек, тик безнең сүзгә кайсысы гына ышанды икән?

— Киттек! — диде Бачана, Тамараның кулыннан чемоданны алып.

— Төн күзеннән кая алып китмәкче буласың син аны, балам?! Иртәнгә кадәр сабыр итсәгез, кеше төсле итеп юлга җыяр идем үзегезне...— дип, әрле-бирле йөренә башлады Маро түти.

— Сезнең яхшы сүзегездән башка аңа бүтән берни дә кирәкми! — диде Бачана, аннары: — Сау булыгыз, рәхмәт сезгә! — дип өстәде.

— Синең ниләр кылып йөргәнеңне бабаң беләмесоң? — дип сорады Зосим, Бачана инде ишегалдына чыккач.

— Белә! — дип бер сүз белән генә җавап кайтарды Бачана һәм Тамараның кулыннан җитәкләде: — Киттек!

Алар сүзсез генә бардылар да бардылар. Шоссега чыккач, Бачана чемоданын җиргә куйды һәм, юл читенә утырып, тәмәке төрде. Тамара да аның янына килеп утырды. Бераз хәл алгач, янә кузгалдылар. Икенче тукталышны Насакирали үренә менәр алдыннан ясадылар.

— Берәр сүз әйтер идең ичмасам! — дип үтенде Тамара.

Бачана, изүеннән бер төргәк чыгарып, сүзсез генә Тамараның алдына куйды.

— Нәрсә бу? — дип сорады кыз.

— Хезмәт көненә алган акчам... Алты йөз сум... Урнашып, тормышың җайланып киткәнче җитәр ул сиңа... Он сатып алырсың...— дип Бачана сүзләрен өзә-өзә әйтте.

Тамара, төргәкне чишеп, акчаларга карап алды, аннары яңадан пөхтәләп төрде дә Бачананың куенына тыкты һәм, тезләренә капланып, үкси-үкси еларга тотынды. Бачана аны юатмады, тынычландырырга да тырышмады: кызның бөтен елыйсыларын елап бетергәнен көтте. Әмма көтеп җиткерә алмады, сөйләнә башлады:

— Елап алу файдалы ул... Кайчак шулай, бер-бер җирем авырта башласа, яисә борчулардан йөрәгем таш булып катып китсә, мин дә урманга барып, агач төбенә ятам да елыйм... Сабый бала шикелле кычкырып-кычкырып елыйм... Көн буе елыйм, күз яшьләрем бетеп, бәгырьдәге таш эрегәнче... Шуннан җанга рәхәт булып китә... Ела, ела!.. Күңел өстең җиңеләйсен бераз... Югыйсә кеше үләр иде... Үпкәләмә син... Авыл халкының гаебе юк монда... Барсына да синең чибәрлегең, күз явын алырдай гүзәллегең гаепле... Ә безнең ирләр... Нишләмәк кирәк, алар, бер-берсеннән көнләшеп, чәйнәшеп беттеләр... Өч айдан бирле минем керфек какканым юк. Һаман сине уйлыйм... Кем генә соң сине шундый чибәр, шундый ягымлы карашлы итеп яратты икән?.. Һәр кешегә дә син бары тик аңа гына елмаясың, карашың белән бары аны гына иркәлисең кебек тоела... Миңа да шулай тоела иде... Әйе, мин аңлыйм, ахмаклык бу!.. Аң-

лыйм, ләкин... мин сине бик яратам, бик... Синнән башка яши алмыйм... Үләрмен кебек...

Тамара елавыннан туктады. Ул хәйран калып Бачананы тыңлый иде. Ә тегесе һаман сөйләнә бирде:

— Миңа озакламый унҗиде тула... Күп түгел түгелен, ләкин алай ук аз да түгел инде... Син миңа балачагага караган кебек карыйсың, анысын мин беләм... Син гаҗәпләнмә... Мин сине шундый нык яратам, шундый нык... Нишләргә соң миңа?.. Ә акчаларны ал син... Урлап тапкан акча түгел ул... Аны миңа бабам бирде... Синең өчен дип... Минем бабам — акыл иясе ул... Синең янга да мине бабам җибәрде, авылдан алып китәргә дә ул кушты... Әгәр дә син мине ярата алсаң икән... Тик син артык чибәр шул, киләчәктә синең белән ниләр буласын мин белмим... Сине саклап калыр, сине кайгыртыр өчен яшьрәк шул әле мин... Ә мин шундый яратам сине, шундый нык итеп... Өч ай инде йокламыйм мин, төнозын сине уйлап чыгам...

Күз яшьләре Бачананың тамагына килеп тыгылды. Ул йөзе белән Тамараның тезләре өстенә капланды да, нәкъ теге чакта, Чхакоура урманындагы кебек, адашкан бүре баласыдай, үкереп-үксеп еларга кереште.

Тамара Бачананың башын күкрәгенә кысты, һәм малай үзенең өшегән-туңган йөрәгенең әкренләп эри башлаганын, җылынуын, ут булып кыза, яна башлавын тойды. Ул Тамараны кочагына алды да шашып-ярсып аның күкрәгеннән, муеныннан, битләреннән үбәргә тотынды. Ул кызның дымсу күзләреннән килгән тоз тәмен тойды, аның дулкынланып пышылдаган тавышын ишетте:

— Син кояшым минем, шатлыгым... Туганым һәм атам минем... Кайгым-сагышым минем... Улым һәм ятимлегем минем... Тормышым һәм әҗәлем син минем... Балакаем минем һәм мәхәббәтем... Кайдан гына килеп чыктың да, кайлардан минем тормышыма килеп кердең син?

Аннары аларның иреннәре, бер-берсен табып, тынып калдылар, хәзер инде аларның йөрәкләре сөйләшә иде.

Аларның күкрәкләрендә көмеш чаң авазлары чыңлап ишетелде, шундый да тигез, бердәм һәм илаһи-мәһабәт булып чыңлый иде ул чаңнар, ирексездән ходайга рәхмәтләр укып, сәҗдә кыласы гына килә иде.

— И кодрәтле тәңре! Безнең җаныбыз, тәнебезне бер ит тә, безне бер бөтен, бик зур һәм бетмәс-төкәнмәс те-

реклек чишмәсенә әйләндер!.. И хак тәгалә, аның каның миңа бир, минем канны аңа тапшыр! Безне гөнаһтан саклап, җаннарыбызны үзеңә кабул ит!

— Бачана, кояшым минем, кайдан гына минем тормышыма килеп кердең син?.. Бәхетем һәм кайгым минем... Кирәкми, шатлыгым минем, кирәкми... Гыйффәтлемен мин...

— И кодрәтле тәңрем! Көч һәм ихтыяр бир миңа!.. Аек акылымнан мәхрүм итмә!.. Ярдәмеңнән ташлама, ходаем!..

...Бер-берсенең кулларыннан җитәкләшеп, алар олы юл буйлап атладылар. Тирә-якта урман төнге йокысыннан уяныл килә. Кошлар кояшка һәм таңга багышлап мәдхия җырларга әзерләнәләр иде. Якын-тирә авылларда этләр өреп куйгалый. Каяндыр елга аръягыннан, беренче әтәчләр тавышы белән урыныннан торып чыккан бер ирнең бакчага кергән хайваннарны сүккәне ишетелә. Әкренләп күк гөмбәзе яктыра башлады. Тау түбәләрендәге болытларга алсу төс инде. Насакиралида таң атты.

Бачана туктады да кулындагы чемоданын Тамараның аяк янына куйды.

— Моннан ары үзең генә китәсең инде! — диде ул әкрен генә.

Тамара аңа озаклап карап торды. Аннары тыныч кына:

— Алга таба ничек яшәрбез соң без? — дип сорады.

Бачана дәшмәде.

— Күршеләргә нәрсә дип әйтерсең?

Бачана җилкәсен генә җыерды.

— Бар...— диде ул көч-хәл белән телен әйләндереп.

— Онытма мине...

Бачана башын чайкады.

— Дөньяда синнән дә ныграк яраткан кешем юк минем!

— Кияүгә чыкма... Мин озакламый үсеп җитәм...— дип, сулкылдап әйтте Бачана.

Тамара аның каршысына килеп тезләнде, егетнең кулларыннан үпте.

— Моннан да ары кая үсмәкче буласың инде тагын? — дип Бачананы тезләреннән кочаклады.

Бачана саклык белән генә кызның кулларын ычкындырды, берничә адым артка чигенде һәм... кырт борылып китеп барды.

Ярты чакрымлап җир киткәч, ул артына әйләнеп карады. Тамара, аңа төбәлгән килеш, әле һаман юл буенда утыра иде.

Бачана гаҗәпләнүеннән тетрәнеп китте: ул каршысында гына искиткеч бер ачыклык белән Тамараның мөлдерәмә яшь тулы зәңгәр күзләрен күрде. Әйе, бары тик күзләрен генә күрде...

Көн үзәге җиткәндә Бачана ашханәгә килеп керде. Халык белән шыгрым бүлмә тәмәке төтененнән зәңгәрләнеп, гөж итеп тора иде. Ласа, гадәтләнгән җитез хәрәкәтләр белән, прилавка артында ялт та йолт помидоркыяр турап тора иде. Ишектә Бачана күренүгә, ул, эшеннән туктап, пычагын тоткан килеш, хәрәкәтсез калды. Ашханәдә тынлык урнашты. Кайсы шатланып, кайсы гаҗәпләнеп, кайсы куркынып Бачанага төбәлде. Барысының да йөзендә бары шул бер сорау иде. Беренче булып тынлыкны бозарга кемнең дә кыюлыгы җитмәде. Ниһаять, Ласа телгә килде:

— Менә ич ул! — дип кычкырып җибәрде Ласа һәм, җилкәсеннән йөз потлы таш төшкәндәй, җиңел сулап куйды. Ашханәгә, әйтерсең, җан өрделәр: бөтенесе берьюлы сүзгә кереште. Кинәт, шул гөрелтене күмеп, Дуту Центерадзеның мыскыллы тавышы яңгырады:

— Сәлам, ыштансыз кияү!

Бачана, милиционерга илтифат итмәстән, Торнике Кинцурашвили утырган өстәлгә таба юнәлде һәм аның каршына килеп басты.

— Кая куйдың син кызыйны? Бабаңа кайтарып бирмәгәнсеңдер бит? — Торнике кызмача иде.

— Торнике Кинцурашвили! — диде Бачана барысы да ишетерлек итеп.— Шушындагы халыкка әйтеп бир әле: Тамара бозык хатын идеме?

— Анысын инде син Ласайядан сора. Тамара бит аның өчен ястык та, түшәк тә иде! — дип шаркылдап көлде Торнике.

— Ласа абый, бу кешенең сүзе дөресме? — диде Бачана Ласага таба борылып.

— Әгәр мин әйткән сүзем, кылган эшем яисә уй-ниятем белән генә булса да кайчандыр шул кызны рәнҗеткәнмен икән, күзем иртәгә таңда чыгасы кояшны күрмәсен, менә шушы пычак йөрәгемә килеп кадалсын! — дип, Ласа кулындагы пычагын яртысына кадәр стойкага батырды.

Бачана янә Торникега таба борылды:

— Әгәр син үзеңне ир кеше дип санасаң, торып бас та әйт, Торнике Кинцурашвили: аның янында син ничә тапкыр булдың? Әйт, әйт, оялма, барыбер үзе ишетми бит!

— Тукта, мин сиңа җавап тотарга кем булдың соң әле син, маңка малай?! — дип кызып китте Торнике.

— Алайса инде сине ничә мәртәбә куып җибәргәнен әйт.

— Беркемнең дә куганы булмады мине! Айныгач үзем кайтып киттем... Әнә, Зосим биредә утыра, ышанмасаң аннан сора! — диде Кинцурашвили юашлана төшеп.

— Мамука Яшвили, мин сиңа барысына караганда да ныграк ышанам! Әйтче, зинһар, ни өчен хатының Дареджан Тамара белән сүзгә килде? — дип Бачана өстәл артында иреннәрен тешләштереп дәшмичә утырган Мамукага эндәште.

— Төрле юк-бар сүз аркасында... Дутуйя Центерадзеның хатыны, җыен гайбәт сөйләп, тәмам котыртты аны...— диде Мамука, башын күтәрмичә генә.

— Син минем хатынга тел тидермә, кабахәт җан! — дип җикерде Центерадзе.

Мамука аягына торып басты, әмма Бачана өлгеррәк булып чыкты:

— Хәзер инде әйтеп бирегез, кайсыгыз бер генә тапкыр булса да аның янында кунып чыкты? Йә, Дуту, син әйт! — диде ул.

Центерадзе урыныннан кузгалды. Ул, ашханәдә тәртип урнаштырып маташкан әрсез малайны, муен тамырына биреп, очыртып чыгарырга ниятләнгән иде, әмма Бачана милиционерның бу хәрәкәтен үзенең сүзенә җавап дип аңлады һәм, стойкада кадалып торган пычакны тартып алып, Центерадзега таба атлады:

— Күзгә терәп алдашасың син, хәсис! Өч тапкыр син аның бүлмәсенә бәреп кермәкче булдың һәм өчесендә дә сине адәм мәсхәрәсе итеп сөреп чыгардылар! Оятың качкан бушбугаз син, Дутуйя Центерадзе. Кешеләр алдында кәпәренер өчен генә бер гөнаһсыз кыз баланың исемен пычраттың! Дөрес әйтәмме мин, Зосим агай?

— Хак сүз, улым, хак сүз! — диде чыраеннан чыккан Зосим агай һәм төртенеп куйды.

— Анысын каян беләсең син, аңгыра баш! — дип, Зосимга очып кунды Центерадзе.— Минем аяктан күнитекне әллә син салдырдыңмы?

— Малайның сүзе хак, җәмәгать, ходай алдында ант итеп әйтәм! — дип кабатлады Зосим.

— Әшәке адәм син, Дутуйя Центерадзе! — диде Бачана милиционерның йөзенә бәреп. Әлеге сүзләрен гомерендә булмаганча, зур бер ышаныч, көч белән әйтте ул.

— Үтерәм мин сине, маңка малай! Кара әле син аны, нинди митинглар җыя башлаган! Кешеләргә пычрак ягып... Закон куйган власть вәкилеме мин сиңа, әллә югыйсә бер йомышчы малаймы?— дип, Центерадзе, револьверын чыгарып, Бачанага таба атлады.

— Маймыл син, Дутуйя Центерадзе, белдеңме! Синең наганыңа төкермим дә мин! — диде Бачана һәм үзе Дутуйя каршысына бара башлады.

Ласа, стойкасы артыннан йөгереп чыгып, ике арага кереп басты.

— Ул чагында менә нәрсә, җәмәгать,— дип кычкырды Бачана.— Кичә төнлә мин Тамара янында булдым! Ул безгә саф кыз бала булып килгән иде һәм саф кыз бала килеш китеп тә барды! Анам исеме белән ант итәм, хак сүз бу!..

Шулчак кинәт ашханәдә «чырк» иттереп китереп суккан тавыш яңгырады, һәм һичкем көтмәгәндә Дуту Центерадзе гөрселдәп идәнгә чалкан барып төште. Мамука Яшвили, кабарып чыккан кулын уа-уа, Бачана янына килде һәм шул ук кулы белән малайның битеннән сөеп куйды:

— Әйбәт егет син, улым! Инде бар, өеңә кайт, анын белән мин үзем сөйләшермен...

Мамука ашыкмыйча гына ишеккә таба атлады...

9

Авырый башлавының егерме икенче көнендә Бачанага профессор урынында әйләнеп ятарга рөхсәт итте. Хәзер инде Бачана, терсәгенә таянып, бер ягында ята һәм күршеләренең һәр икесен рәхәтләнеп тамаша кыла ала иде. Тагын бераздан аңа дәвалау физкультурасыннан күнегүләр билгеләделәр. Күнегү дигәннәре — ике атна дәвамында йодрыкны бер язып, бер төйнәп ятудан гыйбарәт иде. Ниһаять, Бачанага торып утырырга рөхсәт ителде. Бу хәл беренче «амнистия»дән соң егерме көн үткәч булды. Нәкъ әнә шул көнне алар бүлмәсенә һушыңны алырдай гүзәл бер кыз килеп керде. Аны күргәч, Булика хәтта кулындагы оеган сөт шешәсен төше-

реп җибәрде. Чем-кара чәчле, яшел күзле әлеге фәрештә Бачананың караваттитенә килеп утыргач исә, Иорам-ата төртенеп алды һәм ирексездән:

— Инде хәзер дә алланың барлыгына ышанмасагыз, хөрмәтле Бачана! — дип куйды.

— Әгәр бу — төштә генә булмаса, ышанырга туры килер, атакай! — диде Бачана, кызның чибәрлегенә һәм кыюлыгына исе китеп.

— Төш булса булсын, тик минем яныма гына килеп утырсын иде ул! — дип куйды Булика һәм бары шунда гына кашыгы әле һаман авызында икәнлеген абайлап алды.

— Сезнең янга да килермен! — диде кыз бу сүзгә каршы.

— Көтәм сезне, хөрмәтлем, көтәм! — дип чакырды Булика.

— Исәнмесез, иптәшләр! Минем исемем — Кетеван, фамилиям — Андроникашвили. Мин шушы сез яткан больницада дәвалау физкультурасы буенча баш инструктор булам,— дип таныштырды кыз.

— Шулаймыни? Нәрсә уйлый икән соң бу врачлар? Ни пычагыма дип безгә әллә нинди пантопоннар, персантиннар, интенсаиннар биреп җәфалыйлар икән?! Шушындый чибәр ханымның, палатага кереп, бер әйләнеп чыгуы да ун булмаса биш уколга торырлык бит югыйсә! — диде Булика.

Кыз, күңеле булып, елмаеп куйды.

— Хөрмәтле Бачана! Күрәсезме, елмая бит! Зинһар, орынып карагыз әле үзенә! Әгәр шунда юкка чыкмаса, моның өн икәнлегенә чынлап торып ышаныр идем! — дип үтенде Булика.

— Рөхсәт итсәгез! — диде Бачана һәм кызның матур бармакларына кагылды.— Сөен, Булика, тере зат ул!— дип Буликага җавап бирде Бачана, әмма кулын кире алырга ашыкмады. Кыз җайлап кына Бачананың учыннан кулын ычкындырды да аның пульсын санарга керешге.— О, бу минутта минем пульс сезгә бер генә дә юньле хәбәр әйтә алмас!.. Аңа тынычланырга ирек бирегез...— дип, Бачана кызның кулын үзенең йөрәк турысына китерде.— Ишетәсезме, ничек тибә?

Баш инструктор Бачананың күкрәгеннән кулын алды һәм диңгез кабырчыгы сыман кечкенә генә матур алсу колагын аның йөрәк турысына куйды.

Бачананың тыны кысылды.

— Доктор, сез мине бөтенләй үтерергә җыенмыйсыз-

дыр бит? — дип пышылдады ул һәм, ярдәм эзләгәндәй, Иорам-атага инәлүле караш ташлады. Тегесе, берничек тә ярдәм итә алмыйм дигәндәй, чарасызлыктан кулларын җәеп җибәрде дә күзен йомды...

Берәр минуттан кыз тураеп басты һәм җитди итеп:

— Йөрәк турысы авыртамы әле? — дип сорады.

— Авыртуы басылган иде югыйсә, сез килгәнче пульс та тигез иде, хәзер менә барсы да яңабаштан кабатлана,— дип көрсенде Бачана.

— И аллам! Әллә биредә авыруларның барсына да бер үк сүзләр язылган кәгазь таратып чыкканнармы соң?

— Нәрсә, башкалар да шул ук сүзне әйтәмени? — диде Бачана бердән сүрелеп.

— Әйе шул менә! Инде сезгә, язучы кешегә, бераз оригинальрәк булганда да зыян итмәс иде! — дип төрттереп куйды кыз.

— Кая инде ул оригинальлек...— дип мескенләнде Бачана.— Күрәсезме, мәет кенә бит мин хәзер, ә шул көенчә дә сезнең белән сөйләшеп ятам әле...

Кыз кычкырып көлеп җибәрде:

— Әйе, менә монысы чыннан да бик кызык! Йә, ярый, инде эшкә тотыныйк! — диде ул һәм җайлап кына Бачанага урыныннан күтәрелергә булышты.— Сезнең хатха-йога турында ишеткәнегез бармы?

Көтелмәгән бу сораудан Бачана аптырап китте.

— Яшь чакта нәрсәдер укыганым бар иде... Ул... һиндләрнең фәлсәфи-дини тәгълиматы бугай?.. Махсус физик күнегүләр ярдәмендә алар җан белән тәннең камиллегенә ирешәләр... Шулай түгелме?..

— Әйе, дөрес! — дип килеште баш инструктор.— Хәзергә без хатха-йоганың иң гади күнегүләрен үзләштерергә тырышырбыз, ә җан камиллеге турында инде, моннан чыккач, үзегез кайгыртырсыз...

— Тыңлыйм һәм буйсынам! — дип, Бачана күндәм бер кыяфәт белән башын иде.

— «Лотос»ның нәрсә икәнен беләсезме? Һич югы, ишеткәнегез бармы? Әйтик, аякларын бөгәрләп утырган Будданы күргәнегез бардыр дип беләм? Әнә шулай утыру рәвеше «лотос» дип атала.

— Аңлашылды...

— Әйдәгез әле, эшләп карыйк! — Кыз җиңнәрен сызганып куйды һәм Бачананың өстендәге одеялын ачып ташлады. Бачана, нишләргә белмичә, куллары белән ярымшәрә гәүдәсен каплаштырырга тотынды. Кыз исә, берни булмагандай, сүзен дәвам итте: — Димәк, менә

болай: уң табанны тотабыз да сул аякның бот турысына китерәбез...— Бачана күндәм бер кыяфәт белән врач кушканнарны эшләде һәм кинәт кенә, үзенең ни дәрәҗәдә ябыкканлыгын аңлап, хәйран калды: чөнки элгәре ул, үтерәм дисәләр дә, мондый хәрәкәтне ясый алмаган булыр иде. Аның ничектер күңеле күтәрелеп китте, бөтен барлыгын әлегәчә таныш булмаган җиңеллек, иркенлек биләп алды.

— Бик яхшы! — дип мактады кыз.— Ә хәзер сул табанны тотабыз да, бөкләнгән уң аяк астыннан үткәреп, бот турысына... нишләтәбез?

— Китерәбе-е-ез! — дип дәвам итте Бачана тыңлаучан беренче класс баласы сыман һәм әйтелгән хәрәкәтне кабатламакчы булды. Ләкин анысы бик җиңел түгел икән! Сул табан, каядыр ярты юлга җиткәч, туктап калды, чәнчеп-чәнчеп бавыр авыртырга тотынды, Бачана үзе исә шабыр тиргә батты.

— Үзегезне ирексезләмәгез!— дип кисәтте кыз.— Барып чыкмый икән, әүвәлге хәлегезгә кайтыгыз.

Бачана, шуны гына көткәндәй, аякларын сузып җибәрде, җиңеләеп сулыш алды.

— Нәрсә, авыртамы?

— Авырта!

— Зыян юк, акрынлап күнегерсез,— дип тынычландырды аны кыз,— ә хәзер урыныгызга ятыгыз дә тәнегезне йомшатыгыз!

Бачана мендәренә ауды. Инструктор кыз аның мускулларын капшап карады һәм ризасызлык белән башын чайкап куйды:

— Гәүдәгезне йомшатыгыз, йомшатыгыз! Киеренкелегегезне бетерегез! Мәет рәвешенә керегез!

— Нәрсә сөйлисез сез, кадерлем! Аны болай да көчхәл белән генә тергезделәр, ә сез кабат мәет рәвешенә кайтармакчы буласыз! — дип әйтә калды Булика.

— Һиндстан, хатха-йога дигәнегез, кызым, әлбәттә яхшы нәрсәләр, тик шулай да сезнең христианнарга хас булган башка күнегүләрегез юкмы соң? — дип сүзгә Иорам-ата да катышты.

— Христиан күнегүләре дигәнегез — гыйбадәт кылу ул, ә кешене гыйбадәт кылдырып кына аякка бастырып булмый,— диде кыз, кәефе китеп.

— Ә менә бу нишләп физкультура булмасын ди! Карагыз әле! — дип, Булика, саллы-саллы селтәнеп, әле уң, әле сул кулы белән рәттән берничә кат чукынып куйды.— Нәкъ иртәнге зарядка бит!

— Син денсезне ходай тотсын дип каргар идем инде, тик болай да үз аягың белән тәмугка кереп барасың! — диде аңа чын ачу белән Иорам-ата һәм стенага таба әйләнеп ятты.

Кыз Буликаның караваты янына килде.

Булика:

— Рәхим итегез! — дип, караватының икенче башынарак елыша төшеп, янәшәсеннән урын күрсәтте.

— Юк, юк, утырып тормыйм...— Кыз, Буликаның кулыннан тотып, йөрәк тибешен тикшерде.— Сезнең пульс яхшырак... Йә, ничек, күнегүләр ясап карыйбызмы?

— Беләсезме, доктор, сез хөрмәтле Бачананы мәет рәвешенә кертеп азапланган чакта мин әлеге күнегүләрне ясап карадым инде... Ләкин минем барып чыкмады... Шулай булгач, мин аякларымны бөкләп утыра алмаячакмын... Ә инде минә сез, матур колагыгызны куеп, минем йөрәкне тыңламасагыз, мин һичбер икеләнүсез иреезне үтерәм дә төрмәгә кереп утырам. Анысы лотоска караганда мөгаен җиңелрәктер!

— Мондый палатаны беренче күрүем! Бирегә авыру кешеләр түгел, ниндидер тел бистәләре җыелган! Иртәгә үземнең урынга фельдшерны җибәрермен, физик күнегүләрне сезгә ул ясатыр!

— Зинһар, китә генә күрмәгез, мин, аяк бөкләп утыру түгел, кызган табага да утырырга риза! — диде Булика, әмма баш инструктор, ишекне шапылдатып ябып, палатадан чыгып китте.

Булика авыр сулап куйды:

— Терек зат дигән булалар тагын...

— Барсы да төш кенә булып чыкты шул...— дип өстәде Бачана.

— Ул хатынның күзләрендә иблис сурәте шәүләләнә иде! — дип, моңарчы сүзсез яткан Иорам-ата кинәт кенә Бачана белән Буликага таба борылды.— Валлаһи дип әйтәм: аның күзләрендә иблисләр биешә иде! — диде ул һәм янә стенага таба әйләнеп ятты.

Баш инструктор чыгып киткәннән соң биш минут чамасы үткә, кулына подносын тотып, фельшер хатын Женя килеп керде. Поднос өстендәге кардай ак мамык эченнән ялтырап өч шприц күренеп тора иде.

— Кардиологик сәлам! — диде Женя, өстәлгә подносын куя-куя.

— Грузиянең йөрәк кардиограммасына бездән сәлам! — дип җавап бирде Булика.

— Әйбәт хәбәрләр алып килдеңме, Женя? Күзләрең очкынланып яна бүген! — диде аңа Бачана.

— Искиткеч хәлләр!— дип, Женя халат кесәсеннән чыгып торган гәзитенә сугып куйды.

— Кая әле, кая, чүлдә интегүче дәрвишләрнең сусыннары кансын әле! — Иорам-ата, кулларын җәеп, Женяга таба сузылды.

— Сабыр, сабыр, башта укол кадыйбыз, аннары — дөнья хәлләре! — диде Женя катгый итеп.— Йәле, әзерләнегез!

Өчесе дә, дәррәү корсакларына әйләнеп, одеялларын кайтарып ташладылар. Женя Бачанадан башлады...

— Бөтерелмә өстә, кара козгын,
Мин бирелмәм синең хөкемгә...

дип, Бачана, укол кадаган җирен ышкый-ышкый, такмаклап куйды.

— Хөрмәтле Женя, ул энәне шулай төбенә кадәр батырырга кирәкмени соң? — диде Иорам-ата, күзенә бәреп чыккан яшь бөртекләрен мендәр почмагына сөртеп.

— Гафу итегез, чамалап бетермәгәнмен,— дип уңайсызланды Женя.

— Алла бәндәсе, нигә соң нәкъ менә миңа ясаганда гына чама хисен югалтасың икән син? Әллә сиңа бүлмәдә миннән башка да динсез-дәһриләр азмы?

— Сабырлык һәм түземлелек кирәк,— дип, Иорам-атаны тынычландырды Женя һәм Булика янына килде.

— Әүвәл энәңне күрсәт! — дип еламсырады тегесе.

— Менә, кара!

— Җәмәгать! — дип чыелдап җибәрде Булика.— Әгәр шушы нәрсә энә дип атала икән, ул чагында без дигәннәре ни нәрсә?!

— Булды, җитте, көннең көнендә синең белән сатулашып ардым инде. Ят диләр сиңа!— дип тавышын күтәрә төште Женя.

— Шулай булмыйча соң, сиңа нәрсә — синеке авыртмый бит! Үзең ятып кара әле менә! Нишләрсең икән! Әйдә, әйдә, ят әле менә үзең!

— Хәзер, яттым ди менә, көтеп тор!..

— Сиңа үч итеп тынымны да чыгармаячакмын! — дип телләшә бирде Булика һәм тешләре белән мендәренә ябышты. Женя, сөңге кадаган сыман, энәсен батырды.

— Беттеме?— дип сорады Булика, Женя укол кадаган төшне сөртә башлауга.

— Бетте!

— Бу кадәр дә ахмак булырмын икән! Нәрсәгә шуны медицина юлыннан гына китмәгәнмендер?! Башкалардан кай җирем ким югыйсә? — дип ыңгыраша бирде Булика.

Женя ишеккә таба юнәлде.

— Ә сенсация дигәнең кайда соң? — дип кычкырды аның артыннан Иорам-ата.

Женя изге атаның караватына гәзитне ташлады. Тегесе аны шундук эләктереп алды да күзлеген эзләргә тотынды. Түземлеге төкәнгән Бачана аңа үз күзлеген ыргытты:

— Минеке дә плюс өчле. Укыгыз, изге атакай.

— Менә рәхмәт! — Иорам гәзитнең соңгы битен әйләндерде. — Һм-м, безнең «Динамо» «Арарат»ка оттырган!

— Шул да булдымы сенсация?! — дип кулын селтәде Булика.— Безнекеләр оттырыр дип мин алдан ук уйлаган идем аны!

— Хисап нинди? — дип сорады Бачана.

— Икегә — ноль! — диде Иорам-ата күзлеген салача.

— Бу «Арарат» мине тәмам акылдан яздыра инде!— Булика чәпелдәтеп маңгаена сугып алды.— Алар ел буе шул безне җиңәр өчен генә әзерләнәләр дә инде! Башкаларга оттыру аларга бер тиен дә тормый!

— Безнекеләр дә «Арарат» белән мандражсыз уйный алмыйлар ансы,— дип әйтеп куйды Иорам-ата.

— Афәрин, изге-ата! Ул сүзне кайдан беләсез сез?— диде Бачана исе китеп.

— Без барчабыз адәм балалары,
Һәм яраткан безне киң җиһан... —

дип Николоз Бараташвили[1] ярдәме белән Иорам-ата үзенең сүзләрен ныгытып куйды.

— Әгәр минем иркемдә булса, мин үзебезнең бер команданы бары тик Тбилиси әрмәннәреннән генә җыяр идем... Беләсезме, нинди асыл егетләр алар?! «Арарат»ка күрмәгәнне күрсәтерләр иде...— дип хыялга бирелде Булика.

---

[1] *Николоз Бараташвили (1817—1845)*— күренекле грузин шагыйре.

— Изге ата, башка битләргә дә күз салыгызчы. Югыйсә футбол нинди сенсация булсын инде? — дип үтенде Бачана.

Иорам гәзитен җәеп җибәрде, караштыра-караштыра беренче биткә җитте дә кинәт тынсыз калды.

— Булмас, ышанмыйм! — диде ул тавышын күтәреп һәм күзлеге-ние белән бергә гәзитне Бачанага ташлады.

— Нәрсәгә ышанмыйсыз? — дип сорады Бачана күзлеген кия-кия, ләкин шул ук минутта ирексездән үзе дә:— Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел!— дип куйды.

— Нәрсәнең булуы мөмкин түгел? Сугыш чыкмагандыр бит? — диде Булика куркынган тавыш белән.

— Небиеридзены эшеннән алганнар!— диде Бачана гәзитенә кадалган килеш.

— Небиеридзены? Соң теге ни...— Гаҗәпләнүдән Буликаның күзе шакмак булды.

— Шул үзе инде...

— Ва-а-а...— Тәмам аптырашка калган Булика башын чайкап куйды.— Менә хәзер аның кешеләре боз өстендәге балет сыман шуа башлый инде...

Бачана, укып бетереп, гәзитне читкә алып куйды:

— Дөресен әйткәндә, андый нәрсә уема да кермәгән иде...— диде ул уйчанланып.

— Кара әле син аны... Әле кичә генә ул утыра иде... Гел көтмәгәндә... Башыма сыйдыра алмыйм! Ышанырлык түгел! — диде Иорам-ата.

— Карагыз әле, эшеннән алганнармы аны, әллә азат иткәннәрме? — дип кызыксына калды Булика.

Иорам-ата җилкәсен җыерып куйды:

— Гогилашвили, алсалар да, төшерсәләр дә барыбер түгелмени? Иң мөһиме бит аның шул: кичә бар иде кеше, ә бүген инде кеше юк!

— Ничек инде барыбер булсын! — дип, Булика изге атага таба борылды.— Менә, мәсәлән, азат итү нәрсә дигән сүз ул? Димәк ки, әлеге кешенең тормышы чамасыз авыр, димәк, аңа көн күрсәтмиләр... Шуннан соң инде кайсы да булса берәрсе әлеге кешене бәладан йолып ала, аны азат итә... Мисалга менә Африканы алыйк... Аның халкы җәбер-золым күрә, димәк, аларны азат итәргә кирәк!.. Инде килеп, эшеннән алу нәрсә дигән сүз? Димәк ки, берәү креслосында бик җайлап, бик нык утыра, һәм аны, һич көтмәгәндә-уйламаганда, ниндидер бер болтны яисә кадакны суырып чыгаргандай, шул утыргычыннан йолкып алалар. Аңлашылдымы?

— Монда «азат ителде» дип язылган,— диде Бачана.

— Димәк, аңа бик авырга туры килгән. Шуннан тотканнар да азат иткәннәр үзен.

— ...Һәм аның эше прокуратурага тапшырылган...— дип өстәде Бачана.

Булика аптырап китте:

— Ә монысы нәрсә өчен тагын?

— Ришвәтчелек, хезмәт урыныннан үз кирәгенә файдаланучыларга, кода-кодагыйлык, агай-энелек мөнәсәбәтләренә юл куйган өчен, хезмәт ияләренең үтенечләренә ваемсыз булганы өчен.

— Тукта әле, тукта әле, шушыларның барсы өчен дә гаеп бер Небиеридзе өстенә генә төшәме?

— Хәзергә шулайрак килеп чыга...

— Егет икән бу Небиеридзе! Эшләп тә күрсәткән ичмасам! Ә башкалар нәрсә карап торды икән соң, анысы язылмаганмы?

— Ә син үзең кая карадың соң? — дип Иорам-ата Буликаның сүзен бүлдерде.

— Син миннән сорыйсыңмы?— дип гаҗәпләнде Булика.

— Әйе, нәкъ менә сиңа әйтүем! Син — эшче сыйныф! Кемдер берәү шуның ише бихисап яман эшләр кылганда син кайда идең, нәрсәләр уйлап йөрдең?

— Политик яктан чи надан, томана бер кеше икәнсең син, атакай! Беренчедән, мин эшче сыйныф түгел, вак һөнәрче, кустарь, ә икенчедән, минем үз мәшәкатем дә үземә бик җиткән — мин сезнең, Небиеридзеның алгы бүлмәсендә таптана-таптана, тетелеп-таланып беткән аяк савытларыгызны төзәттем!

— Синең бу сүзләрең миңа берничек тә кагылмый,— дип җаваплылыкны үз өстеннән төшерде Иорам.— Небиеридзе бит ул сезнең хөкемдарыгыз, ә минем, ходайга шөкер, үзем табынган мөбарәк затым бар!

— Җыен түрә балаларын чукындырып, акча сугып ятучы син түгелме соң? Анысына ничек, катнашың бармы?

— Тинтәк тә кеше инде син, Гогилашвили! Анысы бит аның ходай кушкан изге эш! Хәлемнән килсә, мин, коммунистларның барчасын чукындырып бетереп, теге дөньяда җабраилнең янәшәсеннән урын алыр идем!

— Ярый, хуш, фани дөнья мәшәкатьләре сезгә кагылмасын да ди... Ә менә сез, хөрмәтле Бачана? Сез кайда идегез, нәрсә карадыгыз? — дип, Булика атаканың юнәлешен язучыга күчерде.

— Кем инде ул без? — дип, аңламаганга салышты Бачана.

— Сез инде, сез, язучылар!

— Безме? Без... Кайда идек дисезме?..— Бачананың кинәт кенә зиһене томаланып киткәндәй булды. «Кара әле, без, чыннан да, шулай кул кушырып кына утырдык микәнни соң?» — дип уйлап куйды ул күңеленнән һәм, җанын юатырдай бер фикергә дә килә алмыйча, көрсенеп: — Без, хөрмәтле Булика, синең белән янәшә шул кыршылып-тузып беткән аяк киемнәрен ямаштырып утырдык,— диде.

— Менә, ичмасам, дөресен әйттең,— дип куанды Булика.— Хәзер инде шунысын да әйт: нәрсә эшләтәчәкләр аны?

— Мөгаен, җәзасын бирерләрдер...

— Нәрсә өчен?

— Нәрсә өчен икәнен әйттем бит инде...

— Димәк, ул, бернәрсә белмәсә дә, бернәрсә аңламаса да, җитәкче урында утырган булып чыгамыни?

— Шулай булып чыга, күрәсең...

— Шулай булып чыгамы, әллә дөрестән дә шулаймы? — дип, сагыз булып ябышты Булика.

— Дөрестән дә шулай!

— Ә хәзер инде минем сүзгә колак салыгыз. Әгәр барсы да газетада язылганча хак сүз икән, әлеге Небиеридзены бүләкләп, рәхмәтләр укып, зур пенсия билгеләп, битләреннән үбеп, кулларын кысып, исән-имин генә озатырга кирәк!

— Нинди хезмәтләре өчен әле? — дип ихлас күңелдән гаҗәпләнде Бачана.

— Ничек инде ул «нинди хезмәтләре өчен?» — дип, Булика караватында торып утырды.— Әйтик, менә сез, хөрмәтле Бачана Рамишвили, язучы, редактор кеше. Имеш, сез төньякның да, көньякның да кай тарафта икәнлеген белмисез һәм, гомумән, үз гомерегездә диңгезне дә, пароходны да күргәнегез юк ди... Һәм менә бервакыт сезне чакыртып алалар да: «Иптәш Рамишвили, менә сезгә пароход, менә аның экипажы, пассажирлары, бар булган мал-мөлкәте, калган вак-төяге. Сезне капитан итеп билгелибез! Пароходны кабул итеп алыгыз да Одессадан Архангельскига илтеп җиткерегез»,— дип әмер бирәләр. Шуннан сез сәфәргә чыгып китәсез... Бер көн йөзәсез, ике көн, өч көн... Пароход әүмән-тәүмән чайкала, халык бер борттан икенче бортка тәгәрәп йөри, кайсыларыныңдыр инде күңеле болгана,

укшыта... Ниһаять, азаплана торгач, ярым җимерек пароходыгызда Архангельскига килеп җиттегез ди... Хәзер инде шундый сорауга җавап бирегез: сез, диңгез эшендә әлефне таяк дип тә белмәгән кеше, алай да пароходны батырмый-нитми тиешле урынга китереп җиткердегез ди. Шулай булгач, хезмәтегез өчен бүләккә лаек түгелмени сез? Минемчә, бик тә лаек! — дип, үз соравына үзе җавап бирде Булика.

Бачана пырхылдап көлеп җибәрде.

— Атакай, сора әле үзеннән: нәрсәдән көлә ул?— дип Иорамга эндәште Булика.

— Сүзең хак синең, Булика, хак! Әмма бит синең ул томанаң, үзен капитан итеп билгеләгәндә, ул өлкәдә пычагымны да белмәвен әйтергә тиеш иде!

— Ә бәлки, ул әйтеп тә карагандыр, тик аның сүзенә колак салмаганнардыр. Әйдә, ал үз кулыңа, ярдәмебездән ташламабыз, дигәннәрдер... Шуннан тегесе алынган инде... Аннан соң бит әле шунысы да бар: капитан постын тәкъдим итеп торганда ризалашмый калуы бик җиңел дип уйлыйсыңмы әллә? Өстәвенә, синнән алда эшләп киткән кешене дә Нельсон дип әйтеп булмасын ди... Нәрсә, әллә сездә, язучылар арасында, андый хәлләр очрамыймы? — диде Булика, Бачанага таба борылып.

— Кызганычка каршы, булгалый шул, һәм еш кына,— дип ризалашты тегесе.

— Шуннан нәрсә килеп чыга соң инде?

— Шуннанмы? Һәр кеше үз урынында, үз эшен башкарырга тиеш булып чыга. Рәхмәт төшкере Руставели:

Һәр адәмнең үз язмышы, тәкъдир аңа булышсын,
Эш кешесе эштә янсын, яуда булсын сугышчы,—

дип юкка гына әйтмәгәндер,— диде Иорам-ата йөзенә тирән олылау галәмәте биреп.

— Хөрмәтле Иорам, сакал-мыегыгызны кырдырыгыз да безнең иманны кабул итегез әле,— дип шаярткан булды Бачана,— сездән бер дигән коммунист чыгар иде!

— Сезнең иманны? Коммунизмныймы? — диде рухани коты алынып.— Ходай-тәгаләне юкка санап, фани дөнья рәхәте белән юанып яшәргәме? Юк инде, зинһар, мине андый юлга өндәп маташмагыз!..

— Ала-а-ай... Карагыз әле, изге ата, минем аңлавымча, сез коммунизмның нәрсә икәнен бөтенләй белмисез икән бит! Коммунизм, әле генә сез Руставели сүзләре белән әйткән нәрсә инде ул! Коммунизм — кеше-

лекнең рәхәт-имин тормышка ирешүе, һәркемгә, сәләтенә карап, хәл кадәренчә, үзе яраткан эш белән шөгыльләнү өчен бөтен мөмкинлек туу дигән сүз ул. Җанына ятышлы әлеге хезмәт кешегә әхлак ягыннан да, рухи яктан да чын мәгънәсендә канәгатьләнү бирәчәк!.. Без, коммунистларга, сезнең инҗил китабыгыз таныш. Сез дә безнең китапка күз салсагыз, ходаегыз белән ант итәм, һич зыян итмәс иде. Ә инде матди якны, сез әйтмешли, корсак ягын кайгыртуга килгәндә исә... Нишләмәк кирәк... Сез хаклы! Әйе, без ул турыда кайгыртабыз һәм киләчәктә дә кайгыртачакбыз! Иң беренче чиратта, кешенең бөтен матди кирәк-ярагы җитеш, мул булырга тиеш. Шул чагында гына ул үзенең уй-фикерләрен, рухи көчен, бар сәләт-омтылышларын тамак туйдыру өчен түгел, ә бәлки күп өлеш мөһимрәк булган, бөегрәк, күркәмрәк максатларга юнәлдерәчәк! Без, бер-береңне уздырырга тырышып, ярышу, көнчелек, кан кою өчен түгел, җир йөзендә иректе хезмәт һәм тынычлык тамыр җәйсен дип тырышабыз. Ә моның өчен, изге атакай, иң элек халыкның тамагы тук булу шарт!.. Безнең тәгълиматыбыз, динебез әнә шундый! Безнең тәңребез дә әнә шундый тормышчан һәм реаль, күкләргә ашкан ниндидер бер зат түгел! — дип сүзен тәгәлләде Бачана һәм, дулкынлануын сиздермәскә тырышып стенага таба әйләнеп ятты.

Ничектер бердән басынкыланып, юашланып калган Иорам-ата исә бәхәсне дәвам итәргә кыймады.

— Ярар соң, сүзләрегез ходайга барып ирешсен, хөрмәтле Бачана! — дип әйтеп куйды ул әкрен генә һәм, Бачана сыман, стенага таба борылды. Ләкин, түземлеге җитеп, озаклап ята алмады: — Сүз җаеннан әйтим, сездән дә ярыйсы гына рухани чыгар иде! — дип өстәде.

Кичен, бер олау ризык төяп, Булика янына хатыны Света килде. Ул ачык чырай белән бүлмәдәгеләргә сәлам бирде һәм, алып килгән күчтәнәчләреннән һәркайсына өлеш чыгарганнан соң, одеял почмагын кайтарды да тыйнак кына итеп Буликаның аяк очына барып утырды.

— Ни хәлең бар, газизем? — дип сорады ул, сөенеченнән, горурланудан авызын җыеп ала алмаган иреннән.

— Кәефме? Арсланныкы кебек! — диде Булика һәм, әлеге сүзләрен раслап, хатыны китергән тавыкның бер ботын каерып чыгарды да умырып тешләп алды, аннары,

күз ачып йомган арада, кимерелгән сөякне хатынына кире сузды.

Тегесе, коты алынып:

— Тончыгырсың, гадәтсез! — дип куйды.

— Тыныч бул! — диде Булика һәм тавыкның икенче ботын йолкып алды да авызын тутырып чәйни-чәйни: — Йә, ничек, шәпме минем хатын, хөрмәтле Бачана? — дип сорады.

— Менә дигән!

— Әрмән хатыннары арасында тагын берәр шундый гүзәлне күргәнегез булдымы?

— Туры килмәде...

— Шулай булмыйча соң, дөньяда бер генә бит ул!

Иорам-ата астыртын гына көлгән сыман:

— Әлбәттә инде! Син дә бит безнең дөньяга килмәгән бер чибәр...— дип елмайды.

— Менә сез минем сөяркәне күрсәгез иде! Менә ул чыннан да чибәрләрнең чибәре инде! — дип Булика хатынына карап күз кысты.

— Тел бистәсе...— дип, чыраен сытты хатын.

— Балалар кайда соң әле? Аталарының хәлен белергә ник килмәде алар? — диде Булика ниндидер бер ясалма кырыслык белән.

— Кайда булсыннар инде, Автандилҗан! Бүген шимбә көн бит, Нестан — инглиз теленнән, Тариэл — фортепианодан дәрес алырга китте.

Булика, яман да кәпәренеп, шапырынырга тотынды:

— Минем кыз, хөрмәтле Бачана, тышкы эшләр министрыннан бер дә ким түгел! Әрмәнчә сөйләшәме? Сөйләшә! — дип, бармагын бөгеп санап китте Булика,— грузинча сөйләшәме? Әлбәттә сөйләшә! Инглиз телен өйрәнәме? Өйрәнә! Мәктәптә француз теле кирәме? Кирә! Җитмәсә әле урам себерүче Физуланың кызы Гванца аны көрд теленә өйрәтеп маташа... Хәзер менә шуны әйтегез инде: безнең министрларыбыздан кайсысы биш телдә сөйләшә? Йә, әйтегез әле, изге ата!

— Кызың әйбәт синең, аллаһе тәгалә сәламәтлек бирсен үзенә!

— Ә улым? Анысы инде — коеп куйган Паганини!

— Паганини скрипкада уйнаган, газизем, ә безнең малай — пианинода,— дип төзәтте аны Света, иренең наданлыгыннан оялып.

— Акыл сатма миңа! Кемнең нәрсәдә уйнаганын үзем дә беләм! Паганини — минем өчен идеал ул, иң камил дәрәҗә! Аңлашылдымы? Тотармын да малайны

скрипкага күчермен менә! Нәрсә өчен түләсәң дә барыбер түгелмени? Нәрсә әйтерсең син шуңа?

— Ихтыярың, газизем, җаның ничек тели! Тик, алла хакы өчен дим, борчыла гына күрмә, яме!.. Профессор атна эчендә сине аякка бастырам, ә киләсе атнада инде өйгә кайтарырга да мөмкин булыр, тик безнең сүзне генә тыңласын, диде.

— Әллә мине тыңламый дисеңме? Бар биргән даруларын эчеп барам, һаман укол кадап торалар... Менә карa әле,— Булика җәлт кенә өстендәге одеялын кайтарып ташлады,— нәрсәгә әйләндереп бетерделәр алар минем...

Света коелып төште:

— Ябын өстеңә, әдәпсез! — диде ул иренә, аннары бүлмәдәгеләргә таба борылды.— Өйдә дә шулай тәрбиясезләнә ул, ходай хакы өчен гафу итегез инде...

— Гафу үтенерлек нәрсә юк монда, барыбыз да шул хәлдә! — дип, тынычландырмакчы булды аны Бачана.

— Беләсең килсә, кадерле хатынкаем, профессор сизми генә: мин күптән йөрим бит инде! — диде Булика һәм, шәрә аякларын караваттан салындырып, идәнгә торып басты, аннары, кукраеп, берничә кат бүлмә буйлап әйләнеп килде.— Йә, тагын нәрсә эшләп күрсәтим икән? — Ул як-ягына каранды.— Йәле, Света, торып бас әле!

Хатыны сәерсенеп кенә урыныннан күтәрелде. Булика аны биленнән кочаклап алды.

— Юләрләнмә! Күтәрәсе булма! Хәзер үк җибәр аны! — дип кычкырды Иорам-ата, әмма инде соң иде: Булика җилтерәтеп хатынын күтәрде дә чупылдатып муеныннан үпте. Света, мондый көтелмәгән хәлдән каушап, кычкырып җибәрде, оялуыннан яңаклары янып чыкты. Булика тагын берничә тапкыр хатынын һавага чөйде дә ниһаять аягына бастырды.

— Менә, күрдегезме инде? — диде ул кәефе килеп.— Света, киемнәремне алып кил, иртәгә үк китәм мин моннан! Урын өстендә күпме аунарга мөмкин?

Булика койка читенә килеп кунаклады. Аның сулышы күкрәгенә капкан, тик шулай да йөзе кояштай балкый иде.

— Нәрсә эшләдең син, ахмак! — диде Иорам-ата ачу белән. Булика шундук пульсын санарга кереште һәм, хәтәр җитди кыяфәт белән берәр минут чамасы сүзсез торганнан соң, канәгатьләнеп авызын ерып җибәрде:

— Булды! Бетте минем инфаркт! Яшәсен тормыш!— диде ул, хатынын кочып.

— Очынма инде! Бераз кешеләрдән оялыр иден! — Света, иренең кочагыннан ычкынып, чәчләрен төзәткәләргә тотынды.

Иорам белән Бачана, әдәп саклап, читкә борылдылар.

— Әллә авыраеп киткәнсең инде? Нәрсәдән икән ул, ә? Кара аны! — дип, Булика, кашларын җыерып, хатынына бармак янады, ләкин шундук шаяртып аңа күз кысты.

— И аллам! Ничек телең әйләнә дә, ничек колакларым түзә икән минем! — Тәмам каушап төшкән хатын кулларын җәеп җибәрде. Булика исә шаркылдап көлде дә бүлмәдәшләренә аваз салды:

— Инде борылыгыз, әфәнделәр, комедия тәмамланды!

10

Кояш үзенең көмештәй агарып балкыган иркен түшәгендә үлеп ята. Аның аллы-гөлле салават күпере белән уралган башы мәңгелек карлы Казбек тавы битендә тынып калган, куллары исә, хәлсезләнеп, түбән таба салынып төшкән.

Кояшның сулышы гаҗәеп дәрәҗәдә авырлашкан.

Кояш дөнья белән бәхилләшеп ята иде.

Бачана, Иорам-ата һәм Булика, үлеп баручы кояш каршында тезләнгән килеш, аңа кулларын сузып, ялварырга керештеләр:

— Ташлап китмә безне, Кояш! Зинһар үлмә, илаһи Кояш!

Аларның күз яшьләре, шау күбекле елга булып, шаулап-күкрәп, Кавкасиони тау бите буйлап түбәнгә, сөттәй ак томанга чорналган иңкүлеккә таба ага иде.

Ә кояш, баш очындагы кешеләрнең илереп-илереп ялваруларына колак салып, әүвәлгечә үзенең көмештәй агарып балкыган иркен түшәгендә тавыш-тынсыз ята бирде. Иртәнге якта ул Кавкасиони тавы өстенә күтәрелде һәм, иксез-чиксез зәңгәр күккә ашмакчы булып, омтылып-талпынып куйды, әмма шул вакыт күкрәгенең кинәт каты итеп чәнчүен тоеп, башта бер тезенә, аннары икенчесенә тезләнде һәм, бердән хәлсезләнеп, Казбек тавы битенә сыенган килеш, хәрәкәтсез калды.

Галәм халкы, коты алынып, үлем газаплары кичерүче Кояшка төбәлде. Урам-күперләр, басу-кырлар һәм юллар, балконнар һәм түбә кыеклары халык белән тулды. Ботакларга менеп кунаклаган бала-чага авырлыгыннан агач башлары түбән иелде.

— Ташлап китмә безне, Кояш!— дип ыңгырашты кешелек дөньясы.

Әмма халыкның аһ-зары үлеп баручы Кояшка ирешми иде инде. Ул бары үзенә таба сузылган кулларны һәм котлары алынудан зур булып ачылган күзләрне генә күрә иде.

— Нәрсәгә шулай хәвефләнә алар? — дип пышылдады Кояш.

— Алар, инәлеп-ялварып, синең ташлап китмәвеңне үтенәләр! — диде Бачана үкси-үкси.

— Соң шул инде...— дип әйтеп куйды Кояш һәм, аның бер күзе йомылды.

— Харап итмә безне, тереклек бирүчебез! — диде Иорам-ата, башын җиргә орып.

— Нәрсә борчый сине, кай җирең авырта? Әйтче безгә шуны, җиһанга нур сибүчебез! — дип өзгәләнде Бачана.

— Җирнең сыкранулары тынгы бирми миңа, җирнең сыкранулары! — диде Кояш.

— Ләкин бит җирнең сызланулары да, тереклеге дә синең кулда! — дип, талпынып куйды Иорам-ата.

— Җир — минем йөрәгем ул. Миндә бары ул гына яшн, бары тик ул гына сулыш ала. Башка бөтен күзәнәкләрем, бөтен әгъзаларым инде күптән сүнеп, үлделәр... Сез, миңа табынучы кешеләр, шуны бер дә күрми, сизмисезмени соң?

— Җисемең нидән гыйбарәт соң синең, Кояш? — дип гаҗәпсенде Бачана.

— Мин — мәхәббәт юлында корбан булганнарның утлы-ялкынлы рухы... Сөюдә җанын фида иткәннәрнең рухыннан көч алам мин... Инде менә хәзер сүнәр сәгатем җитеп килә, чөнки җирдә мәхәббәт кизләүләре кибеп-корып бетте, чөнки җирдә сөю газапларыннан үлүгә караганда, бер-берсен күралмыйча, зәһәрлектән үлгән кешеләр күбрәк хәзер... Мәхәббәтне тергезегез, шул чагында мин дә яңадан туармын... Ялынып-ялварып сорыйм сездән, кешеләр, адәм балаларының мәхәббәте белән тергезелгән тереклек китерегез миңа!.. Югалган сөю хисләрен кайтарыгыз миңа, шул чагында мин дә сезнең янга кабат әйләнеп кайтырмын!..

Кояшның сулыш алуы ешайды, һәм ул бәргәләнә-сукалана башлады.

— И Кояш! Ташлап китмә безне, мәрхәмәт ит! Моннан ары без бер-беребезне яратырбыз, үлемебезне мәхәббәткә бағларбыз!.. Без — Автандил, Иорам-ата һәм мин — синең исемеңнән мәхәббәтне сиңа кире кайтаруларын үтенеп, җирдә яшәүче барча кешеләрдән гозерләп сорарбыз! Кешелек дөньясы синең бу өндәвеңә илтифатсыз калмас, үч-нәфрәтне онытып, дөньяда кабат мәхәббәтне тергезер — минем моңа иманым камил. Тик син безгә шул мәхәббәт орлыкларын гына бир һәм изге теләктә бул! — дип инәлде Бачана.

Шунда Кояш үзенең кайнар учы белән аның маңгаена орынды, һәм Бачана, Кояш җылысы белән бергә, үзенең җанына нindидер чиксез мәхәббәт, рәхим-шәфкать иңгәнен тойды. Аннары Кояш калтыранып китте, соңгы тапкыр киерелеп-сузылып алды да... бөтенләйгә сүнде.

Шулчак Булика әле суынып өлгермәгән Кояшның күкрәгенә килеп капланды һәм такмаклый-такмаклый еларга керешге:

— Үзең белән алып кит мине дә, Кояш! Синсез яши алмыйм мин! Мәхәббәт билгесе итеп үз куеныңа кабул ит мине! Ялынып-ялварып сорыйм синнән, Кояш!

Ул да булмады, котлары алынган Иорам-ата белән Бачананың күз алдында Булика, үлгән Кояшның күкрәгендә эреп бетте дә Кояш белән бергә, салават күпере балкышына кушылды.

...Тәңребез Гайса пигамбәрнең туарына егерме гасыр кала һәм ул пәйда булганнан соң тагын егерме гасыр дәвамында Бачана белән Иорам-ата җиһан буйлап әлеге сүнгән Кояшны күтәреп йөрделәр. Алар, ятимләнеп-бушап калган күк йөзенә Кояшны кайтармакчы, караңгылыкка чумган шыксыз җиргә яктылык иңдермәкче булып, бер-берсен яратырга, бер-берсенә карата рәхим-шәфкать күрсәтергә өндәп, галәм халкы алдында күзләреннән кайнар яшь коя-коя ялвардылар. Тынып калган халык, яланбаш килеш, илаһи затлар зиратына, соңгы юлга үзенең гомерен — Кояшны озатты, чөнки җирдә Кояшка лаек башка урын табылмады... Бачана белән Иорам-ата, ниһаять, билгеләнгән урынга килеп җиттеләр һәм Кояшны кардай ак болытлардан ясалган төргәгә иңдергән чакта, кинәт караңгы күк йөзендә берсе гаҗәеп зур, икенчесе беренчесенең күләгәсендә шәүләләнеп кенә күренгән бик кечкенә, тәлинкә сыман ике кара түгәрәк барлыкка килде. Үз Кояшыннан мәхрүм

булган кешелек дөньясы, исе китеп, шул ике тапка текәлде. Әлеге түгәрәкләрнең берсе — дөньядан киткән Кояш шәүләсе булып, кечерәге — Кояшның күкрәгенә ятып, мәхәббәтеннән эреп юкка чыккан Булика иде. Аларны танытач, Бачана үксеп-үксеп еларга тотынды.

Ул бар тавышына:

— Туганнар, бер-берегезне яратыгыз! — дип кычкырды да бозланып каткан җиргә йөзтүбән ауды...

...Шул хәлендә күпме яткандыр, Бачана анысын хәтерләми. Әмма шулай бар нәрсәдән хәбәрсез булып ятканда ул үзенә гаҗәеп тә якын, таныш бер җылы агымның сизелер-сизелмәс кенә кагылып үткәнен тойды һәм, чалкан әйләнеп, яшь пәрдәсе томалаган күзләрен күккә төбәде. Анда баягы зур түгәрәк эленеп тора иде, әмма хәзер инде ул кызыл бакыр төсенә кергән. Түгәрәк торган саен кыза, яктыра барды. Теге кечкенә түгәрәк тә әкренләп кызара бара иде. Бераздан, зур түгәрәкнең яктылыгы соң дәрәҗәгә җитеп, ул кабат күк йөзендә балкып торган Кояшка әйләнгәч, түгәрәкнең икенче, кечкенәсе, метеор сыман түбән атылып, җиргә томырылды.

Җир йөзендә көн туды. Кавкасиони тавы башында Кояш балкый иде. Элеккегә караганда чырайсызрак, зәгыйфьрәк күренсә дә, әүвәлгечә шат һәм бәхетле иде ул. Кояш иркен итеп сулыш ала, Кояш яши иде.

— Дан сиңа, мәхәббәт Кояшы! Дан сиңа, тереклек! — дип, Кояшка мәдхия юллады Бачана... Үзе исә әле көлә, әле елый иде.

— Бачана!.. Хөрмәтле Бачана!.. Уяныгыз, зинһар! — дип, куркуга калган Иорам-ата Бачананы селкетә иде.

Бачана йокысыннан айнып китте, әмма үзенең кайда икәнен, ни булганын аңышып бетә алмыйча, берәр минут чамасы әле күзләрен иләсләндереп һаман урынында ята бирде. Бераздан, тәмам исенә килгәч, ул караватында торып утырды. Йөрәге еш-еш тибә иде. Кояш инде чыккан булса да, бүлмә эче әле һаман ярым караңгы иде.

— Нәрсә булды сезгә, хөрмәтле Бачана? Чабуына ут капкан кеше шикелле төнозын чәбәләнеп чыктыгыз. Әле шаркылдап көләсез, әле үкси-үкси елыйсыз... яман төш күрдегезме әллә?

Бачана, күзләрен уып, ахмак бер кыяфәт белән елмаеп куйды. Иорам-ата үзенең караватына барып ятты.

— Шундый төш күрдем мин, хөрмәтле Иорам, хәтта Коперник та көнләшер иде миннән...

— Алай искитәрлек нәрсә күрдегез соң?
— Кояшның вафатын!
— Нәрсә?! — Иорам-ата үз колагына үзе ышанмый торды.
— Төшемдә, имеш, Кояш үлде... Шунда, зар елап, беләсезме кемнәр яшь түкте?
— Кемнәр?
— Сез, мин һәм Булика... Өчебез генә идек...
Иорам-ата Бачананың сөйләгәнен сәгать буе бүлдермичә тыңлады. Бачана Кояш әйткән сүзләрне кабатлаганда гына ул ихлас күңелдән, тырышып-тырышып төртенә башлый иде. Хикәят тәмам булгач, Иорам, баш астына кулын салып, уйчан карашын түшәмгә текәде.
Шулай байтак вакыт сүзсез ятканнан соң, рухани:
— Изге төш кергән сезгә, хөрмәтле Бачана! — диде.
— Икенче тапкыр инде!— дип ризалашты Бачана.
Бүлмәдә янә тынлык урнашты. Кинәт Иорам-ата җәһәт кенә сикереп урыныннан торды да, аяк очларына гына басып, Буликаның караваты янына килде. Әллә ничек агарынып киткән Булика, күзләрен ачып, тыныч кына ята иде.
— Автандил! — дип эндәште Иорам-ата акрын гына.
Бачана сәерсенеп куйды: Булика үзен Автандил дип атамауларын үтенгәннән бирле, аларның аңа алай эндәшкәннәре юк иде. Нишләп әле нәкъ менә хәзер изге ата шулай дип эндәшә икән?
— Автандил! — дип кабатлады Иорам катырак итеп.
— Уятмагыз, йокласын бераз... Мин аңа кабат сөйләрмен,— диде Бачана.
— Автандил! — Иорам-ата Буликаны селкетеп куйды.
— Бигрәк каты йоклый инде! — диде Бачана.
— Әйе, каты йоклый... Сез дә йоклагыз! Стенага таба борылып ятыгыз да йоклагыз!
— Нинди йокы инде ул хәзер!
— Әйләнеп ятыгыз да хәзер үк йоклагыз диләр сезгә! — дип боерды рухани һәм калтыранган кулы белән сакланып кына Буликаның җансыз йөзен маңгаеннан иягенә таба сыпырып төште.
— Иорам-атакай, ни булды? — дип сорады Бачана кинәт үзгәргән тавыш белән. Ниндидер хәвеф якынлашуын сизенеп, аның чигәләре кыса башлады.
— Төшегез рас килде... Кояш вафат булды!..
Иорам-ата барып палата ишеген ачты...
Бачана башыннан одеялына бөркәнде, йөзе белән

мендәренә капланды һәм, тамагына килеп утырган әче төерне йотар өчен, тешләре белән мендәренә ябышты.

Буликаның гәүдәсен палатадан алып чыгып киткәч:

— Гаҗәп, үлгән кешенең ачык күзләре тәрәзәсе ябылмый калган ташландык йортны хәтерләтә икән,— дип сөйләнеп куйды Иорам-ата.

11

Кәефләнеп алган бер төркем Верэ[1] егетләре Меликишвили урамындагы аптека каршында нәрсә турындадыр кызып-кызып сүз көрәштерәләр иде.

Бәхәс кавказлыларның яраткан ризыгы хашидан башланып китте. Егетләрнең Цицка атлысы, хаши — кешелек дөньясының баш төзәтү өлкәсендә эзләп тапкан иң бөек казанышы, дип исбатлый иде. Аның фикерен Кока белән Коплик та куәтләде. Копака исә, моның иң яхшы дәвасы — каты итеп пешерелгән шикәрсез чәй, диде. Бачана «боржоми»ны, Бердзена «набеглави»[2]ны алга куйды, ә Датико коньяк белән аспирин тарафдары булып чыкты. Рәсми төстә тавышка куеп санаганнан соң, бәхәсләшүчеләрнең һәркайсы үз фикерендә калуга карамастан, җиңүче дип Цицка табылды. Хәер, егетләр арасында баш төзәтүнең иң яхшы чарасы — күкертле мунча инде ул, дип санаучылар булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Әмма алар тавыш бирүдә катнашмадылар. Абсолют күпчелекне тәшкил иткәнлектән, әлеге төркем үз фикерен конкурссыз гына уздырды. Хәер, алар бәхәстә болай да катнаша алмаган булырлар иде, чөнки үз гадәтләренә тугрылык саклап, бу егетләр хәзерге вакытта күкертле мунчада сихәтләнеп, хәл алып яталар иде.

Шуннан соң бәхәс шәраблар мәсьәләсенә күчте, тик монысы озакка сузылмады — беренче урын бертавыштан иң яхшы дип табылган сигезенче номерлы кахетин шәрабына бирелде. Аннан инде, сүз үзеннән-үзе политика мәсьәләсенә күчеп китте. Монда алай тиз генә бердәм фикергә килә алмадылар, шулай да, бәхәсләшә торгач, бүгенге көннең исән политик эшлеклеләренә һәм гаскәр башлыкларына түбәндәге лаеклы үз урыннары тәкъдим ителде:

---

[1] *Верэ* — Тбилисидәге бер районның элекке исеме.
[2] *«Боржоми», «набеглави»* — минераль су исемнәре.

1. Сталин
2. Черчилль
3. Эйзенхауэр
4. Де Голль
5. Жуков

Дөрес, биредә Жуков белән беррәттән Монтгомери исеме дә телгә алынды, ләкин ике тавыш кимрәк җыйганлыктан, Британия фельдмаршалына алтынчы урын белән канәгатьләнергә туры килде.

Политика мәсьәләләреннән соң чират футболга житте. Монысында инде эшләр шактый җайлырак китте. Спортчы буларак та, әхлак ягыннан да Верэ яшьләренең таләпләренә туры килә торган, бөтен дөньяда бердәнбер лаеклы кеше табылды: ул — Борис Пайчадзе[1] иде.

Сүз иярә сүз чыгып, егетләр сәнгать мәсьәләләренә дә кагылып үттеләр. Бу өлкәдә, һәрвакыттагыча, Бердзенаның абруе өстен чыкты: беренчелек таҗы Шота Руставели белән Микеланджелога бирелде, Бердзена аны тикмәгә генә яратып-иркәләп Микело дип атамый иде шул.

...Бәхәс кылучылар яныннан, аларның гөнаһлы җаннарын иләсләндереп, керосин сатучы Аполлон Кавжарадзеның кызы — аккош муенлы, төз, зифа буйлы Гуранда үтеп киткәч, бәхәс кинәт генетика, нәсел дәвамлылыгы мәсьәләләренә кереп китте.

— Менә, нәселдән килә дигән нәрсәне кире кагып кара инде син!— диде Цицка сокланып.— Коеп куйган җәйран бит! Ә балалары аның нинди булачак!

— Нәселдән килә, имеш!.. Мине дә әнә шулай ашатып-эчертсәң, киендерсәң, дөньяда бер чибәр булыр идем!— дип, Коплик кулындагы тәмәке төпчеген хәйран оста чиртеп, туп-туры чүп савытына озатты.

— Әйе-е-е, кызы, сүз дә юк, бер дигән! Нәселле нәрсә!— диде Бердзена, әңгәмәнең төп темасына кайтып.— Тик шунысы гына начаррак: керосин исе килә аңардан...

— Ничек итеп сезне югары уку йортына кабул иткәннәрдер?!. Бу кадәр дә томана булырсыз икән! Геннар, нәсел, раса дигән нәрсәләрнең буш сүз икәнен белмисезмени әле һаман? Кешеләрнең һәммәсе дә бер, тигез, ә инде аларның төрлечә формалашуы тормыш шартларыннан һәм тәрбиядән килә! Гитлерның башына

[1] *Борис Пайчадзе* — озак вакытлар Тбилиси «Динамо»сын житәкләгән танылган футболчы.

да нәкъ әнә шул расачылык теориясе җитүен онытмагыз, нинди дер чибәр Гуранда аркасында кабат әлеге теориягә әйләнеп кайтмакчы булдыгызмы?— диде Кока үгет-нәсихәт укыгандай итеп.

— Һәм кем сүзен кабатлыйсың инде син? Князь Әмиреджибиныкын[1] түгелме? Оялыр иден, Кока!— дип, Цицка исе киткән кебек башын чайкап куйды.

— Төкерәм мин синең Әмиреджибиыңа! Мин материалистмын!

— Материалист түгел, шарафист[2] син! Белдеңме?!— диде Цицка һәм Коканың кулыннан папиросын тартып алды.

— Нәрсә әле сез җыен тузга язмаганны лыгырдыйсыз?— дип кабынып китте шунда Бачана.— Мин үземнең этиемә, этием үзенең этисенә, бабам исә үзенең бабасына охшаган икән, геннар булмыйча, нәрсә дияр идегез тагын моны?! Шушы нәрсә үзе генә дә минем нәселле булуым турында сөйләмимени?

— Сөйли сөйләвен, тик нинди нәселлекне күз алдында тотасың бит...— дип кеткелдәде Копака.

Кемне-кемне, тик менә Копаканың[3] үзен нәселсезлектә һич кенә дә гаепләрлек түгел иде. Копака Грузия тарихы китабында сурәте төшерелгән Георгий Саакадзега[4] ике тамчы су кебек охшаш иде. Әзмәвердәй киң җилкәле, борын тишекләре гарәп чапкыныныкы сыман киерелеп торган, зур күзле бу егеткә кул сугышларында Верэдан алып Навтлугига[5] кадәр тиң юк иде.

— Геннарны инкяр итү, иң беренче чиратта, нәсел яклары сыеграк булган кешеләр өчен файдалы!— дип әйтеп куйды Цицка.

— Димәк, сезнеңчә, Коплик белән мин нәселсез булып чыгабызмыни инде? Шулай дип әйтәсегез киләме?— дип үпкәли калды Кока.

— Син нәрсә, тилебәрән орлыгы ашадыңмы әллә? Әле генә бит үзең раса, геннар, нәсел — барсы да юк сүз дип гәп куертып маташтың, инде хәзер үзең безгә гаеп атасыңмы?— дип кычкырды аңа Копака.

---

[1] *Әмиреджиби* — борынгы грузин князьләренең нәселе.
[2] *Шарафист (шәһәр халкы телендә)* — эчәргә яратучы.
[3] *Копаки (грузинча)*— овчарка.
[4] *Георгий Саакадзе, Бөек Моурави (якынча 1580—1629)*— Грузиянең политик эшлеклесе, танылган полководец.
[5] *Навтлуги* — Тбилисидәге бер районның элекке исеме.

— Ярар, туктатыгыз бу базарны! Әнә профессор Имедашвили килә, хәзер аннан сорыйбыз!— дип бәхәсчеләрне тынычландырды Бердзена.

— Ә сорауны кайсыбыз бирә?— дип кызыксынды Коплик.

— Копака, әлбәттә. Арабызда иң нәселле заттан ул бит!— дип чәнчеп куйды Бачана.

— Нишләп мин? Әнә, Бердзена сорасын!— дип кырт кисте Копака.

— Юк, юк! Ул бәхеттән мин Цицка файдасына баш тартам!— дип үз кандидатурасын читкә какты Бердзена.— Шунысын да искә алыйк, аның тырыш студент икәне дә кыяфәтеннән үк күренеп тора!

— Ярый соң, мин каршы түгел!— дип, Цицка төркемнән аерылды һәм, култык астына кара портфелен кыстырып, ашыкмый гына атлап килгән профессорны көтеп тора башлады.

Профессор исә, егетләргә бөтенләй игътибар итмәстән, яннарыннан үтеп китте. Цицка, аның юлына аркылы төшеп, түбәнчелек белән сәлам бирде:

— Исәнмесез, хөрмәтле профессор!

— Исәнмесез,— дип җавап бирде тегесе.

— Гафу итегез, хөрмәтле профессор... Безнең монда бер мәсьәлә буенча бәхәс чыкты да... шул турыда сезнең фикерне беләсебез килгән иде...

— Ничек ул алай... Менә шушында, урам уртасындамы?— Профессор, аптырабрак, як-ягына карангалап алды, күзлеген төзәтеп киде.

— Менә бирегә рәхим итегез!— дип, Цицка, профессорны култыклап алып, егетләргә таба атлады. Тегеләр исә, ихтирам белән читкәрәк тайпылышып, профессорга кубалакланган стена буеннан урын бирделәр.

— Тыңлыйм сезне!— дип, профессор кара портфелен бер кулыннан икенчесенә күчереп куйды.

— Эш менә нәрсәдә, Эквтимэ Николаевич,— дип сүз башлады Коплик,— без монда геннарның, нәселдән килү дигән нәрсәнең булу-булмавы турында бәхәсләшеп киткән идек. Менә Цицка әйтә...

— Кем?— дип кайтарып сорады профессор.

— Цицка!

— Нәрсә дигән сүз соң ул?

— Цицка — менә бу егет инде!— дип, Коплик иптәшенең җилкәсенә кулын салды.— Давид исемле ул, без аны Цицка дип йөртәбез.

— Ярый, аңлашылды. Нә, нәрсә дип әйтә инде Цицка?

— Алар, Копака белән икесе...

— Ә Копака кем?

— Минә монысы!

— Ничек, паспортта да шулай Копака дип язылганмы?

— Юк, паспорт буенча Тенгиз ул!— дип җавап бирде Бердзена.

— Ә монысы кем?— дип сорады профессор.

— Монысы — Бердзена!

— Грекмыни [1] ул?

— Юк, гурияле [2]!

— Ничек дидегез?

— Грузин.

— Аның исеме ничек?

— Мераб.

— Ә сезнеке?

— Коплик.

— Йа хода, ниһаять, адәм рәтле бер исем ишеттем!.. Шулай итеп, йә, ни йомыш, Коплик?

— Әйттем бит инде... Менә алар табигатьтә геннар, нәселдән килү дигән төшенчә бар дип бәхәсләшәләр, ә Кока белән мин...

— Әһә, әле Кока да бармыни? Су салынганымы, әллә бушымы? [3] — дип кызыксынды профессор һәм үз сүзеннән үзе көлеп җибәрде. Егетләр дә елмаештылар,— профессорның күңелен күтәрә алуларына бик канәгать иде алар.

— Димәк, Кока белән сез икегез расалар һәм геннар юк сүз дип барасыз, шулаймы?

— Шулай!— дип баш какты Коплик.

— Сез хаклы! Расачалык теориясе фәнгә нигезләнмәгән, реакцион тәгълимат. Фашистлар теориясе ул. Ә инде нәселдән бирелү, терек организмнарның үсеш үзгәрешен өйрәнүче генетика фәненә килгәндә исә, эшләр башкачарак...

— Гафу итегез, профессор,— дип бүлдерде аны Бердзена,— ә менә нәселле хайваннар турында ни әйтерсез? Менә, мәсәлән, атларның яңа токымнарын китереп чыгаралар бит. Әнә безнең Александровск бакчасында ях-

---

[1] *Бердзени (грузинча)* — грек.

[2] ***Гурия*** — **Грузиянең бер өлкәсе.**

[3] Сүз уйнату: «кока» грузинча — «кувшин», «чүлмәк» дигән сүз.

шы нәселле этләр өчен махсус күргәзмә-ярышлар үткәреләә, аларны хәтта алтын медальләр белән бүләклиләр!

— Исемегез ничек әле сезнең?

— Мераб!

— Беләсезме, кадерле Бердзена, хайваннар дөньясында гасырлар буена дәвам иткән табигый сайланыш нәтиҗәсендә...

— Кеше дә шул ук иҗтимагый бер үсеш баскычындагы хайван түгелмени?— дип бүлдерде аны Цицка.— Авыл хуҗалыгында сайлап үрчетү, төрле токымнарны кушу юлы белән терлекләрнең яңа нәсел төрләрен китереп чыгармыйбызмыни?

— Дуслар, нәрсә соң әле сез радио сыман борөзлексез сөйлисез дә сөйлисез, ә тыңлый белмисез!— дип, кулларын җәйде профессор һәм портфелен җиргә төшереп җибәрде.

Моңарчы сүзсез торган Бачана, ялт кына иелеп, портфельне алды да, профессорның култык астына кыстырып, тыйнаклылык белән:

— Без сезне тыңлыйбыз, хөрмәтле профессор,— диде.

— Ә-ә... сезнең исемегез ничек?

— Бачана.

— Менә нәрсә, кадерле дусларым Бачана, Кока, Коплик, Бердзена, Цицка һәм Копака! Мондый сорауларны алай урамда аяк өсте генә хәл итеп булмастыр... Иң яхшысы — сез минем янга, биш белән алты арасында кафедрага, яисә кичке уннан таң атканчыга кадәр өйгә рәхим итегез, шунда күңелегез булганчы гәпләшербез. Йә, ничек, сез ризамы?— дип сорады профессор каушап калган егетләрдән.

— Мөмкин булса, без өегезгә килер идек,— диде Бачана.

— Бик әйбәт!

— Безне кертерләрме соң?— диде Коплик, аягындагы ботинкасына күз салып.

— Әлбәттә! Тик сез Верэ егетләре килде дип әйтергә генә онытмагыз.

— Сау булыгыз, хөрмәтле профессор!— дип хушлашты Цицка.

— Сәламәт булыгыз!— дип, профессор фетр эшләпәсен чак кына күтәрә төште дә үз юлы белән китеп барды. Егетләр ихтирам белән башларын иеп калдылар.

— Профессор димәссең, бигрәк әйбәт кеше!— дип әйтеп куйды Цицка, әлеге сөйләшүгә йомгак ясагандай.

— Егетләр, тиле Марго килә!— диде шулчак Бердзена, тавышын күтәрә төшеп.

Базар ягыннан, Меликишвили урамының сул кырыеннан, күңелле генә җыр көйләп, кулларын бутый-бутый, Верэ районының мәшһүр тилесе Марго килә иде:

Диңгездән пароход бара
Ерак-ерак илләргә.
Бүләк алып кайтыр миңа —
Марго дигән чибәргә!..

Вакыт-вакыт ул:

— Хабарда[1]! Верэ Маргосы килә!— дип кычкыргалап куя да кабат үзенең җырын дәвам итә:

Сезнең белән биермен мин
Лезгинка да, танго да.
Килегез бер, күз салыгыз
Сылу, чибәр Маргога...

Марго исерек иде. Маргоны белүче узгынчылар аңа елмаеп сәлам бирәләр дә кызганып артыннан карап калалар, аннары, башларын чайкап, юлларын дәвам итәләр. Таныш булмаган кешеләр исә, әлеге исерек һәм акылы бигүк тулы булмаган хатын белән очрашасы килмичә, ашыга-ашыга тротуардан урам уртасына чыгалар иде.

Егетләр турысына җиткәч, Марго, үбү ишарәсе ясап, кулларын иренен китерде дә ике канат шикелле як-якка җәеп җибәрде:

— Верэ егетләренә сәрхүш Марго үзенең сәламен юллый!

— Сәлам, Марго!— диеште егетләр, кулларын югары чөеп.

— Йә, нәрсә, җанкисәкләрем, тагын башыгыз авыртамы, тагын кесәгездә акча урынына тычкан тизәге генәме? Килегез яныма, бәгырькәйләрем, килегез, җанкисәкләрем, әйдәгез Танц-Геурккa төшик, сыра белән сыйлармын үзегезне!— дип, Марго изүеннән берничә утызлык чыгарды да баш очында болгап алды.— Килегез, оялмагыз! Барыбер иртәгә үк мине сыйлыйсыгыз була бит!

— Марго, кадерлем, бар өеңә кайт, ял ит...— дип үтенде Копака.— Без эчтек инде.

---

[1] *Шәһәр халкы телендә «Юл бирегез!», «Читкә китегез!» дигәнне аңлата.*

— Чибәр егеткәй, кайсы тарафларга барып, кайларга гына салыйм бу газиз башкаемны?! Ал мине үзеңә! Акылдан язган тиле Маргога нәкъ менә шушындый хуҗа кирәк! Синнән дә яхшырак итеп кем багар аны?.. Ал мине хатының итеп! Кызган мине! Гомерем буе хыялымда сине уйлап яшәдем, якты йолдызым! Баһадир гәүдәңне бер генә тапкыр булса да кочаклыймчы! Әллә мине үзеңә тиң түгел дип әйтәсең киләме? Кара әле минем гәүдәмә — килмәгән җирем юк, эчке киемнәрем дә нинди әнә!— дип, Марго бер кулы белән янбашына кагылып алды да икенчесе белән, итәген күтәрә төшеп, челтәр тоткан ап-ак эчке киемнәрен күрсәтте.— Иртәгә әле крепжоржеттан теккәнен киям!— Марго җәһәт-җәһәт атлап урам аркылы чыкты да егетләр янына килеп басты.

— Бар, Марго, кайтып ял ит!— дип Копака аның иңенә кулын салды.

— Егетләр, миңа барыгыз да бер! Кайсыгызга да кияүгә чыгарга ризамын! Мин сезнең барыгызны да тигез яратам! Нәрсәгә дип әле син тешеңне ыржайтасың, Бердзена? Менә бер сиңа гына күңелем ятмый минем! Бигрәк кире беткән инде син, бөтен тормышымны тәмугка әйләндерер идең! Ә менә Цицка — бөтенләй башка! Ул — укымышлы, тәрбияле...

— Барыгызны да тигез яратам дигән буласың үзең...— дип, сүзгә катнашты Бачана.

— Син дә мондамыни, бичара ятимем? Синең янына килермен мин, хак менә, килермен! Коендырып-юындырырмын үзеңне, чәчләреңне тарармын, күлмәкләреңне уып, чалбарыңны үтүкләп китәрмен... Кара әле көзгегә: кемгә охшагансың син?

— Булды, җитте, Марго... Күрәсеңме, яныбызга кеше җыела башлады... Әйдә, кадерлем, озатып куйыйм үзеңне...— дип, Копака аны култыклап алды.

— Төкерәм мин кешегә!.. Верэ егетләре яшәсен!— Марго Копаканы кочаклады да, башын аның күкрәгенә салып, җырлап җибәрде:

Әйдә, җанкаем, китик,
Бар дөньясын бер итик...

Чатка җиткәч, Копака аның белән хушлашты һәм, Марговның туры өенә таба кайтып киткәнен күреп, егетләр янына әйләнеп килде.

— Чү, чү, Копака, мәет озатмагансыңдыр лабаса!— дип куйды Цицка, иптәшенең сытык йөзен күреп.

Марго — Петриашвили урамының аргы башында, яртылаш җиргә иңгән, ике тәрәзәле, кечерәк бер юеш бүлмәдә яши иде. Бүлмәгә ишегалды ягыннан дүрт басмалы агач баскычтан төшәсе. Өстенә урын җәймәсе каплаган бер өстәл, тутыккан никель бөҗралы тимер карават, бер шкаф, ике урындык, үтүк, кер үтүкли торган такта — бүлмәсендәге бар җиһазы әнә шулар иде. Бүлмә ишегендә акбур белән «Дивана Марго» дигән язу чекрәеп тора. Монысы инде — бала-чагага эше. Марго исә әлеге язуны сөртеп ташламый гына түгел, күңеленнән ул балаларга аз гына үпкә дә белдерми иде.

— Беренчедән, бу сүзләр фәрештә кулы белән язылган, икенчедән, хак сүзләр бит,— дип әйтә иде ул.

...Марго, яшьли әтисез калып, әнисенең бердәнбер кызы булып үсте. Бар җире килгән, баг алмасыдай бу чибәр кыз, күрше-күләнне куандырып, үскән саен һаман гүзәлләнә, сылулана барды. Верэ халкы үзенең бу чибәре белән чын-чынлап горурлана иде. Әйе, 1936 елны, шәһәр өстенә котырынган су ташкыны ябырылып, Нахаловка районының яртысын һәм Пескидагы[1] тегермәннәрне агызып киткән, җиргә казып эшләнгән күкертле мунчаларны кешеләре белән бергә баскан афәтле көнгә кадәр барсы да шулай имин генә иде. Шул көнне әйтерсең лә Маргоның кояшы сүнде, шул көннән кызның язмыш тәгәрмәче тау түбән тәгәрәде.

Ул елны Верэ карчыклары Маргоны алтын коючы Гогияның никахсыз туган улы Ванога димлиләр. Шәһәр халкының ул вакытлардагы язылмаган законы буенча, кыз багу йоласы үткәрелергә, кәләш үзенең булачак кайнанасына, каенсеңелләренә мунчада анадан тума ялангач күренергә тиеш була; янәсе, алдап-йолдап, кияү кешегә кимчелекле кызны димләмәгәннәрме. Гөнаһы кайнанасына, каенсеңелләренә, Маргоның бичара анасына төшсен! Шундый чибәр кызны тикшереп карарга кайсының гына башына килгәндер! Кайвакытны шулай, Марго, өреккән зифа болан сыман, Петриашвили урамы буйлап йөгереп төшеп Меликишвили урамыннан узып киткән чагында, кибет ишекләре төбендә җыелышып торган сатучы-

[1] *Нахаловка, Пески* — Тбилисидәге районнарның элекке исемнәре.

лар, алучылар, авызларын ачып, аның артыннан сокланып карап кала торганнар иде.

Әлеге хәвефле якшәмбе көннең иртәсендә Маргоны хатын-кызлар мунчасына алып киләләр. Төн канатыдай кара чәч толымнарын тыгыз күкрәкләре өстенә салындырган, мәрмәр сын кебек ак, сылу-зифа буйлы кыз, горур башын югары чөеп үзен әйләндереп алган козгыннар өере каршына килеп баса. Кәләшнең гүзәллегенә исләре киткән карчыклар тешсез авызларын мүкелдәтә-мүкелдәтә хуплап пышылдаша башлаган бер мизгелдә җир асты мунчасына көчле су ташкыны бәреп керә. Котлары алынган хатыннар чәрелдәшеп ишеккә ябырылалар һәм, шул мәхшәр эчендә, нәрсә эшләгәннәрен аңышмыйча, ишекне үзләренә таба тартасы урында бөтен өерләре белән ишеккә капланып, үзләренең юлларын үзләре биклиләр... Ләмле болганчык су күз ачып йомганчы җир асты мунчасын басып та китә. Акырган-бакырган, чырылдашып елаган тавышлар бердән тынып кала... Ярдәмгә шәһәр халкы чабышып килеп җиткәндә биредә инде коткарырдай кеше калмаган була. Шулвакыт кайсысыдыр подвал түшәмендәге тимер рәшәткәләрнең берсенә ябышкан кызны күреп ала. Кызның күзләре курку-шашудан катып калган була. Рәшәткәне ватып, кызны подвалдан чыгаралар, әмма аның кәкрәеп каткан бармакларын әле байтак вакыт әлеге тимердән ычкындыра алмый азапланалар.

Шушы хәлләрдән соң Марго бер ай больницада ятып чыга. Кыз, теге афәтле көнне һичнәрсә булмагандай, зиһенен җыеп бернәрсәне дә — батып үлгән әнисен дә, булачак туган-тумачаларын да һәм, гомумән, котырган су ташкынын да хәтеренә төшерә алмый. Врачлар, кызны аңына китермәкче булып, күпме генә тырышсалар да нәтиҗәсе чыкмый: Марго, дивана бер кыяфәттә, һаман дәшми утыруында була. Аннары аны психик авыруларны дәвалау йортына күчерәләр. Анда ул ярты ел ятып чыга. Ниһаять, Марго әкренләп тынычлана, сөйләшә башлый, әмма кызның зиһене инде төзәлмәслек чуалган була. Ә кияү тиешле кеше, адәм актыгы Вано, шул вакыт эчендә кәләшенең язмышы белән ник бер кызыксынып карасын, ник бер хәлен барып белсен дә, сукыр бер тиенлек ярдәм күрсәтсен.

Өенә әйләнеп кайтканнан соң Марго, янына берәүне дә кертмичә, атна буе бикләнеп утыра. Ничектер

шулай беркөнне иртән күршеләре аның бүлмәсеннән килгән җыр тавышын ишетәләр һәм ничек кирәк алай бүлмәсенә бәреп керәләр. Керсәләр, Марго, каршысына ике шешә шәраб куеп, өстәл янында утыра, шешәнең берсе инде бушаган, икенчесе әле башланмаган була. Күршеләрен күргәч, кыз елмаеп җырлап җибәрә:

Сезнең белән биермен мин
Лезгинка да, танго да.
Килегез бер, күз салыгыз
Сылу, чибәр Маргога...

Дөнья мәшәкате арасында күрше-күлән, танышбелеш бичара Марго башына төшкән бәхетсезлекне әкренләп онытa. Кыз да үзенең ялгызлыгына ияләнә. Әмма, япа-ялгызы калып, барысы тарафыннан онытылса да, Марго, кулын сузып, хәер эстәргә чыкмый. Ул хәллерәк кешеләрнең керләрен уып-үтүкли башлый. Ә эшләгән акчасы аңа җан асрарга артыгы белән җитеп килә. Тора-бара кыз ничектер үзеннән-үзе хәмергә ияләшеп китә. Өс-башын ул һәрвакыт чиста, пөхтә йөртә, көн саен эчке киемнәрен алыштыра. Хезмәте өчен акча алган көннәрне ул сыйланып ала да урам бетереп үзенең яраткан көйләрен җырлап йөри. Каршысына берәрсе очраса, менә карагыз, минем эчке киемнәрем нинди матур дип, күлмәк итәген күтәреп күрсәтә һәм шунда ук әлеге киемнәрнең кемнеке икәнен дә әйтеп бирә...

Әмма вакытлар үтү белән, хәмернең зарары үзен нык сиздерә башлый. Маргоның йөзе, әүвәлге сафлыгын, алсулыгын җуеп, җыерчык белән каплана. Урам буйлап җырлар җырлап килүче, җаны имгәнеп, вакытыннан алда бетерешкән бу исерек хатынны күргәндә, аның яшь чакларын, чибәрлеген, горур буй-сынын, ялтырап торган кара күзләрен хәтерләүчеләр генә хәзер ачынып башларын чайкап калалар иде.

Акылына зәгыйфьлек килгән Маргоның сәер кыланышларына ияләшеп җиткәнче, әйләнә-тирәдә яшәүчеләр арасында бичара кызны мәсхәрәләп көлүчеләр дә булмады түгел. Шулар белән телләшә торгач, Марго сүгенергә дә өйрәнеп китте. Алай-болай берәрсе аны рәнҗетә-нитә калса, Марго урамның урта бер җиренә чыгып баса да шундый оста итеп сүгенеп җибәрә — узып баручылар, колакларын томалап, тизрәк читкә качалар иде. Әмма шул чакны урамда берәр бала-чага күренсә, Марго, сүгенүеннән капылт тук-

тап, берни булмагандай, тыныч кына өенә таба китеп бара иде.

— Фәрештә алдында берәүгә дә, хәтта ходай тәгаләгә дә әшәке сүз әйтергә ярамый!— дип сөйләнә иде ул.

Тагын шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: шушы михнәтле-авыр тормышы дәвамында Маргоның бер генә тапкыр да кызлык абруен һәм дәрәҗәсен төшергәне булмады. Маргоны күреп белүче Верэ халкының кайсысы да, кулына тәүрат китабы тотып, аның фәрештәдәй саф, гөнаһсыз кыз булуына ант итә алыр иде...

Кичен Марго Бачананың өенә килде. Ишектән керә-керешли үк:

— Ятимем, син өйдәме?— дип дәште ул һәм, җавап биргәнне дә көтеп тормастан, бүлмәгә үтте. Бачана өстәл артында халык хуҗалыгын планлаштыру буенча чәршәмбе көнне тапшырыласы имтиханга хәзерләнеп утыра иде.

— Ни йомыш, Марго?— дип сорады ул, дәфтәрләрен бер читкә куеп.

— Кая, бир, нәрсәләрне юарга кирәк?— диде Марго һәм Бачананың конспектларын актарырга кереште.

— Нинди кер уу ди тагын! Бар булган киемем — өстемдә!

— Нәрсә дә булса бардыр әле!— дип, үзенекен сөйли бирде Марго.

Бачана шкаф ишеген ачты һәм аннан ярыйсы ук таушалган ике күлмәк һәм бер иске чалбар алып идәнгә ташлады.

— Тик, зинһар, артык каты ышкыма, болай да тетелеп беткәннәр,— дип үтенде ул һәм кабат дәфтәренә төртелде.

— Ул конспектларың шулай кызыкмыни соң, бер минутка да башыңны күтәрә алмыйсың,— диде Марго, стенага кертеп эшләнгән кечкенә шкафны ача-ача.

— Әйе шул, бик кызык, җитмәсә тагы имтиханы борын төбендә!

— И-и тиле! Укыган өчен сиңа түгел, киресенчә, үзеңнән акча түләтсәләр, менә ул чакта чыннан да кызык булыр иде!— диде Марго һәм канәгатьсезләнеп шкаф ишеген шапылдатып ябып куйды.— Ни пычагыма дип бүлмәдә шушы буш әрҗәне тотасыңдыр?! Ишегалдына чыгарып ат әнә!.. Эчәргә берәр нәрсәң юкмы?

— Валерьянка бар.

— Анысын имтихан алдыннан профессорыңа бирерсең, яме!

Марго иелеп идәндә яткан күлмәк-штаннарны җыеп алды һәм тураеп басты да, йөзен җыерып, эчен тотты:

— Шайтан алгыры, тәки тынгылык бирми бит!— диде ул. Аннары күлмәкнең берсен җәеп салды да башын чайкап:— Нәрсә бу — күлмәкме әллә өстәл ашъяулыгымы? Танц-Геурк ашханәсендә пешкән һәр ризыкның табы төшкән бит монда! Оят түгелме сиңа?

— Бик тә оят, Марго җаным, тик нихәл итим соң?

— Өйләнергә кирәк, ахмак, өйләнергә!

— Шулай дисеңме? Тик хатынга нәрсә ашатырмын соң?

— Бер-берегезне ашарсыз!

— Ярар, шулай итәрмен!— диде Бачана.

— Күлмәк-чалбарларыңны иртәгә кич китерермен. Биш тәңкәңне әзерләп куй!— дип, Марго ишеккә таба атлый башлаган иде, ләкин кырт кына туктады да, күлмәген күтәреп, матур трусигын күрсәтте:— Йә, әйтеп кара әле, минем өстә кем киеме?

Бачана җилкәсен җыерып куйды.

— Тышкы эшләр тимер юлы культура министрыныкы!— дип горур кыяфәт белән әйтеп куйды Марго һәм бүлмәдән чыгып китте.

Икенче көнне кичен Марго килмәде. «Күрәсең, берәр җирдә салып алгандыр да йокы симертәдер»,— дип уйлады Бачана һәм аның янына үзе китте.

Ул килгәндә, Марго яшәгән бүлмәнең ишеге ачык, эчтән ут күренә иде. Марго үзе, алсу төстәге чигүле эчке күлмәктән урын өстендә ята, аның йөзе уттай яна, күзләре елтырый иде.

— Ә-ә, ятимем, килерсең дип уйлаган идем аны,— дип Бачанага елмайды ул һәм култык астына кыстырган градуснигын алды.— Мә, кара әле, ничәне күрсәтә икән? Күз алдымда әллә нинди сары таплар йөри, берни күрмим...

Бачана градусникка карады да хәйран калды: терекөмеш баганасы утыз тугыз да тугызны күрсәтә иде.

— Ни булды сиңа, Марго?

— Белмим, җаным... Ниндидер бер явызы кызган тимер белән эчемә кадый да кадый, бораулый да бораулый... Шәрабының да, аракысының да файдасы тимәде... Кич җиткәнче ничек кирәк алай түзгән идем дә... Инде менә аудым... Ничә булган анда?

— Күп...— дип Бачана градусникны өстәлгә куйды.

— Шулай да ничә?

— Утыз сигез...

— Күлмәк-чалбарларын өстәлдә... Аллага шөкер, үтүкләргә өлгердем... Шкафтан уксус ал да, су кушып, маңгаема сөлге чылатып куй әле... Башым ут кебек яна... Бу бәхетсез башкаема шул гына җитмәгән иде тагын...

Бачана кушканны эшләде.

— Мин берәрсен алып килим әле,— диде ул аннары.

— Кемне?

— Врачны!

— Минем ише тиленең кемгә хаҗәте бар?.. Үз акылында булганнары да әле караучысыз-нисез үлеп китә...— диде Марго елмаеп.

Бачана сүзсез генә бүлмәдән чыкты да, алдына-артына карамыйча, Петриашвили урамы буйлап түбән таба җан-фәрманга йөгерде.

Егетләр аптека каршысында ни турындадыр кызып-кызып бәхәсләшеп торалар иде.

— Марго үлә!— дип кычкырды аларга Бачана тыны кысылып.

— Ничек «үлә»? Әле кичә генә монда булган иде бит!— дип гаҗәпләнде Тенгиз.

— Әйе, булган иде, ә хәзер менә үлә!— дип кабатлады Бачана.

— Нәрсә лыгырдыйсың син?! Рәтләп сөйлә әле!— дип, тотып селекте аны Коплик.

— Үлә дип әйтеп торам бит инде!

— Нәрсә булган соң аңа?— дип сорады Цицка.

— Эче авырта, температурасы кырык!

— Нәрсәдән булыр икән ул, Датико?— диде Копака.

— Әйтә алмыйм, Тенгиз. Врач чакыртырга кирәк, хирургны.

— Әйдәгез Шатиришвилига йөгердек!— дип кычкырды Кока.

— Адәм актыгы ул Шатиришвили! Акча төртмәсәң, аягын да атламаячак, хәер, инде күптән йокы бүсәдер!— дип, нәфрәтләнеп читкә төкерде Бердзена.

— Хаҗәте бер тиен! Вахтангның этисе Игнатийга чаптым мин, менә ул ичмасам дөрес кеше!— дип кычкырды Цицка һәм томырылып йөгереп тә китте.

Биш минут чамасы үтүгә, егетләр, аяк очларына гына баса-баса, Маргоның бүлмәсенә керделәр һәм тавыш-тынсыз гына караватянына килеп тезелделәр. Би-

чара хатын, үзен-үзе белештермичә, урын өстендә кызышып ята иде. Егетләрне күрүгә ул, гаҗәпләнеп, терсәкләренә таянды, аннары кабат мендәренә авып төште дә үкси-үкси еларга тотынды. Ул да булмады, ниндидер үзәк өзгеч бер әрнү белән кинәнә-кинәнә көләргә кереште.

— Җаныкайларым... Көткән идем мин сезне, менә ялгышмаганмын... Әйбәт малайлар сез... Йә, нәрсә әле сез мәет чыккандагы төсле тезелешеп бастыгыз... Сезнең барлык чир-сырхауларыгыз, сездән китеп, шушы тиле Маргога күчсә иде...

— Курыкма, Марго, хәзер Цицка врач алып килер,— диде Тенгиз көч-хәл белән телен әйләндереп.

— Нәрсәгә миңа врач? Хәзер инде үлмим мин... Әрнүе дә басылды, температура да төште...— Марго, маңгаена япкан юеш сөлгене йолкып алып, почмакка ыргытты да кулын чәбәкләп куйды. Бачана, сөлгене чылатып, кабат аның маңгаена каплады.

— Ятимем, син куптардыңмы бу ыгы-зыгыны? Шуның өчен менә егетләрдән гафу үтен! Хәзер үк!.. И-и-и! Кайсы гына авыруның, җитмәсә әле акылга туймаган авыруның, төшенә шушындый асыл егетләр керде икән? Һай, Марго, Марго! Уңган да инде үзең!— диде дә кинәт елый башлады. Егетләр, кулларын кая куярга, күзләрен кая яшерергә белмичә, башларын түбән игән килеш басып тора бирделәр. Марго, бераз тынычлана төшкәч, Бачананы чакырып алды:

— Әнә анда, шкаф өстендә, агач тартмачык бар. Шуны алып бир әле миңа... Менә шулай...— Марго тартманы күкрәгенә куйды һәм, беркавым уйланып торганнан соң, аны колагына китереп селкеткәләде дә сөенечле елмаеп, капкачын ачып җибәрде. Тартма эчендә калай беләзек, йөзек, алка кебек җыен ялтыравыклы чүп-чар ята иде.

— Дөнья бәһасе менә бу асылташ Тамар патша өчен Әфганстанның башкаласы Кабулдан махсус кайтартылган...— дип, Марго зәңгәрсу төстәге пыяла кашлы, ике тәңкәлек бакыр йөзекне тартмадан алды.— Мин моны сиңа бүләк итәм, Копака... Өйләнгәч, хатыныңа, уң кулының урта бармагына кигезерсең... Марго бүләге диярсең... Тагын шуны да әйт, әгәр мин бераз яшьрәк булсам, син ана гомерендә дә әләгәсе түгел идең. Миннән хәер-фатиха сиңа!.. Мә, ал!..

Тенгиз йөзекне алды. Бачана аның яңак төерләре биешкәнен күрде.

— Ә менә бу, һинд мәрҗәненнән эшләнгән алкалар синең хатыныңа булыр, князь Коко Әмиреджиби... Ак йөзле, яшькелт күзле, кара чәчле хатынга бик тә төс булыр... Мә, ал, оялма!— дип Марго Коконың учына өч тиенлек уенчык алкалар салды.

— Менә бу алтын беләзек — сиңа, Бердзена!.. Дагъстан осталары койган аны... Андый беләзек — зифа буйлы, тулы күкрәкле, кара күзле хатынга килешер иде... Мә, ал, бүләк итәм!— Бердзена консерв банкасыннан кисеп ясалган әлеге калай кисәген Марго кулыннан зур түбәнчелек белән кабул итеп алды да бер сүз дәшмичә бүлмәдән чыгып йөгерде.

— Ә менә монысы инде — үземә!— диде Марго ун тиенлек көмеш акчалар бәйләмен күкрәге өстенә куя-куя.— Яшь чагымда мин бу муенсаны бер салмый кия идем, шуңа күрә аны бирәүгә дә калдыра алмыйм... Үпкәләмәгез, яме!.. Бачана, яныма кил әле!

Бачана якынрак килеп басты.

— Сиңа дип менә бу фарсы зөбәрҗәтен тотам... Ә син берәр фәкыйрь ятимәгә өйлән, чөнки башкалар сине аңламаячак... Мә, ал, ходай сиңа бәхетле тормыш бирсен!..— Бачана Маргоның кулыннан тимерчыбык кигертелгән зәңгәр сәдәфне алды.— Калганын үзең өләш инде...

Бачана, кулына тартманы тотып, егетләрне йөреп чыкты. Һәркайсы, тартма эченә карап тормыйча гына, үзенә берәр нәрсә алды.

— Ардым инде... Ә ул һаман чәнчи дә чәнчи...— дип ыңгырашты Марго, һәм, хәле китеп, башын артка ташлады.

. — Бераз гына түз, Марго, врач менә-менә килеп җитәргә тиеш! Курыкма, яме!— дип юаткан булды Коплик, калтырана башлаган ияген кулы белән тотып.

— Кем сиңа куркам ди әле? Мин күптән инде, кояш чыкканны көткән кебек, ул көннең килүен зар-интизар булып көтәм... Кил, әйдә кил инде, әҗәлем, мине болай җәфалама!..— дип Марго күзен йомды. Аның яңаклары буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде.

— Килде!— дип кычкырды шунда кайсысыдыр.

Бүлмәгә профессор белән Цицка килеп керделәр. Профессор бүлмәдәгеләр белән баш кагып кына исәнләште дә туп-туры Маргоның караватына таба атлады, кайсысыдыр китереп биргән урындыкка утырып, авыруның пульсын тикшерде, аннары учын аның ут кебек янган маңгаена куйды.

Марго күзләрен ачты.

— Исәнмесез, кадерлем!— дип елмайды аңа профессор.

Марго, яшьләрен сөртеп, янәшәсендә утырган кешегә төбәлде.

— Ходай сезгә сәламәтлек бирсен, хөрмәтле Игнатий!— дип, Марго да елмаеп җавап кайтарды.

— Сез минем исемне беләсезмени?

— Кем генә белми икән аны? Грузия халкының яртысы сезнең аркада гына теге дөньядан кире кайтты бит!

— Бераз кимрәк!— дип шаяртты профессор.— Ә хәзер миңа шуны әйтегезче, кадерлем, нәрсә борчый сезне?

— Иң борчыганы шул: менә бу юлбасарлар ничек итеп җиде төн уртасында сезне бимазаларга җөрьят итәләр икән?

— Анысы өчен хафаланмагыз,— дип тынычландырды аны профессор,— минем эшем шундый, ә йокымны мин көндез туйдырам... Йә, сөйләп бирегез әле, кай җирдә, нәрсәгез авырта сезнең?

— Ут кебек янам мин, доктор, янам...

— Кайчан башланды инде бу хәл?

— Бүген иртән... Юк, кичә, өченче көн... Баштарак, аракы эчкәч, авыртуы басыла торган иде... Бүген менә аудым инде...

— Кая әле, өстегезне ачыгыз!— диде профессор.

Марго бер егетләргә, бер профессорга карап алды.

— Тиле булсам да оялгыч бит, доктор...

— Күпмедер дәрәҗәдә без барыбыз да тиле инде, тик шулай да бернәрсәдән дә оялмыйбыз әле,— дип авыз эченнән мыгырданды профессор һәм шундук одеялны ачып ташлады. Еегетләр читкә борылдылар. Профессор исә, дүрт бармагын куеп, җайлы-ипле хәрәкәтләр белән авыруның эчен капшарга кереште:— Бу турыда авыртамы?.. Ә менә монда?.. Монда?..

Марго, иренен тешләп, сүзсез генә ята бирде. Доктор карап бетергәннән соң гына, ул:

— Бөтен җирем тоташ авырта, доктор, үлсәм котылыр идем ичмасам...

Профессор одеялны читкә алып ташлады да, Марго-ның уң аягын тез турысыннан бөгеп, аны әкрен генә югарыга, эченә таба китерә башлады. Марго кычкырып җибәрде.

Професор тиз генә аягына торып басты.

— Бирелә телефон бармы?

Цицка сораулы карашын Маргога төбәде.

— Дугладзе өендә,— дип ыңгырашты тегесе.

— Хәзер үк ашыгыч ярдәм машинасын чакыртыгыз. Игнатий Джикия кушты, дип әйтегез, хәзер үк килеп җитсеннәр!

Цицка чыгып йөгерде.

— Хәлем бик мөшкелме, доктор?— дип Марго урыныннан күтәрелә төште.

— Тик кенә ятыгыз, акыллым. Сезгә селкенергә ярамый!— дип, профессор Маргоны урынына яткырды, җиңелчә генә яңагыннан чәбәкләп алды.— Кайда йөрдегез соң сез шул гомер, ә?

— Борчылмагыз, доктор, минем өчен үлем — бәйрәм генә ул... Юкка мәшәкәтьләнмәгез...

Профессор өстәл янына килеп утырды, башын кулына салып, тынып калды.

Шунда Кока профессорның пинҗәк кесәсенә сиздермичә генә акча салды. Профессор исә, Кокага карамыйча, әлеге акчаларны кесәсеннән алды да өстәл өстенә куйды. Аннары, пинҗәгенең эчке кесәсеннән бер төргәк унлыклар чыгарып, тегеләре янына салды да, торып, бүлмәдән чыгып китте. Егетләр аның артыннан кузгалдылар.

— Берәр өмет бармы, профессор?— дип сорады Бердзена.

Профессор башын чайкады.

— Бернинди дәме?— дип кабатлады Тенгиз.

— Бер процент...

— Ни булган соң аңа, профессор?

— Перитонит... Сукыр эчәгесе шартлаган... Өченче көнне үк инде... Кирәк бит, ә!..

Унбиш минут үтүгә ашыгыч ярдәм машинасы килеп җитте. Маргоны носилкага салдылар да машинага таба атладылар. Бүлмәсеннән чыкканда ул егетләргә таба борылды:

— Хушыгыз, Верэ егетләре! Хушыгыз, җаныкайларым!— Аннары кинәт носилкасыннан күтәрелде дә ялварган тавыш белән:— Күкертле мунчага йөрмәгез!.. Зинһар өчен дим, беркайчан да барасы булмагыз!.. Минпән сезгә васыять!..— диде.

Мәрхүмәнең гәүдәсен шифаханәнең мәетләр бүлмәсеннән сишәмбе көнне алып чыктылар. 1936 елгы ташудан соң да Маргоны шушы больницага китергәннәр иде.

Верэ кварталы, Петриашвили һәм Меликишвили урамнары тоташтан халык белән шыгрым тулы иде. Кызыксынып тукталучыларның саны таныш-белешкә караганда да күбрәк иде.

Шау чәчәккә күмелгән табутны, агач носилкага куеп, Верэ үре буйлап сигез егет күтәреп барды, яннарыннан аларга алмашка тагын сигез егет атлый иде. Табут алдыннан чәчәкләр белән бизәлгән машина бара. Бередә чәчәк шул хәтле күп иде, читтән караганда искиткеч зур бер чәчәк бәйләме үзе зиратка таба барадыр кебек тоела иде.

Меликишвили урамында шәһәр транспорты: автобуслар, машиналар, трамвайлар тынып калды. Петриашвили урам чатына җиткәч, егетләр биш минутка тукталдылар. Менә бер машинаның сузып-сузып кычкыртканы яңгырады, аңа икенчесе, өченчесе килеп кушылды һәм кинәт бөтен квартал тоташ гүләү авазларына күмелде.

— Кыямәт көне җиткәнме әллә?— дип әлеге процессиягә очраклы гына килеп эләккән бер шофер, чыраен сытып, кабинадан башын чыгарды.— Үткәрәләрме бүген безне, юкмы?!

— Сигнал бир әйдә!— диде аңа шулчак Верэ кварталы егетләренең берсе.

— Нигә әле?— дип гаҗәпләнә калды шофер.

— Шулай кирәк!

— Ничек... кирәк!— дип карулашты машина хуҗасы.

— Менә болайрак!— диде дә егет сигналга басты.

— Ал кулыңны! Аккумулятор утыра!

— Зыян юк, этеп җибәрербез!— дип җавап бирде егет, кулын сигналдан алмыйча.

— Нинди түрәне күмәләр соң ул кадәр? Нәрсәгә дип әле мин сигнал бирергә тиеш?— Ачуы кабарган шофер кабат кабинасыннан башын чыгарды.

— Верэ Маргосын күмәбез...

— Кемне?

— Кара әле, агай-эне, кулың исән чакта кушканны эшлә инде син, ә!— дип егет шоферның башын машина эченә төртеп кертте.— Аңладыңмы?

Машина хуҗасы егетнең шаярып сөйләшмәвен аңлады булса кирәк, бар көченә машинасын акыртырга тотынды. Егет исә икенче бер машинага таба атлады. Берәр минуттан анысы да кычкыртырга тотынды. Егетнең ерагайганын күреп, шофер сукранып алды:

— Жанна д'Аркны күмәләрмени?..

— Юк, тиле Маргоны күмәләр!— диде процессиядә катнашучылардан берсе.

— Тиленe?! Шушылай итеп тиле кешене күмәләрме?

— Әйе, әнә шулай итеп күмәбез!— дип җавап бирде шоферның янәшәсендә тукталган икенче бер Верэ шоферы.

— Менә егет икәнсез! Мондый кварталда үлсәң дә үкенечле түгел!— дип әйтеп куйды хәйран калган шофер.

Кичен Танц-Геурк духаны Верэ егетләре белән тулды. Зурдан купмыйча гына табын әзерләделәр — өстәлләргә икмәк, сыйр, шәраб, редиска куелды. Тамада сайлап маташмадылар. Егетләр урыннарына утырып, подвалда тынлык урнашкач, Цицка аягүрә торып басты һәм стаканын тутырып шәраб салды да, аның берничә тамчысын икмәк кисәгенә тамызып, сүзен башлады:

— Верэ кварталының кайгысы өчен, аның күз яшьләре һәм шатлыгы өчен, аның җуелган матурлыгы өчен!

Барсы да урыннарыннан тордылар һәм сүзсез генә стаканнарын бушаттылар.

Ул көнне Танц-Геурк подвалында моннан ары бер сүз дә әйтелмәде, бер стакан шәраб та эчелмәде.

— Сыеграк, сыеграк шул, Рамишвили...— дип, профессор иренеп кенә Бачананың зачет кенәгәсен актарып чыкты.— Нәрсә булды, ник хәзерләнмәдең?

Бачана дәшмәде.

— Ни булды сиңа, Рамишвили?— дип кабатлап сорады аннан профессор, җавап ала алмагач.

— Авырдым мин, хөрмәтле профессор, хәзерләнергә өлгермәдем...

— Авырмадың син, теге тиле хатын белән әвәрә килеп йөрдең!.. Әллә кичә синең, кан кардәшен күмгән сыман, табут артыннан ияреп барганыңны күрмәде дисеңме?

— Тиле түгел иде ул, хөрмәтле профессор,— дип каршы килде Бачана.

— Кем соң ул алайса? Ираклий патшамы? Исең китәр, халык кварталы белән акылдан шашкан диярсең! Ике сәгать буена хәрәкәт тукталып торды!

— Җаны имгәнгән авыру хатын иде ул, хөрмәтле профессор!— Бачана, авызында әче тоз тәме тоеп, урыныннан торды.

— Кая кузгалдың әле син?— диде профессор гаҗәпләнеп.

— Кабат килермен,— диде Бачана кыюсыз гына.

— Әллә берәр якының идеме ул синең?

Бачана озак кына дәшми торды, аннары профессорга күтәрелеп карады да:

— Ул минем апам иде...— диде.

Профессор Бачананың күзләренә текәлеп карады. Егет, аның карашын күтәрә алмыйча, башын түбән иде. Икесе дә бер мәлгә сүзсез калдылар. Аннары профессор зачет кенәгәсен япты да Бачанага сузды:

— Бар, Рамишвили!— диде һәм, урыныннан торып, тәрәзә каршына барып басты.

Бачана зачет кенәгәсен кесәсенә салды да бүлмәдән чыкты.

— Йә, ничек? Ничәле алдың?— дип, аны сабакташлары урап алдылар.

Бачана җавап бирмәде: коридорны үтеп баскычтан төште дә, университет бакчасына чыгып, бер буш эскәмиягә килеп утырды. Бар нәрсәдән битараф булып байтак утырды ул. Аннары кесәсеннән зачет кенәгәсен алды да болай тиктомалдан гына аның битен ачып карады...

...Бачананың үз гомерендә беренче бишлесе иде бу. Ул шап иттереп зачет кенәгәсен япты, тагы ачты, тик бу юлы инде ул берни күрмәде.

Бачананың күзләре тулы яшь иде.

Бачана елый иде.

12

Булика вафат булганнан соң, профессор Бачана белән рухани янына берәүне дә яткырмаска, буш койканы исә, авыруларның күңеленә борчу салып тормасын дип, бүлмәдән чыгарып куярга кушты. Ләкин палатадагы буш урын хуҗасыз караватка караганда да авыррак тәэсир итә булып чыкты.

Һәр көнне иртән йокыдан уянуга Бачана да, Иорамата да, ирексездән, әле кайчан гына Буликаның караваты торган урынга күз ташлыйлар һәм, үткәндәге хәлләр искә төшеп, аларның йөрәкләре сулыгып-сулыгып тибә башлый иде. Аннары инде көн дәвамында нәрсә хакында гына сөйләшә башласалар да, Буликаның берәр мәзәк яисә шаян-тапкыр сүзен көткәндәй, әңгәмәне өзеп, әледән-әле шул якка таба карап алгалыйлар иде.

Шул рәвешле ике атна чамасы дәвам итте. Әмма вакыт дигәнең әкренләп үз җаен ала икән, тора-бара

Бачана белән Иорам-ата да Буликаның юклыгына иялә-нә башладылар кебек...

...Көннәрдән бер көнне иртән Иорам-ата Бачанага һич көтелмәгән бер сорау бирде:

— Хөрмәтле Бачана, сезне, мөгаен, Дидуби пантеонына күмәрләрдер, шулаймы?

Бачана башта бу сүзгә көлеп куйды, әмма шунда ук хәвефләнеп:

— Әллә начар төш күрдегезме?— дип сорады.

— Әйе, күрдем, әмма төшем сезгә түгел, үземә кагылышлы,— дип күңелсезләнеп кенә җавап бирде Иорам-ата.

— Ул очракта мине түгел, бәлки үзегезне кая күмәселәрен сорарга иде... Нәрсәдер хәйләлисез ахры сез, атакай!— дип шиген белдерде Бачана.

— Шул шул менә... Әгәр сезне пантеонга күмсәләр, бәлки шунда, чиркәү ишегалдында, минем өчен дә урын табылмас иде микән дим...

— Андый принциптан чыгып эш ителсә, мин Язучылар союзының ишегалдында күмелергә тиеш булам... Әгәр менә сез Дидуби чиркәвенең башлыгы булып эшкә урнашсагыз, ул чагында инде чынлап та каберләребездә бер-беребезгә терәлеп үк ятуыбыз бик ихтимал!

— Димәк, сезнең өчен инде пантеонда урын күптән алып куелган, югыйсә сез алай шаяртмас идегез!— дип сүзен йомгаклады Иорам-ата.

— Ялгышасыз, изге ата!

— Нигә?

— Нигә дисезме? Чөнки Дидуби пантеоны инде күптән шыплап тулган. Этеп-төртеп тә сыйдыра торган түгел... Шул, аягүрә бастырып күммәсәләр генә... Ахыр чиктә, шунысына иманым камил: сезне дә, мине дә җирләми калдырмаслар, шәт...

Иорам-ата авыр сулап куйды.

— Шулай да, нинди төш күрдегез соң, атакай?— дип кызыксынды Бачана.

— Әйтмәгез дә инде!.. Кайчандыр, мин җеназа укып, соңгы юлга озаткан барлык мәрхүмнәр бөтенесе бергә Ортачала чиркәвенең ишегалдына җыйнаулашып килгәннәр дә минем чыкканымны көтеп торалар, имеш!

— Ничек соң? Чыктыгызмы?

— Шунда мин — дөньяның бер бичара фәкыйре, куян йөрәкле куркак җан кеби, чиркәү түрендәге алтарь артына кереп постым... Исемә төшсә, оятымнан үкереп елыйсым йә үземә үзем кул саласым килә!

— Үзеңә-үзең кул салу, изге атакай, һәр шәхеснең чын-чынлап тулысынча автономияле булуын күрсәтә,— дип тәэсирләнеп сөйләп китте Бачана.— Тик, кызганычка каршы, андый нәрсә сезнең динегез тарафыннан тыела шул, чөнки мордарлык коточкыч зур гөнаһ кылу һәм җан кыю дип санала.

— Белгәнемчә, үз-үзеңә кул салуны сез дә алай бик хупламыйсыз шикелле,— дип җавап кайтарды Иорам-ата.

— Әйе, кайбер мәсьәләләрдә безнең фикерләр туры килә. Нәкъ менә шуңа күрә дә «сездән яхшы коммунист чыгар иде» дип әйткән идем мин,— диде Бачана, үткәндәге сөйләшүне искә төшереп.

— Хәтерем ялгышмаса, ул чагында мин дә сезгә «шуның нәкъ киресе дә булырга мөмкин» дип җавап биргән идем шикелле,— диде Иорам-ата, Бачананың сүзләрен юкка чыгарып.

— Изге ата, мине үз ягыгызга аударырга тырышмагыз, югыйсә бит сезнең мәхәллә халкының һәммәсен коммунистлар ягына түндерүем бар!

— Шулай булмыйча соң! Коммунист, өстәвенә тагын язучы да булсын... Берүзегез генә дә йөз руханидан хәтәррәк сез! Шулай да җан ияләренең, башка кыяфәт алып, җир йөзенә кабат кайтуына өметләнәм әле мин. Бәлки, сез шул кабат фани дөньяга кайтканнан соң хак тәгаләгә ышана башларсыз!— дип, Иорам-ата төртенеп куйды.

— Язучы кеше, атакай, үз халкының тугрылыклы эте ул... Мин үзем, башка кыяфәт алып, кабат җир йөзенә әйләнеп кайтуга ышанмыйм, әлбәттә, әмма да ләкин андый хәл була калса, минем җаным, һичшиксез, эт сурәтенә кереп кайтыр иде. Шулай булгач, мин дөнья куйганнан соң, хуҗасыз этләргә мәрхәмәт кылыгыз, аларга төбәп таш атмагыз: бәлки, арада берсе — миндер!

— Сезне тыңлавы — җан рәхәте, хөрмәтле Бачана! Тик дөнья куйган һәр язучының җаны урам этенә күчә барса, дөнья йөзендә яшәве бер дә күңелле булмас иде!— дип, астыртын гына елмаеп куйды Иорам-ата.

— Әйе, сезнең җаннарның бүреләргә күчә баруын да исәпкә алсаң, бөтенләй түзәрлек булмас шул.

— Нишләп бүрегә?!

— Үз мәхәлләсе халкыннан куркып качкан мәхәллә башлыгын арслан дип әйтеп булмый инде!— диде Бачана, елмаюын яшереп кенә. Иорам-ата яткан җиреннән

боргаланып куйды һәм, җавап таба алмыйча, үпкәләп читкә борылды.

— Шулай да сез борчылмагыз,— дип сүзен дәвам итте Бачана,— төшегез хәерлегә сезнең. Йөз ел яшәячәксез әле сез.

Иорам-ата йомшара төшкәндәй булды.

— Әйтегез әле, зинһар,— дип сүз башлады ул,— сезнең административ баскычлардан чыгып караганда, әйтик, минем эш ниндирәк хезмәттәге кешенең вазифаларына туры килә икән?

— Сезнең мәхәлләгә күпме кеше йөри соң?

— Дин тотучыларның исәбен алып бармыйбыз без.

— Ярый. Чиркәү иганәләрдән күпме керем ала?

— Күпме дип әйтим икән... Һәрхәлдә, храмны ремонтлау өчен җитми инде...

— Ә болай, гомумән, нинди акчага яшисез сез?

— Акча белән безне хөкүмәт тәэмин итә.

— Ничек?! Коммунистлар чиркәүне үз акчасына тотамы?— диде Бачана кычкыра төшеп.

— Шуннан ни булган? Чиркәүне үзләре мәхәлләсез калдырды бит, хәзер менә янчык авызын бераз чишсеннәр инде...

— Ала-а-ай... Бу очракта, атакай, дәүләт хезмәтенә күчереп исәпләгәндә, сезнең дәрәҗә авыл клубы мөдире вазифасына туры килә,— дип Бачана Иорам-атаның җәмгыятьтәге урынын ачыклады.

— Көлүегезме бу?!

— Нишләп инде?

— Мин бит духовный семинария бетергән кеше!

— Безнең клуб мөдирләре дә күбесе югары белемле, иң аз дигәндә дә, махсус урта белемнәре бар! Ә үзләре нинди мактаулы исемнәр йөртәләр! Атказанган сәнгать эшлеклесе, атказанган культура работнигы!.. Ә менә сезнең арада ичмасам берәү генә булса да республиканың атказанган рухание бармы? Мәсәлән, минем андый нәрсәне ишеткәнем юк!— дип, Бачана, рухланып китеп, күрәләтә көләргә кереште.

Иорам-атаның кәефе китте.

— Ул кадәр кайгырмагыз!— диде Бачана.— Әйдә, күчегез безнең якка, вәгъдә — иман: райкомга инструктор итеп билгелибез үзегезне!

— Хөрмәтле Бачана!— диде рухани чын-чыннан хәтере калып.— Сез бирегә нәрсәгә дип килдегез? Инфарктан дәваланыргамы, әллә христиан руханиларын тоткан юлларыннан яздырырга дипме? Безгә рәхим итегез әй-

дә, күңелегезгә хуш килсә, мин сезне поп ярдәмчесе итеп билгеләрмен!

— Нигә ачуланасыз, изге ата? Әгәр сезнең тәгълиматыгыз хак икән, вафатымнан соң мин баштанаяк сезнең хөкемгә калачакмын. Ул чагында инде мине теләсә нәрсә эшләтә аласыз!— диде Бачана көлеп.

— Юк инде, туганкай! Ахирәттә без очрашмаячакбыз!— дип кырт кисте Иорам.

— Ни өчен әле?— диде Бачана күңелсезләнеп.

— Ни өченме? Коммунистик тел белән әйткәндә, оҗмахка тәкъдим итәр өчен сезнең анкета мәгълүматларыгыз туры килми! Сезнең юл — туп-туры тәмугка гына! Аңлашылдымы?

— Ә безнең дуслык? Үзегезнең канат астыгызга алмассыз микәнни мине?— дип, изге атаның күңелен йомшартмакчы булды Бачана.

— Минем ярдәмнән әллә ни мәгънә чыкмас кебек... Иблис инде сезне күптән майлы калҗа көткәндәй көгәдер...

— Әгәр мин иманымны алыштырып сезнең якка күчсәм?

— Кылган гөнаһларыгызны да таныпмы?

— Әгәр минем гөнаһларым булмаса?

— Шулайдыр шул! Кайдан килеп сезнең гөнаһыгыз булсын ди! Бөтен тормышыгыз, кылган эшләрегез үзегезгә чын хакыйкать кебек тоелгач...— диде Иорам-ата кулын селтәп.

— Ихлас күңелдән инанган кешеләр — чын мәгънәсендә бәхетле кешеләр, Иорам-ата... Ә без үзебезнең хак юлдан баруыбызга ышанабыз...— дип җавап бирде Бачана җитдиләнеп.

...Палатага фельдшер Женя килеп керде. Бачана белән Иорам-ата дәррәү одеялларын кайтардылар да, корсакларына әйләнеп, укол салынасы төшләрен ачып куйдылар. Женя шаркылдап көлеп җибәрде.

— Өстегезгә ябыныгыз, иптәшләр! Бу юлы мин буш кул белән кердем... Хөрмәтле Бачана, анда сезнең янга килгәннәр, кунагыгызны шул кыяфәттә каршыламассыз бит инде.

— Кунак дисезме? Нәрсә кирәк аңа?— дип, Бачана сагая калды.

— Сезнең сәламәтлегегез белән кызыксына... Гәрәт чүлмәген нишләтим: алып куйыйммы, калсынмы?— диде Женя, көлә биреп.

— Ир кешеме, хатын-кызмы?

— Хатын-кыз. Якын кешегез, ди...

— Алай булганда — калсын! — диде Бачана чираттагы кунакны каршыларга әзерләнә-әзерләнә.

— Аңлашылды!

Женя чыгып китте. Ишек ябылырга да өлгермәде, култык астына шактый калын папка кыстырган, урта яшьләрдәге, чал чәчле бер ханым, җил-җил атлап палатага килеп тә керде. Бүлмә уртасына җиткәч, ул тукталып калды, як-ягына каранды һәм, беркавым икеләнеп торганнан соң, туп-туры Иорам-атаның караватына таба юнәлде.

— Исәнмесез! Мин сезнең гаилә дустыгыз — Нина Санеблидзе! — диде хатын һәм, урын тәкъдим иткәнне дә көтеп тормастан, руханиның каршына килеп утырды.

— Гаилә дусты? — дип кабатлап сорады тегесе.

— Әйе. Сезнең әтиегез Акакий белән минем әтием Лазарь 1915 елдан 1916 елга кадәр бергә Баку индустриаль техникумында укыганнар.

— Туктагыз әле, дөресен генә әйткәндә, сез кем янына килдегез соң? — дип гаҗәпләнде рухани Бачанага күз ташлап. Әмма тегесе, йөзен сытып, Иорамнан әңгәмәне дәвам иттерүен үтенде.

— Кем янына булсын? — дип гаҗәпләнде хатын үз нәүбәтендә. — Сезнең янга, әлбәттә!

— Без сезнең белән танышмы? Очрашканыбыз бармы? — дип әкренләп рольгә керә башлады Иорам-ата.

— И аллам, танышлармы, имеш! Кая карама: радиодан дисеңме, телевизордан дисеңме — берөзлексез Бачана Рамишвили, Бачана Рамишвили дип һаман сөйләп, күрсәтеп торалар!.. Хәер, әйтергә кирәк, соңгы вакытта бераз үзгәргәнсез үзгәрүен... Сакал үстергәнсез...

— Әйе, палатада салкынрак шул... — дип, Иорам-ата сакалын сыпырып куйды һәм одеялына төренебрәк ятты.

— Шулай, шулай! Чир белән шаярырга ярамый! — дип ризалашты ханым.

— Һм-м-м... Сез миңа йомыш белән килдегезме, хөрмәтлем? — Иорам-атаның тәмам түземе төкәнде.

— Әйе. Кәефләрегез ничегрәк соң?

— Рәхмәт. Хәзер яхшырак инде... Үзегездә ни хәлләр бар?

— Миндәме?! Мин бетәм, батам, янам, үләм! — диде ханым бер тын белән.

— Миннән нинди ярдәм кирәк соң сезгә?— дип Иорам-ата ярдәм кулын сузарга ашыкты.

— Ярдәм дисезме? Ярдәм итү түгел, коткарырга кирәк мине!— дип үз таләбен белдерде ханым.

— Булдыра алырмын микән соң?— дип икеләнгән булды Иорам-ата.

— Ничек?! Сезме?! Бачана Рамишвилимы?! Ха-ха-ха!— дип ясалмаланып көлде ханым.— Сезнең бер сүзегез, бер хатыгыз, телефонны алып бер шылтыратуыгыз...

— Сезнең үтенечегез нидән гыйбарәт инде? Аңлатып бирегезче, зинһар!— Иорам-ата бу әңгәмәнең күптән түгел генә тәмәке әзерләүче бәндә белән Бачана арасында булган сөйләшүне хәтерләтә башлавын уйлап куйды.

— Икенче августта, көпә-көндез, кеше күз алдында минем улымны суйдылар.

Иорам-ата шаккатып беравыкка өнсез калды.

— Кемнәр? Кайда?— диде ул көч-хәл белән телен әйләндереп.

— Ояты качкан бер ришвәтче, тинтәк... Университетның йөз дә җиденче аудиториясендә...— диде ханым трагик бер тавыш белән һәм шунда ук кызу-кызу сөйләргә дә тотынды:— Ул киткәнгә карап, нәрсә дә булса үзгәргәндер дип уйлыйсызмы?

— Кем киткәнгә карап?— диде Иорам-ата аңышып бетмичә.

— Кем булсын инде тагын!— Ханым, күзләрен шакмакландырып, түшәмне айкап алды.— Кабахәт, үземне дә, малайны да суйды бит! Баланы аудиториядән күтәреп алып чыктылар... Өч ел бит! Өч ел буе малайны өч фәннән хәзерләдем — грузин, инглиз теленнән һәм тарихтан! Һәркайсына җидешәр йөз түләдем! Һәм менә нәтиҗәсе нинди!

Иорам-ата, ниһаять, кече Санеблидзеның исән-имин булуын төшенеп, җиңел сулап куйды.

— Нәрсә, мәктәптә укымадымыни ул?

— Менә сез үзегез мәктәптә укыдыгызмы? Нәрсәгә генә өйрәтә алдылар анда сезне?

Иорам-ата, нәрсә дип җавап бирергә дә гаҗиз булып, башын түбән иде.

— Балага Автандилның [1] васыятьнамәсен яттан сөйләргә кушкан бит! Эт җан! Җидешәр йөз сум акча каера-каера әзерләгән үз укучыларыннан сорасын иде ул

---

[1] *«Автандилның васыятьнамәсе»* — Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» исемле әсәреннән бер бүлек.

аны! Автандилның васыятьнамәсе, имеш! Аны хәтта Руставели үзе дә яттан белмәгән, югыйсә нәрсәгә дип язып торыр иде икән ул аны!

— Алай ук әйтмәгез инде!— дип каршы килде Иорам-ата.

— Шулай булмыйча соң! Ул каһәр суккыры васыятьнамәне әллә укытучы үзе укыгандыр дип уйлыйсызмы? Оятсыз ришвәтче!..

— Ни өчен әле сез шулай дип уйлыйсыз?

— Нәрсәсен уйлап торасың аның? Ул ыштыр битнең кем икәнен белер өчен йөзенә бер карау җитә!

— Һич ышанасым килми!— дип бирешмәде Иорам-ата.

— Әйдәгез, бәхәстәнме?— дип кулын сузды хатын.

— Нәрсәдән?— диде рухани һәвәсләнеп китеп.

— Нәрсәдән теләсәгез дә! Һәм, гомумән, минем шуны әйтәсем килә: яттан Руставелины, дөнья тарихын һәм инглиз телен белгән балага университетта нәрсә генә эшләргә кала соң? Белемне бит белемсезләргә бирергә кирәк! Менә шулай!

— Яхшы, хуш. Инде хәзер нишләргә тиеш без?..— дип, Иорам-ата әлеге хатынның гомуми һәм югары белем бирүдә яңа кагыйдәләр пропагандалавына чик куйды.

— Сез миңа ярдәм итәргә тиеш!— дип әйтеп салды ханым.

Иорам-ата, ярдәм көтеп, Бачанага карады. Әмма тегесе, сөлге белән авызын томалаган килеш, башын гына чайкады.

— Ничек итеп?— диде рухани тәмам гаҗиз булып.

— Мәгариф министрлыгына барып килегез.

— Ләкин бит мин больницада ятам әле!..

— Телефоннан шылтыратыгыз яки хат языгыз!..

— Нәрсә дип?

— Бу малай минем кардәшем дип, яхшы укый, бик шәп итеп хәзерләнде, спортчы дип... Аннары...

— Белмим, белмим...— дип ыңгырашты Иорам-ата.

— Менә мәктәптән алынган белешмә. Укучылар арасында үткәрелгән спартакиадада ул өченче урынны алды, өч метр —озынлыкка, метр да унҗиде сантиметр — биеклеккә сикерде...

— Алайса аны физкультура институтына урнаштырырга кирәк! Минем бу иптәш — спортсмен, ул булышыр!— дип, Иорам-ата Бачанага күрсәтте. Тегесе, йөзеннән сөлгене алып, баш какты.

— Нәрсә сөйлисез сез? Нинди физкультура институты ди ул тагын?— Ханым Бачана ягына җирәнүле караш ташлады.— Мин бала үстерәм, кәҗә тәкәсе түгел!

— Нишләп сез андый сүзләр сөйлисез, хөрмәтлем?— дип үпкә белдерде Бачана.— Думбадзе, Гокиели, Хныкина, Джугели[1]— барысы да шул институтны бетергән кешеләр...

— Сез спортчымы?— дип бүлдерде аны ханым.

— Әйе.

— Сездә дә инфарктмы?

— Әйе.

— Шул кирәк сезгә!

Бачана көлемсерәп куйды:

— Менә рәхмәт!

Ләкин ханым никтер шундук үзенең килешсез кыланышын төзәтмәкче булды:

— Ходай сәламәтлек бирсен сезгә!— дип куйды.

— Әллә сез аллага ышанасыз?— диде Иорам-ата куанып китеп.

— Һи-и, ышанган кешегә ни ярдәме тигәне бар соң аның? Менә сез ярдәм итегез миңа, шул чагында минем аллам да, коткаручым да булырсыз!

— Булмый, үтерсәгез дә хәлемнән килми!— диде Иорам-ата авыр сулап.

— Сезнеңме? Депутат, Үзәк Комитет члены, редактор кеше була торыпмы? Алайса тагын кем ярдәм итә ала инде?— дип ихлас күңеленнән гаҗәпләнде ханым.

— Карагыз әле, хөрмәтлем, сез Үзәк Комитетның әшнәлек, агай-энелек турындагы карарын укыдыгызмы?— диде рухани чыгырыннан чыгып.

— Әшнәлекнең ни катнашы бар монда? Мин бит үз улым өчен сорыйм, чит кеше өчен түгел!— дип соңгы тапкыр талпынып карады хатын.

— Юк, булмый! Аннары икеле билгесе куелган бит инде аңа! Һәм, гомумән, әйдәгез бу турыда сөйләшүне туктатыйк!..— диде Иорам катгый тавыш белән һәм стенага таба борыла башлады.

— Ярый алайса...— дип җиңелде хатын.— Ул чагында миңа икенче бер мәсьәләдә ярдәм итегез...

— Тагын нәрсә инде?— дип чәчрәп китте Иорам-ата.

— Сез Беренче Май райбашкарма комитеты пред-

---

[1] *Нина Думбадзе, Елена Гокиели, Надежда Хныкина, Мзия Джугели* — заманының күренекле спортчылары.

седателенә кода тиешле икәнсез... Инде килеп, фатирга кагылышлы кечкенә генә бер мәсьәләне хәл итеп ташлыйсы иде... Безнең күршебез Сололакида[1] дүрт бүлмәле фатир алып чыкты. Нәрсә өчен, нинди хезмәтләре өчендер, анысы безгә билгесез, әлбәттә... Без аның бушап калган бүлмәсен үзебезнекенә кушмакчы идек. Колониядәге улым өйләнәм дип яза. Тиздән срогы тула аның. Кайгыртырга тиешме мин аны? Тиеш, әлбәттә! Дөрес, бу бүлмәне тагын берәү дәгъвалап йөри йөрүен, ләкин ул хаклы рәвештә безгә калырга тиеш. Әгәр, стенаны тишеп, ишек ясасаң һәм бер кырыйга баскыч җайлап куйсаң, безнең кухняны һәм теге фатирның лоджиясен күршеләрнең ике бүлмәсе белән берләштерергә була. Ул күршегә без Церетели проспектыннан икенче бер бүлмә белештек инде. Дөрес, бераз ераграк, әлбәттә, бүлмәсенең мәйданы да дүрт метр да унҗиде сантиметрга кечерәк, ләкин без аңа ремонтны үзебез ясаячакбыз, аннары ирем бушлай телефон керттереп бирергә булды. Шул фатир белән янәшә генә бер бүлмәдә ялгыз авыру хатын яши. Ходай аңа сәламәтлек бирсен, әмма озакламый үләчәк ул. Узган ел шул хатын минем иремне уллыкка алды, хәзер без ул бичараны ашатып-эчертеп, тәрбия итеп торабыз. Әгәр менә хәзер шул хатынның бүлмәсенә күче улымны яздырмасак, без ул бүлмәдән колак кагачакбыз, аңлыйсызмы шуны? Бөтен куйган хезмәтләребез җилгә очачак!.. Телефонны алып, сезнең бер шылтыратуыгыз җитә бит, хөрмәтле Бачана! Ходай сезгә сәламәтлек бирсен дип, көне-төне догалар укыр идек!..

— Үтенечегезне кире кагу миңа, әлбәттә, бик уңайсыз, тик... Белмим мин ул председательне...— дип Иорам-ата маңгаена бәреп чыккан тирен сөртеп алды.

— Аның каравы ул сезне белә!— дип шатланып кычкырып җибәрде ханым.

— Ай-һай, белә микән...— дип сөйләнеп алды Иорам-ата һәм, ярдәм сорап, бик тә мәгънәле итеп Бачанага карады. Тегесе, бичара руханины кызганып, озаккарак сузылган бу әңгәмәгә бик актив килеп кушылды:

— Әйе, алар таныш түгел, монысы миңа бик яхшы мәгълүм!

— Һич ышанасым килми!

— Әнием белән ант итәм!— диде Бачана, кулын күкрәгенә куеп.

---

[1] *Сололаки* — Тбилисидәге бер районның элекке исеме.

— Бәлки, миңа сез ярдәм итәрсез?— Ханым, Иорам-атаны онытып, өметле карашын Бачанга төбәде.

— Минем танышлык физкультура институтында гына...

— Булса соң, киләсе елга мәктәпне минем төпчек улым бетерә. Бик шәп йөзә ул, Кобулетида, ярдан йөз метр эчкә кереп, су төбеннән ташлар алып чыга! Фамилиягезне әйтегезче, зинһар, киләсе елга сезне борчыйсы булыр,— дип ханым сумкасыннан блокнот белән карандашын чыгарды.

— Аңарчы әле исән булсам...

— Анысы да дөрес... Бәхет яклары минем шулай чамалы инде... Алай да фамилиягезне әйтегез әле...

Әңгәмәнең шушы урынына җиткәч, Бачана бөтен инсценировканы җимереп ташлады. Ул, шаяртып кыланганнарын онытып, горур кыяфәт белән:

— Бачана Рамишвили булам!— дип әйтеп салды.

Ханым, исе китеп, ачкан авызын ябарга онытты, кулындагы карандашы һавада асылынып калды.

Бачананың үзенең дә маңгаена салкын тир бәреп чыкты.

— Нәрсә дидегез сез?!

— Әйе, мин — Рамишвили булам!— дип кабатлады Бачана.

— Алайса ул кем соң?— диде хатын, Иорам-атага күрсәтеп.

— Ортачала изге троица чиркәвенең башлыгы Иорам Канделаки.

Ханым ни дип тә әйтә алмас хәлдә аптырап калды, йөзе нииндидер көлсу төскә керде.

— Җитмәсә бит әле шул кеше миннән «аллага ышанасыңмы» дип сорап торган була!

— Әйе, берникадәр гаеп, әлбәттә, минем өскә дә төшә, ләкин...— дип акланып маташты Иорам-ата.

Ханым аягүрә торып басты. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты.

— Шушымы инде сезнең гуманизм?— Ханым нәфрәт тулы күзләрен Бачанага текәде.

Бачана бер сүз дәшмичә җилкәсен генә сикертте һәм тел астына бер сәдәф валидолын салды.

— Шамакайлар!— дип кычкырды ханым һәм палатадан чыгып китте.

— Әйе-е-е... уңайсызрак килеп чыкты,— диде Иорам-ата.

— Бик начар килеп чыкты... Барысына да мин генә гаепле. Кичерә күрегез, зинһар!..

— Кичерәм, әлбәттә, чөнки шул ук дәрәҗәдә мин үзем дә гаеплемен, әмма аннан да бигрәге — чын күңелдән кызганам мин сезне! Шушы дөнья йөзендә сезнең сәламәтлегегез өчен борчылган, әйе, бары тик сәламәтлегегез өчен генә борчылган бер генә кеше дә юкмыни соң?— Иорам-ата шундый да ихлас итеп, чын күңеленнән әйтте ки, Бачана да хәтта үзен кызганып куйды.— Күрәсең, бик күпләр шулай тинтерәтәдер сезне, күп кешегә ярдәм итәргә туры киләдер сезгә?

— Шулай, сезнең эш рәхәт, халык сезнең катыгызга тез чүгеп килә дә бары бер генә нәрсә — җаннарын гөнаһлардан йолуны гына сорый...— диде Бачана кулын селтәп.

— Күптән төштегезме инде сез шундый хәлгә?

— Газета редакторы булып эшли башлаганнан бирле... Әгәр шушыннан исән-имин котылырга язган булса, чыгуга барысына да төкерәм!.. Кешелек кыяфәтем калмады инде, атакай, ниндидер бер җәмгыяте хәйрия рәисенә әйләндем... Әле тегесе, әле бусы өчен утенә-утенә кешеләрнең теңкәсен корытып бетердем...

— Кешеләргә игелек кылу — ходай кушкан изге эш инде ул,— дип куйды рухани.

— Сезнең белән килешәм мин, гомерем буе кешеләргә яхшылык эшләргә тырыштым, тик... Ничек уйлыйсыз, менә бүгенге ханым... Кызганырлыкмы аны?

— Икейөзле, хәйләкәр бер бәндә!— диде Иорам-ата катгый итеп.

— Тәңре катына, кулына шәм тотып, рәхим-шәфкать сорарга дип әлеге ханым шикелле әрсез-хәйләкәрләр дә килеп тезләнәдер бит — андыйларга ничек карыйсыз сез?

— Сезнең белән чагыштырганда, хөрмәтле Бачана, безнең бер өстенлегебез бар: безгә килүче бит, ярдәм сорап, турыдан-туры аллаһе тәгаләнең үзенә ялвара.

— Әйе-әйе, анысы миңа мәгълүм, атакай! Сез һәр очракка да туры килә һәм берниндн җаваплылык таләп итми торган универсаль формулага таянып эш итәсез. «Ходай шулай кушкандыр!» яисә «Ходай кушмагандыр!..» дисез. Бик уңай формула! Ә без гаҗәп тә катлаулы һәм бик конкрет формулалардан чыгып эш итәргә тиешбез: «Бу эш законга сыймый!» яисә «Бусы законга каршы килми!» дибез. Аннары әле без көрәшергә дә тиешбез, аңлыйсызмы? Гыйбадәт кылырга ту-

гел, көрәшергә! Законга каршы эшләнгән эшнең тамырын корытып, законлылыкны урнаштырыр өчен көрәшергә! Гаепле кешене сез алла хөкеменә тапшырасыз, ә без — гадел хөкемгә!.. Сезнең тормыш җиңел, Иорам-атакай!..

Рухани җавап кайтармады, одеялын башыннан ук бөркәнде дә тынып калды.

— ...Әмма шулай да кеше барыбер игелек кылып яшәргә тиеш! — дип әйтеп куйды ул байтак вакыт сүзсез ятканнан соң.

— Ләкин бит тормышта син кылган яхшылыкның нинди җимеш бирәсен һәрвакыт алдан белеп бетереп булмый... Әгәр теләсәгез, үзем белән булган бер хәлне сөйләп бирәм, хәер, аны әкияткә тартымрак дисәң дөресрәк булыр...

— Сөйләгез! Рәхәтләнеп тыңлыйм! — дип, Иорам-ата, башын одеял астыннан чыгарып, тыңларга хәзерләнде.

— Беркөнне шулай секретарь кыз минем кабинет ишеген ачты да:

«Бачана Акакиевич, сезнең янга бер маймыл килгән!» — диде.

«Чакырыгыз, керсен», — мәйтәм.

Ишектән кечкенә генә бер маймыл килеп керде һәм күрешергә дип үзенең дымлы салкын кулын (ялагайлар белән алдакчы-карак бәндәләргә аеруча хас нәрсә!) сузды. Аннары минем өстәлгә берничә бит кулъязма китереп салды да, бер почмакка китеп, күзләрен мөлдерәтә-мөлдерәтә минем фикерне көтә башлады.

Мин аның кәгазьләренә күз йөртеп чыктым. Гадәттә, якшәмбе гәзитенең дүртенче битендә «Гыйбарәләр»... исемле гомуми баш астында чыга торган хикмәтле тапкыр сүз, киная, төрле мәзәк һәм дә шуның ише җыен юк-бардан тупланган бер нәрсә иде ул. Хәер, авторның маймыл икәнен искә алганда, ярый инде.

Дарвин тәгълиматы өйрәткәнчә, кайчан да булса бу маймылдан, бәлки, кеше чыгар дип, мин аның берничә гыйбарәсен газетада бастырып чыгардым. Шуларның берсе әле дә хәтердә: «Температурасы чынлап торып югары булган кеше генә безнең аптекалардан градусник эзләп азапланыр».

— Ярыйсы гына бит! — дип көлеп куйды Иорам-ата.

— Ул чакта мин дә нәкъ әнә шулай уйлаган идем... Шуннан соң маймыл минем янга тагын килде. Бу юлы

инде аны берәү дә танымады, чөнки ул кеше сыман итеп, хәтта яхшырак та киенеп килгән иде. Ул янә үзенең мәзәк һәм тапкыр сүзләрен алып килгән иде. Мин укый башладым, карасам — язу алымнары монын нәкъ теге маймылныкы кебек.

«Кара әле, күптән түгел генә монда бер маймыл килгән иде, шул син идең бит, әйеме?» — димен.

«Әйе, мин шул маймыл,— ди бу.— Минем бик тә кеше буласым килә, шул эштә миңа ярдәм итсәгез иде»,— ди.

«Ләкин бит кешене хезмәт кенә кеше иткәнлеген син белергә тиеш,— димен.— Бар, түземлегеңне җыеп бераз эшлә әле»,— дим.

«Анысы миңа мәгълүм, укыганым бар,— ди бу.— Ләкин мин түземсез маймыллар нәселеннән шул. Аннары, кешеләрнең күбесе мине хәзер үк инде адәм затыннан саный»,— ди.

«Ярар, синеңчә булсын,— мин әйтәм,— тагын бер-ике гыйбарәңне бастырдык, ди, шуннан сиңа ни файда? Син бит барыбер маймыл булып калачаксың?».

«Ә сез мине фаш итмәгез!»— дип үтенә маймыл һәм, рәхмәтен әйтеп, хушлашып чыгып китә.

— Табигатем белән игелекле кеше мин. Кызгандым бит маймылны, өстәвенә ул хәйран оста итеп кешеләргә охшатып сөйли, кылана белә иде. Кайбер «әсәр»ләрен тагын бастырдым. Әйдә, юансын, мин әйтәм, аннан безгә ни зыян? Әнә шулай итеп маймылыбыз кешегә әйләнде...

— Аның кеше түгел, маймыл икәнен шулай берәү дә сизмәдемени?— дип бүлдерде Бачананы Иорам-ата.

— Ни хикмәттер, атакай, сизмәделәр шул! Кешегә әйләнгән маймылга караганда, маймылга әйләнгән кешене танып алуы җиңелрәк, күрәсең... Әле әнә күптән түгел генә безнең зоопарктан өч маймыл качкан иде. Шул хәбәр алынгач, милициядә оператив киңәшмә җыеп, качкыннарны ничек тизрәк тотарга икән дип баш вата башлыйлар. Киңәшмә озаккарак сузылган, күрәсең. Шунда бер милиционер торып баса да: «Иптәш подполковник, эшне кыскарак тотыйк әле, маймыллар кешеләр белән аралашып китсә, үлсәң дә таба алмассың аннары!» — ди.

— Шуннан ни булган?— дип түземсезләнеп сорады Иорам-ата.

— Качакларның икесен тотып алалар, ә өченчесен әле дә булса таба алганнары юк, ди... Ярар, хикәямне

дәвам итим... Шулай итеп безнең маймыл кеше арасына керде... Берничә елдан ул тагын редакциягә килде. Бу юлы инде ул үзенең... хикәяләрен алып килгән иде. Хикәяләрен укып чыктым мин моның һәм... чәчләрем үрә торды.

«Нәрсәләр болгаттың син монда, бичара маймыл? Нинди чүп китердең син?!» — димен моңа.

«Нишләп чүп булсын,— ди маймыл үпкәләп.— Тәнкыйтьче буларак, миңа үз хикәяләрем бик ошый!» — ди.

«Ничек, син инде тәнкыйтьче булдыңмыни?» — димен мин исем китеп.

«Әйе,—ди бу вәкарь белән,— мин тәнкыйтьче, гыйльми дәрәҗәм дә бар, радио-телевидение буенча, «Белем» җәмгыятендә һәм дә бер югары уку йортында лекцияләр укыйм»,— ди.

Әлеге маймылның лекцияләрен тыңлап утыручы студентларны чын күңелдән кызгандым, ләкин нишли ала идем соң мин? Югары уку йортыннан куып-сөреп чыгарыр өчен мин кафедра җитәкчесе дә, ректор да түгелмен. Аннан соң минем моңа бернинди мораль хокукым да юк — чөнки бит әлеге маймылны кеше арасына мин үзем керттем!..

— Һич югы бит сез аның... әлеге лекторның маймыл икәнен кешеләргә әйтә ала идегез!— диде Иорам-ата кинә белән.

— Әйттем, атакай, әйттем, ләкин соң иде инде... «Син үзең маймыл!» — дип җавап бирделәр миңа.

— Шул кирәк сезгә!— диде Иорам-ата ачуы килеп.

— Сүзегез хак!— дип ризалашты Бачана.

— Шуннан нәрсә эшләдегез инде сез?— Иорам-ата чын-чынлап борчуга төшкән иде.

— Кулымнан килгәнне эшләдем инде: хикәяләрен кире үзенә кайтардым.

— Маймыл ничек кабул итте соң?

— Нишләсен, җәнҗал куптарды! Мин Язучылар союзы члены түгел, шуңа каныгасыз, ди! Союзга кереп алыйм әле менә, аннары карап карарбыз, ди!— Шунда минем «маймылның урыны Язучылар союзында түгел» дип әйтәсем бик тә килгән иде, ләкин мин дәшми калдым...

— Ни өчен сез дәшмәдегез, хөрмәтле Бачана?— дип тавышын күтәрә төште Иорам-ата.

— Чөнки минем моңарчы да аннан яманрак маймылларга рекомендация дә, тавыш та биргәнем булды!— дип, Бачана тынып калды.

— Кабат очрашмадыгызмы?— дип сорады Иорам-ата бераз тынычлана төшкәч.

— Очрашмыйча соң! Ул Язучылар союзына керде, хәтта дуслашты да минем белән. Минем сәламәтлек өчен тост күтәргәндә «минем атам» дип хөрмәтли иде... Ә соңыннан, минем кандидатураны депутатлыкка күрсәткәч, райком секретаре янына махсус барып, рәхмәт әйтеп кайткан.

— Шаяртмагыз инде!

— Чәчрәп китим! Секретарь янына кергән дә бу әйткән ди: «Грузин язучылары исеменнән, күп санлы укучылар, безнең өчен кадерле булган Бачана Рамишвили эшләгән газета редакциясе хезмәткәрләре һәм дә аның бик күп дуслары исеменнән сезгә, хөрмәтле Николай Петрович, аңа күрсәткән ышанычыгыз өчен ихлас күңелдән зур рәхмәтләремне белдерәсем килә. Сезнең кебек принципиаль, тәвәккәл йөрәкле, вөҗданлы коммунист кына Бачана Рамишвилиның үткәнендә казынып тормастан, аның кешелек сыйфатларыннан, бүгенге көндә күрсәткән хезмәтләреннән чыгып фикер йөртә ала...» ди икән.

«Аның үткәненә ни булган?»— дип сораган гаҗәпкә калган райком секретаре.

«Алай искитәрлек берни дә юк! Мәсәлән, заманында Рамишвилиның ата-анасы репрессияләнгән булуы, яшь чагында аның үзенең дә күпмедер вакыт... дөрес, хаталанып кына... утырып чыгуы кебек җыен юк-бар фактларны игътибарга алып маташмавыгыз бик тә куандыра, әлбәттә... Анкета — анкета инде ул, үзегез беләсез... Яисә, әйтик, күптән түгел генә Рамишвили редакцияли торган газетада «большевик» диясе урынга «меньшевик» дип басылган иде... Әйе, нәкъ менә шундый вак-төяк фонында сезнең кешелекле, нык принципиллы булуыгыз күренә дә инде! Шуның өше фактларга күз йомып, әлегә яшь, тәҗрибәсез һәм дә әллә ни күп хезмәт күрсәтергә өлгермәгән кешегә ышаныч һәм өметләр баглап, шундый зур тәвәккәллек кылу — сезнең кебек нык принциплы, тәҗрибәле җитәкченең кулыннан гына килә торган эш, хөрмәтле Николай Петрович. Сез кылган яхшылыкны тиешенчә бәяләр өчен мин хәтта сүз таба алмыйм. Рәхмәт, тагын бер кат рәхмәт сезгә!»— дип әйткән маймыл райком секретарена...— дип Бачана үзенең хикәясен тәмамлады.

— Кайда соң ул хәзер?— дип сорады Иорам-ата авыз-теле бәйләнеп.

— Анысын әйтә алмыйм... Хәер, белмәссең, бәлки әле иртәгә хәл белергә дип килеп чыгуы да бик ихтимал...

13

Бачананы партия сафына членлыкка кандидат итеп алу мәсьәләсен райком бюросына куйганчы, аны райкомга әңгәмәгә чакырдылар.

Бачана парткабинетка керде, озын өстәл артында утырган өч ир кешегә башын иеп сәлам бирде дә өстәлнең бирге башына килеп урнашты.

— Иптәш Рамишвили, безнең беренче әңгәмәбез күпмедер формаль төс алып тора. Аның максаты бер: үз сафларына алынасы кешенең кем булуын партия яхшы белергә тиеш. Шул сәбәпле, әгәр сез каршы килмәсәгез, без сезгә берничә сорау бирер идек. Бәлки әле, сезнең дә безгә соравыгыз бардыр,— диде өстәл артында уң кулда утырган һәм алдына Бачананың шәхси делосын ачып куйганы.

— Рәхим итегез, зинһар, ничек тиеш, шулай эшләгез,— дип җавап бирде Бачана, йөрәгенең ашыгып-ашыгып тибә башлавын тойган хәлдә. Әлеге әңгәмә кайсы ягы беләндер имтихан алганны хәтерләтә иде, ләкин бер аермасы бар: өстәл артында утыручылар теләсә кайсы фәнгә кагылышлы сорау бирә алалар иде.

— Иң элек танышып үтик. Без — карт бльшевиклар. Минем исемем — Александр, фамилиям — Иорданишвили,— диде әңгәмәне башлаучы ир кеше.— Ә алар — минем дусларым Вано Бандзеладзе һәм Давид Манагадзе.

— Бик шатмын, исәнмесез!— диде Бачана урыныннан күтәрелеп.

— Утырыгыз, зинһар,— диде Иорданишвили. Шадра йөзле, кәкрерәк борынлы, коңгырт-кара күзле бу кешенең калын тавышы каяндыр тирәннән, күкрәк түреннән үк чыга иде.— Мине менә нәрсә кызыксындыра: ни өчен сез моңарчы партиягә кермәдегез?

Бачана бу сорауны көткән иде, әлбәттә, һәм аның андый очракта әйтелә торган шаблон җавабы да әзер иде: имеш, моңарчы андый җаваплы, зур эш өчен үзен әзер түгел дип саный иде, инде менә хәзер, төпле, нигезле итеп үзләштергәннән соң... һәм башкалар... Ләкин ул бөтенләй башкача җавап бирде:

— Чөнки моңарчы мине кабул итмәделәр!

— Ни сәбәпле?— дип сорады аннан Бандзеладзе исемлесе: кызгылт йөзле, җәенке борынлы, кечкенә йөгерек күзле кеше. Бачана аның күзләренең нинди төстә булуын һич кенә дә аера алмады.

— Гаризада барсы да язылган анда...

Иорданишвили, алдында яткан шәхси делоны ачып, Бачананың гаризасына күз йөртеп чыкты, әмма бер сүз дә әйтмәде.

— Минем ата-анам репрессияләнгән иде...— дип өстәде Бачана.

— Аларның гаепсез булуы исбат ителгән хәзер,— диде Иорданишвили, дусларына карап алып.

— Комсомолга ничек кабул иттеләр соң сезне?— дип кызыксынды Манагадзе, Кавказ овчаркасыныкы сыман куе чәчле дәү башын Бачанага борып. Аның күзләре искиткеч ягымлы итеп, игътибар белән карыйлар иде.

— Ата-анамның кулга алынуларын яшердем мин...

Өстәл артында утыручылар гаҗәпләнеп бер-берсенә карашып алдылар.

— Анысы шулайдыр, тик... Бу турыда мәктәптә белмиләр идемени?— дип сорады Манагадзе.

— Беләләр иде. Комсомол комитеты секретаре да белә иде.

— Шулай да дәшми калдымы?

— Әйе.

— Ни өчен?

— Ул минем якын дустым иде... Аннары, авыр сугыш еллары иде... Ул елларда комсомолга болай гына, комсомол булу өчен генә кермиләр иде... Дустым ул турыда белә иде...

— Тагын кем белә иде?

— Барсы да... Райкомнан башкалары...

— Һәм берсе дә серне чишмәдеме?

— Әйе, берсе дә ялгыш кына да ычкындырмаган!— дип, Бачана өчен Иорданишвили үзе җавап бирде һәм шәхси делоны бер читкә этәреп куйды.

— Ничек уйлыйсыз, әгәр сезнең ата-анагызның репрессияләнгән булуын белсәләр, комсомолга алырлар идеме?

— Юк, алмаслар иде!

Бүлмәдә бер мәлгә тынлык урнашты.

— Әйтегезче,— дип тынлыкны бозды Бандзеладзе,— хаксызга гаепләнгән ата-анагыз өчен рәнҗедегезме сез, шул рәнҗү күңелегездә һаман яшиме?

Бачана, әлбәттә, үзенең «юк-юк, нинди рәнҗү ди ул, мөмкинме соң» дип кире кагарга тиешлеген аңлый иде, ләкин ул дөресен әйтергә булды:

— Әйе, рәнҗедем!— диде ул, калтыранган куллары белән тартмадан папирос ала-ала.

— Миңа да бирегезче!— дип, дулкынланып кулын сузды Манагадзе. Бачана аңа папирос тартмасы белән шырпы сузды.

— Ә соңыннан... рәнҗүегез беттеме соң?..— дип сорады Бандзеладзе, тартмадагы папироска үрелеп.

— Әйе, бетте... Ләкин байтак еллар үткәннән соң кабат уянды,— дип, Бачана папиросын кабызды.

— Кайчан инде ул?

— Реабилитация булганнан соң... Ата-анам исеменә ягылган нахак гаепне алып ташлаганнан соң мин шатлана алмадым, киресенчә, күңелдә ачу катыш рәнҗү генә кузгалды...— Бачана папиросын сүндерде һәм шунда ук икенчесен кабызды.— Чөнки ничәмә-ничә еллар буена бер гаепсезгә күпме хәсрәт, ким-хурлык, мохтаҗлыклар кичердек без...

— Ата-анагыз кайда хәзер?— дип сорады Иорданишвили.

— Дөньяда юк инде алар...

— Нинди уй-тойгылар белән керәсез инде сез хәзер партиягә?— диде Бандзеладзе.

Бачан уйга калды. Бандзеладзе исә, папиросын чәйни-чәйни, борчылып, соравына җавап көтте. Тынлык озаккарак сузылды. Ниһаять, Бачана сүзен башлады:

— Мәгълүм булганча, кешелек тарихында ышануы авыр булган парадоксаль нәрсәләр байтак... Кешеләргә, гомумән, ирекле баштанмы, ирексездәнме хаталану хас. Аннан соң алар хаталарын төзәтергә тотыналар: кайберләре иртәрәк, кайсыберләре соңгарыбрак төзәтә. Кайсылары кылган эшләренең дөреслегенә үлгәнче ихлас күңелдән ышанып яши... Алар ясаган хатаны инде киләчәк буынга төзәтергә кала... Минем җанны имгәткән кешеләр исә тиешле җәзасын тулысынча алдылар, хәер, алар хәзер дөньяда юк инде... Хәзер ил белән идарә итәргә безнең буын, минем яшьтәшләр килә. Һәм минем нindидер үч алу турында уйларга хакым юк. Киресенчә, шушындый аяныч хәлләр яңадан кабатланмасын өчен генә дә, мин алар белән бер сафка басарга тиешмен. Чөнки мин алар эшенең хаклыгына ышанам һәм аны үз эшем дип саныйм... Аннары тагын бер мөһим ягы бар: язучы кешенең субъектив булырга хакы юк!

Әгәр ул объективлык тойгысын югалта икән, аның бар иҗаты сукыр бер тиенгә дә тормый!

Бандзеладзе җаваптан канәгать булып башын кагып куйды, Иорданишвили исә икенче сорау бирде:

— Владимир Ильич Ленинның Әзербайҗан, Грузия, Әрмәнстан, Дагъстан һәм Тау республикасы коммунистларына язган хаты белән танышмы сез?

Бачана озак кына уйланып торды да:

— Хөрмәтле Александр, иптәш Ленинның әле сез әйткән һәм башка хатлары белән таныш булмасам, мине партиягә алачакларммы?— дип сорады.

Көтелмәгән сораудан Иорданишвили сүзсез калды. Бачана исә сүзен дәвам итте:

— Сез миннән үзегезгә мәгълүм булган нәрсәләр турында гына сорыйсызмы, әллә инде мин белергә тиешле нәрсәләр турындамы?

— Мин сезнең белүегезне теләгән нәрсәләр турында сорыйм, иптәш Рамишвили... Әлеге хат безгә һәм безнең дусларга дип язылган...

Бачана уңайсызланып китте. Ул, нидер әйтергә теләп, аягына торып басты, ләкин Иорданишвили аннан өлгеррәк булып чыкты:

— Сау булыгыз, иптәш Рамишвили!— диде ул урыныннан күтәрелеп.

Бачананың күңеле шомланып-сискәнеп китте... Башыннан «Барсы да бетте!» дигән куркыныч уй чагылып үтте һәм шунда ук чәнчеп йөрәге авыртырга кереште. Ул кире урынына утырды, кулы белән йөрәген тотты.

— Ни булды сезгә?— дип борчылып сорады Манагадзе.

Бачана ничек кирәк алай урыныннан кузгалды.

— Зыян юк, хөрмәтле Давид, хәзер үтәр... Инде үтте дә менә!— диде ул елмаеп.

— Иртәгә көндезге бердә сезнең мәсьәлә бюрода каралачак. Барсы да әйбәт булыр дип уйлыйм мин... Ә теге хатны сез, шулай да, тагын бер кат күздән кичерегез, әгәр вакытыгыз булса, әлбәттә...— дип киңәш итте Иорданишвили.

— Хөрмәтле Александр!— «Әзербайҗан, Грузия, Әрмәнстан, Дагъстан, Тау республикасында яшәүче коммунист иптәшләргә» исемле хатны Ленин 1921 елның 14 апрелендә язган, шул ук елның 8 маенда ул «Правда Грузии» газетасының илле бишенче санында басылып чыккан...

— Әкәмәт сәер кеше сез, Рамишвили!— дип көлемсерәп куйды Иорданишвили.— Ярый, сау булып торыгыз!

— Сау булыгыз һәм зур рәхмәт сезгә!— дип, Бачана һәркайсына кулын биреп хушлашты да парткабинеттан чыкты.

Көндезге сәгать бердә Бачананы беренче секретарь кабинетына чакырдылар. Ул кабинетка керде, өстәл тирәли утырган бюро членнарына баш иеп сәлам бирде һәм «боларның кайсысына утырырга икән, әллә мондый очракта, гомумән, утырырга ярамый микән» дип, стена буйлап тезелеп киткән урындыкларга күз салды. Шулчакны:

— Рәхим итеп утырыгыз!— дигән таныш тавыш яңгырады.

Бачана башын күтәрде һәм бары шунда гына яшь райком секретарен күреп алды. Ул, уң күзен кыса төшеп, елмаеп Бачанага карап тора иде. Бачана урындыклар рәтенең урта бер җиренә килеп утырды.

— Аңлатып торуның кирәге юктыр дип уйлыйм,— дип, секретарь урыныннан күтәрелде,— Бачана Рамишвилины без барыбыз да беләбез. Бүген ул безнең зур гаиләбезгә аяк баса... Сезне гариза, анкета һәм рекомендацияләр белән таныштырып үтим...

— Укып тормасагыз да ярый!— диде арадан кемдер.

Секретарь Бачананың шәхси делосын читкә алып куйды да кабинеттагыларга мөрәҗәгать итте:

— Кемнәрдә сораулар бар?

— Минем соравым бар!— диде шунда бюро членнарыннан берсе.

Бачана эсселе-суыклы булып китте.

Секретарь беркадәр гаҗәпсенебрәк аңа карап алды.

— Рәхим итегез!

Кабинетта бер мәлгә тынлык урнашты, ләкин шушы кыска гына вакыт Бачанага бик озак кебек тоелды.

— Иптәш Рамишвили, сез ни өчен партиягә керәсез, шуны әйтсәгез иде?

Һәммәсе Бачанага таба борылдылар. Ул аягүрә торып басты, яулыгы белән битен сөртеп алды да җавап бирергә хәзерләнде, ләкин соңгы минутта кире уйлады. Бачана Рамишвилины коммунистлар партиясе сафына алыргамы, юкмы икәнлеген хәл итәргә җыелган кешеләргә нәрсә дип әйтергә тиеш соң ул? Андый очракта

нәрсә әйтелергә тиешлеген Бачана, әлбәттә, белә иде: имеш, ул партиянең Программа һәм Уставы белән тулысынча килешә, имеш, ул партия кушканны тайчанмыйча үтәргә, кирәк икән партия эше өчен гомерен дә кызганмаска һәрвакыт әзер, имеш, аның коммунистик җәмгыятьне актив төзүче буласы килә... Әйе, боларның барысын да ул яттан белә иде, ләкин менә шушы минутта әзер җавапны кабатлау аңа соң дәрәҗәдә кирәкмәгән, көлке бер нәрсә кебек тоелды... Чөнки әлеге санап чыккан эшләрне башкарыр өчен генә коммунист булу зарур түгел. Аннан соң, бюродагылар арасында Бачанага каршы килердәй кеше дә юк иде сыман... Шунда ул һич көтмәгәндә:

— Партия сафында намуслы кешеләрнең күбрәк булуын телим!— диде дә урынына утырды.

Кабинетта, йомшак җил исеп үткәндәй, гаҗәпсенеп пышылдашып алдылар. Аннары тирән тынлык урнашты. Бачана башын игән килеш утыра бирде. Бераздан ул секретарьның тавышын ишетте:

— Иптәшләр, Бачана Рамишвилины мин балачактан беләм һәм шуңа күрә һич икеләнмичә «башыннан аягына кадәр коммунист ул» дип әйтә алам. Мин аны коммунист дип саныйм һәм аның кандидатурасын яклыйм. Бачана Акакиевич Рамишвилины Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафына кандидат итеп алырга дигән кешеләрнең кул күтәрүләрен сорыйм.

...Шулчакны, моңарчы әле, мөгаен, бер генә партия тарихында да күрелмәгән хәл булды: башкалар белән беррәттән Бачана Рамишвили үзе дә кул күтәрде.

14

Тбилисидә инде ике көн тоташтан ишелеп-ишелеп йомшак коры кар ява. Шәһәр урамнарында транспорт хәрәкәте тукталды. Әйләнә-тирә кемнәрнендер, бозлавыкка таеп китеп, куркынып чәрелдәшкән тавышларына, кызлар чыркылдашуына, кар атышып уйнаучы егетләрнең айгылдап көлешкән күңелле шау-шу авазларына күмелеп калды. Һавалар чистарып, искиткеч сафланды, гаҗәеп рәвештә татлы булып хушланып калды. Кар кызы сыман актан киенеп алган Тбилиси, вакытыннан элек чаларган чәчләре белән мактанып, үз урамнары буйлап үзе кәефләнеп йөридер кебек иде

Кичке сәгать унынчы иде инде. Бачана, бер уйсыз диярлек, кулларын кесәсенә тыгып, пальто якасын ку-

тәргән килеш, чәнчеп-чәнчеп битенә орынып киткән тылсымлы кар пәрдәсе аша, ашыкмый гына Вакэ паркы буйлап кайтып килә иде. Мосашвили урамы чатында ул почмактан капыл гына килеп чыккан бер хатын белән бәрелеште. Көтелмәгән бу хәлдән икесе дә бердән сискәнеп киттеләр һәм, тиз генә аңыша алмыйча, шулай беркавым бер-берсенә терәлешкән килеш тукталып калдылар. Бачана әлеге ханымның очкынланып янган зур күзләрен күреп өлгерде. Икенче мизгелдә инде ул җәһәт кенә читкә тайпылды һәм, аңа юл биреп, гаепле кыяфәт белән:

— Кичерегез, зинһар, калбатоно!— диде, ләкин алай эндәшер өчен ханым аңа артык яшь кебек тоелды, ахры, Бачана шунда ук:

— Гафу итегез, туташ!— дип өстәде.

— Зыян юк, булгалый!— диде ханым тыныч кына һәм үз юлы белән китә башлады.

Бачана, ерагая барган хатын артыннан караган килеш: «Әгәр дөньяда эчке сизенү һәм гаделлек дигән нәрсә бар икән, ул әйләнеп карарга тиеш!» дип уйлап куйды. Һәм, ни хикмәттер, ханым борылып карады. Бачана, шуны гына көткән сыман, әкрен генә аңа таба атлап китте, ханым да Бачанага каршы килә башлады. Кара-каршы килеп җиткәч, алар икесе дә туктап калдылар, һәм шунда Бачанага кинәт сулышына һава җитми башлады:

— Исәнмесез!— диде ул тыны кысылып.

— Исәнмесез!— дип кулын сузды хатын.

Бачана, ашыга-кабалана кулындагы перчаткасын йолкып салып, ханымның кулын эләктереп алды. Аның кулы йомшак, җылы иде. Бачана әлеге билгесез хатынның күзләренә карады: ахры, ул да дулкынлана иде.

— Кая барасыз сез?— дип, теленә килгән беренче сорауны бирде Бачана.

— Өйгә кайтам,— диде хатын, кулларын тун кесәсенә тыгып.

— Сез шундый чибәрсез!— дип куйды Бачана һәм кызарынып китте.

— Беләм,— диде хатын тыныч тавыш белән.

— Үзеңнең чибәрлегеңне тоеп йөрү, мөгаен, бик рәхәттер ул, әйеме?

— Кем белгән аны!— дип иңнәрен җыерды хатын.

— Әлбәттә, рәхәттер! Мәсәлән, мин үзем чибәр ханымга карап торырга бик яратам!— дип остара бирде Бачана.

— Шулай икәне сизелә!— диде ханым елмаеп.

— Бәлки мин үземнең соклануымны сөйләп сезнең вакытыгызны аламдыр?— дип исенә килде Бачана.

Ханым исә, «юк» дигәнне аңлатып, башын чайкады.

— Сез Бачана Рамишвилига бик нык охшагансыз,— диде ул.

— Әйе шул, бик нык!— диде Бачана куанып һәм аның күңеле горурлык хисе белән тулды.

— Сезгә башкалар да шулай дип әйтәме?

— Бар танышларым да диярлек!

— Нинди гаҗәеп охшашлык!

— Әйе, без аның белән шул дәрәҗәдә охшашканбыз, хәтта минем паспортымда да Бачана Рамишвили дип язылган!— дип көлеп җибәрде Бачана.

Ханым аңа шикләнеп карап куйды.

— Кая, фуражкагызны салыгыз әле!

Бачана, кар сарган фуражкасын салып, тезенә каккалады.

— Ай аллам!— дип кычкырып җибәрде ханым.— Сез чыннан да Бачана Рамишвили ич!

— Сезнең исемегез ничек, чибәр кыз?— дип батыраеп сорады Бачана.

— Минем кызым Майя исемле...

Бачана бер мәлгә каушап калды.

— Аңа әле бер генә яшьтер, әйеме?— диде ул уңайсызлануын сиздермәскә тырышып.

— Унҗиде инде!— диде ханым.

— Мөмкин түгел!

— Кызым Майя белән ант итәм!

— Ә сезнең исемегез ничек?

— Мария.

— Сез бик чибәрсез, Мария!

— Сез дә...

Бачана кызарынып китте:

— Булмаганны...

— Кызым Майя белән ант итәм!— дип кабатлады ханым.

— Йә сезнең кызыгыз юк, йә сезнең ант итүгез чын күңелдән түгел,— диде Бачана кәефе кырыла төшеп.

— Юк, мин дөресен сөйлим!— диде ханым җитди итеп һәм кырт кына борылды да килгән юлыннан китеп барды.

— Туктагыз әле!— дип кычкырды Бачана. Ханым туктады.— Озатып куйыйм мин сезне!

— Мин бик ерак яшим.

— Кайда?

— Воронцов купере янында.

— Әйе, ераграк икән шул. Озатып куярга рөхсәт итегез...

— Юк, минем ялгызым гына кайтасым килә!— дип, ханым, сөйкемле йөзен кар бөртекләренә каршы куеп, башын югары чөйде.

— Курыкмыйсызмы соң?

Ханым «юк» дип башын чайкады да китеп барды.

Бачана, ерагая барган ханымнан күзен ала алмыйча, байтак шулай сокланып карап торды. Аның адымнары иркен, йөреше горур иде. Якалары кыршылган иске кыска туны да, тапталган итекләре дә аның сылу-зифа гәүдәсенең мәһабәт бер матурлыгын боза алмый иде. Ханым, урам чатына җитеп, күздән югалгач кына Бачана айнып киткәндәй булды.

— Менә тиле! Ичмасам фамилиясен генә булса да сорыйсы калган!

Ул томырылып Чавчавадзе проспектына йөгереп чыкты, ләкин ханым беркайда да күренмәде. Ул, кайнар уч төбенә кунган кар бөртегедәй, эреп юкка чыккан иде...

Бачана өенә кайтты. Өстендәге карны каккалап, ишек төбендәге җәймә астыннан ачкычын эзләп тапты, ишекне ачып бүлмәсенә керде һәм, гомерендә беренче тапкыр, үзен чолгап алган куркыныч, чиксез бер бушлык тойды.

15

Ул көнне Бачана йомыш белән килгән ике кешене кабул итте: аларның берсе камил акыллы булып, икенчесе акылга зәгыйфьрәк бер адәм иде. Хәер, моның шулай икәнлеге соңыннан гына беленде, башта исә алар икесе дә Бачанага гадәти кешеләр кебек тоелган иде.

Бачана үзенең бүлмәсендә, эш өстәле артында, тире эшкәртү комбинаты директорының караңгы эшләре, аның тотнаксыз, бозык бер кеше булуы, башбаштаклыгы турында язылган фельетонны төзәтеп утыра иде. Фельетон ярыйсы ук усал һәм оста язылган иде. Сүз дә юк, иртәгә чыгасы газета санында ул иң төп мәкалә, шаккатыргыч яңалык булырга тиеш, шуңа күрә аның турында әлегә Бачана белән автордан башка берәү дә белми иде. Фельетон дөреслектән шактый ерак тоелган бер вакыйганы бәян итүдән башланып китә иде...

...Халыкара вагонда, купеларның берсендә ике ханым утырып бара. Алар шундук танышып китәләр, һәм

озакламый ике арада күктәге йолдызларга үрелми, җирдә яшп торган кешеләргә хас гадәти әңгәмә башлана. Уртак танышларының һәм моңарчы бөтенләй дә таныш булмаган кешеләрнең гайбәтен чәйнәп, республикадагы бик тә мөхтәрәм бер кешенең ишек өстенә кызыл фонарь элгәннән соң, әлеге ханымнарның берсе, кинәт тыны кысылып, буыла-буыла ютәлләргә тотына. Ашыга-кабалана килеп җиткәч врач, авыру ханымны ничек кирәк алай һушына китергәннән соң, «Шулай кинәттән генә ни булды сезгә?» дип сорый. Тәмам хәле киткән хатын, күршесенең туныңа күрсәтеп:

— Мәче... тиресе...— дип ыңгыраша.

— Нәрсә тиресе?— дип сорый врач аңышмыйча.

— Аллергия... Мәче тиресеннән аллергия миндә...

— Аңлашылды... Болай булгач, тунны купедан чыгарырга туры килер...

— Сез нәрсә, акылдан яздыгызмы әллә?— ди шунда тун хуҗасы, шартлап ярылырга җитешеп,— нишләп мәче тиресе булсын ди ул?! Кеш тиресеннән тегелгән тун ич ул! Аның өчен мин дүрт мең ярым түләдем!..

— Күпме генә түләсәгез дә, тунны берничә минутка булса да чыгарып торырга туры килер...

Байтак тарткалашканнан соң, ахырда, проводник тунны купедан алып чыгып китә. Авыру хатын шундук иркенләп тын ала, ютәле дә басыла...

Вакыйга әнә шуннан башланып китә... Шулай итеп, поездда очраклы рәвештә җеп очыннан тартылган йомгак тәгәрәп китә һәм, тәгәри торгач, мех эшкәртү комбинатына җитеп туктый. Йомгакка ияреп, тимер юл транспортына һәм медицинага һич кагылышы булмаган, ләкин тиренең сортын, бәясен гаҗәп яхшы аңлаган кешеләр калкып чыга...

...Инде менә хәзер шул комбинатның директоры, май баскан күзләре белән елмаеп, Бачана каршында басып тора. Аның кем булуын Бачана әлегә белми иде, әмма чапмаган-юынмаган, авыр гәүдәле бу кешенең бөтен кыяфәтеннән үз-үзеннән канәгать икәнлеге, оятсызлыгы-эрсезлеге бөркелеп тора иде.

— Исәнмесез!— диде ул һәм, урын тәкъдим иткәнне дә көтмәстән, Бачана өстәле каршындагы креслога килеп утырды.

Бачана, фельетонны бер читкә куеп, тыңларга әзерләнде, әмма керүче кеше сүзсез утыра бирде. Шул рәвешле берәр минут чамасы үтте.

— Тыңлыйм сезне!— диде ниһаять Бачана.

— Юк, киресенчә, мин сезне тыңламакчы булам!— дип елмайды керүче.

— Аңламыйм...

— Мин — тире эшкәртү комбинаты директоры!— диде керүче кеше, төссез саргылт күзләрен Бачанага төбәп.

«Күрәсең, моның үт капчыгы авырудыр»,— дип уйлап куйды Бачана һәм:

— Фамилиягез ничек сезнең?— дип сорады.

— Сандро Маглаперидзе. Минем фамилия сезгә таныш булырга тиеш!— диде әлеге кеше карлыккан калын тавыш белән.

— Беренче тапкыр ишетүем!— дип алдашты Бачана.— Хәер, анысы мөһим түгел. Нинди эш буенча килдегез? Мин сезне чакырмаган идем кебек...

— Минем комбинат тирәсендә купкан ыгы-зыгы хакында сөйләшмәкче идем... Киңәш йөзеннән шуны әйтәсем килә: эшнең асылына төшенмәгән ахмакларның лыгырдавына колак салмасагыз иде сез... Әгәр нәрсәдер кызыксындыра икән — туп-туры үземнән сорагыз!— диде Маглаперидзе акыл өйрәткән тавыш белән.

— Нәрсә турында сөйләгәнегезне аңламыйм... Мин бернәрсә дә белмим...— дип салкын гына җавап бирде Бачана.

— Барын да беләсез сез... Кызганычка каршы... Шул ук минем хезмәткәрләрдән... Ярар, алар белән мин исәп-хисапны үзем өзәрмен...

« Оятсыз адәм! Ничек сөйләшә бит минем белән!»— дип күңеленнән ярсынып уйлап куйды Бачана, әмма үз-үзен кулга алды һәм тыныч тавыш белән:

— Кабатлап әйтәм, нәрсә турында сөйләгәнегезне төшенмим... Бәлки аңлатыбрак әйтерсез?— диде.

— Рәхим итегез! Ләкин мин сезгә мәгълүм нәрсәләр турында түгел, бәлки үземә мәгълүм булганнары турында сөйләргә җыенам.

— Тыңлыйм сезне.

— Сезнең газетаның иртәгәге санында «Мәче тиресе ябынган батыр» исемле баш астында фельетон басылып чыгарга тиеш. Дөресен әйткәндә, әлеге мәгънәсез фельетонның авторына бөек Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»ын уку бер дә зыян итмәс иде. Анда, әйтергә кирәк, бик тә гыйбрәтле сүзләр бар:

Кеше тиеш гомер юлын дуслар белән үтәргә,
Егетлекме — ашыкмасаң дуска ярдәм итәргә?!

Аннары тагын мондый сүзләр дә бар:

Роза гөле, ямьсезләнеп, беркөн кибеп шиңеп бетсә,
Ул картайган гөл урнына, тишелеп чыгып, яшь гөл үсәр...

— Бу шигъри юллар сезгә, әлбәттә, таныштыр,— дип елмаеп өстәде Маглаперидзе.

— Мине эшемнән алырга җыенмыйсыздыр бит?— дип Бачана да елмаеп җавап бирде.

— Нәрсә сөйлисез сез, хөрмәтле Бачана! Минем бары сезне кисәтеп куясым гына килә: югарыда, безнең комбинат белән җитәкчелек итүче кешегә, иртәгәне санда басыласы фельетон ошар дип уйлыйсызмы?

— Фельетонның эчтәлеге кайдан таныш сезгә?

— Таныш инде менә, хөрмәтле Бачана... Фельетонда минем турыда, имеш, ул туймастамак, алдакчы, имеш, аның сөяркәсе бар диелгән... Аннары анда аллергия белән авыручы бер хатын, ниндидер тун турында кәмит сөйләнә... Кыскасы, бераз үзегез турында да уйласагыз иде, хөрмәтле Бачана. Утырган урындыгыгыз сез уйлаганча ук нык түгел дияр идем мин... Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтүем...

Бачана ачуыннан кызарынып чыкты, шулай да мөмкин кадәр тынычрак күренергә тырышып:

— Нинди киңәш бирмәкче буласыз соң сез миңа, иптәш Маглаперидзе?— дип сорады.

— Иң әүвәл — сез тынычланыгыз. Хәер, яшермим, үзем дә дулкынланам мин... Әйе, менә шушылай, сезнең катка килеп баш ору минем өчен зур түбәнлек! Андый чакта мин, гадәттә, редактор янына бухгалтерларымны җибәрә торган идем... Редактор янына гозер белән беренче килүем! Шуны исегездән чыгармагыз!

— Хөрмәтегез өчен рәхмәт!— дип баш какты Бачана.

— Мыскылламыйча гына сөйләшеп булмыймы, хөрмәтле Бачана? Сезне хөрмәт иткәнгә күрә килдем мин монда... Аңа китсә, кешедән көләргә мин үзем дә бик оста...

— Ул чагында сез вакытыгызны юкка әрәм итәсез!— дип җавап кайтарды Бачана.

— Фельетонны алып ташларга кирәк!— диде Маглаперидзе катгый итеп.

— Анысы булмас!

— Сезгә телефоннан бер кеше шылтыратып әйтер, аңа инде карышып маташу...

— Ник шунда ходай тәгалә үзе килми! Иртәгә чыгасы сан инде җыелган, ә аны тоткарлау хөкүмәткә илле

мең сумга төшәчәк... Шулай булгач, бу әңгәмәне бетерик...

— Күпмегә?— дип көлеп җибәрде Маглаперидзе.

— Илле мең сумга!— диде Бачана басымлап.

— Ул зыянны мин үзем каплыйм.

— Хөкүмәт синең хәер-сәдакаңа калмаган!

— Хөкүмәт дигәнең, кадерлем, нәкъ менә сезнең белән минем ише кешеләрдән тора инде ул. Әгәр дә без бер-беребезгә ярдәм кулы сузмасак, хөкүмәт җимерелер иде! Ничек шуны аңламыйсыз сез?

Битенә олтан каплаган бу затның үз-үзеннән бик канәгать бер чырай белән туктаусыз елмаеп утыруы Бачананы тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Әгәр сез бер-береңә ярдәм итешүне төрле алдау-йолдауларга, караклыкка юл кую дип аңлыйсыз икән, нык ялгышасыз, хөрмәтле Сандро! Бар нәрсәне дә акчага сатып алып булмый!

Маглаперидзе урыныннан торып басты.

— Тәҗрибәсе булмаган яшь этәч сез, хөрмәтле Бачана. Сез әле кычкырырга өйрәнеп кенә киләсез. Карагыз аны, тәпиегезгә типке чыкмас борын тавышсыз кала күрмәгез!

— Киңәшегезне истә тотарга тырышырмын!

— Шуны да онытмагыз: «...кешедә, мәгълүм булган биш тойгыдан тыш, тагын берсе, алтынчысы яши, шул тойгы булмаганда, бөтенесе бер тиенгә дә тормый»,— ди Моэм.

— Алтынчы тойгы дигәнегез нәрсә инде ул?— дип көлемсерәде Бачана.

— Акча ул, хөрмәтле Бачана, акча!— диде Маглаперидзе һаман да шул канәгать елмаюы белән.

— Ләкин, ничек кенә булмасын, иртәгә иртән фельетон газетада басылып чыгачак, тиешле органнар инде аннары чарасын үзләре күрерләр.

— Редакция әлеге органнардан җавап килгәнне көтәчәкме?

— Әлбәттә!

— Кызганам мин сезне, хөрмәтле Бачана, чын күңелдән кызганам!

Шулай дип, Маглаперидзе ишеккә таба атлады.

Бачана аның артыннан: «Адәм актыгы!»— дип кычкырмакчы иде, ләкин комбинат директоры ул уйлаганнан җитезрәк булып чыкты — бусаганы атлауга шалт итеп ишекне ябып өлгерде.

Берәр сәгатьтән, Бачананың тынычланганын гына көтеп торган кебек, бүлмәгә икенче берәү йомыш белән килеп керде. Әлеге кешенең мөгамәләсе хәтәр әдәпле булып, килеш-килбәте дә мәһабәтле күренә, акыллы күзләреннән игелек нуры сирпелә сыман иде.

— Исәнмесез, хөрмәтле редактор!— диде ул.

Бачана, аягүрә басып, керүчегә кул бирде, урын тәкъдим итте. Тегесе, рәхмәт әйтеп, эшләпәсен салды, аны, портфеле белән бергә, янәшәдәге өстәл өстенә куйды һәм бары шуннан соң гына күрсәтелгән урынга килеп утырды.

— Таныш булыйк: Үзәк статистика идарәсе хезмәткәре, Галактион Георгиевич Мтварадзе!

— Бик шатмын... Нинди йомышыгыз төште?

— Сезне борчып, кадерле вакытыгызны алуым өчен, зинһар, гафу итегез... Ләкин, сезнең игътибарлы кеше булуыгызны белгәнгә күрә, ярты гына сәгатькә тоткарларга батырчылык итәм...

— Рәхим итегез, бер сәгатькә дә риза!

— Сезне әлеге сәер, кабатлап әйтәм, сезнең өчен сәер тоелган вакыйга белән бимазалап маташмас өчен, турыдан-туры фактларны бәян итүгә күчәм. Тик, зинһар өчен дим, мине бүлдермәгез һәм кирәк-кирәкмәскә сораулар бирмәгез. Шулай ук секретарегызны да алдан кисәтеп куегыз, әңгәмә вакытында бүлмәгә берәүне дә кертмәсен.

Бачана, кыңгырау төймәсенә басып, секретарен чакыртты.

— Елена Сергеевна, мин бүлмәдә юкмын. Ярты сәгатьтән булачакмын,— диде ул.

Секретарь «аңладым» дип башын какты да ишекне ябып куйды.

— Тыңлыйм сезне!— диде Бачана керүчегә мөрәҗәгать итеп һәм кулына карандашын алды.

— Юк, юк, зинһар, язып бармагыз!

Бачана карандашын кире куйды .

— Димәк ки, озын сүзнең кыскасы шул: мин — гуманоид!

Бачана дерт итеп сискәнеп китте:

— Ничек? Нәрсә дидегез?

— Әйе, мин — гуманоид!— дип кабатлады Мтварадзе.

Бачана шунда барысын да аңлап алды. Ләкин, бүлдермичә тыңларга сүз бирүен уйлап, тешен кысып, түзәргә булды.

— Аңлашылды, зинһар, дәвам итегез!— диде ул.
— Без, Гомос планетасында яшәүчеләр, Җиргә Андромеда Томанлыгыннан килдек һәм бирегә тереклекнең беренче орлыкларын чәчтек. Күптән булып узган ул хәлләрнең төгәл исәбен кеше зиһене генә исәпләп бетерә алмау сәбәпле, сезне математик хисап нәтиҗәләре белән җәфалап тормыйм... Кыскасы, без Җиргә җан өрдек... Галәм киңлекләрендә үткәрелгән искиткеч мөһим тәҗрибә иде бу... Тәҗрибә уңышлы үтте, Җирдә тереклек бөреләнде, заманнар үтү белән ул үзенең җимешен дә бирде.
— Бер генә сорау мөмкинме?— диде Бачана кулын күтәреп.
— Әңгәмәгә кагылышлы булса гына!— дип кисәтте Мтварадзе.
— Әйтегез әле, Галактион Георгиевич, мәсәлән, менә сез үзегез безнең планетага кайчан һәм ничек килдегез?
— Сездә шундый сорау туар дип уйлаган идем мин аны... Эш, беләсезме, нәрсәдә: безнең цивилизация вакыт һәм ара ераклыгы дигән нәрсәләрне, гомумән, юкка чыгарды. Әлеге төшенчәләр безнең теләккә бәрабәр. Сез мине аңлыйсызмы? Димәк, без, космик кораблар, оча торган тәлинкәләр һәм шуның ише транспорт чараларыннан башка да, теләгән җиребезгә күз ачып-йомган арада барып җитә алабыз дигән сүз... Инде минә килгәндә, мин исә сезгә беркайдан да килмәдем. Җиргә тереклек орлыклары алып килгән экспедиция группасы, тереклек дөньясы үсә барган саен, аны җайга салып, дөрес юнәлеш биреп торыр өчен, безнең периодик төстә барлыкка килеп торуыбызны генетик яктан алдан программалаштырып куйган. Андый алым камиллеккә ирешү юлларын һәр терек организмның үзенә сайларга мөмкинлек бирә.
— Алайса, үзегезнең гуманоид булуыгызны сез кайдан белдегез соң?
— Бу турыда, вакыты җиткәч, Гомостагы фәнни үзәктән безгә биотоклар ярдәмендә хәбәр итәләр.
— Шундый хәбәрне сез кайчан алдыгыз инде?
— Күптән түгел генә әле, узган якшәмбедә. Йокыга ятканда кеше идем, ә гуманоид булып уяндым.
— Барысы да аңлашылды!— диде Бачана.
— Киресенчә, бернәрсә дә аңламадыгыз әле! Алай гына да түгел, сез мине акылдан язган кешегә саныйсыз, тик сиздермәскә генә тырышасыз. Илтифатыгыз өчен рәхмәт.

Бачана уңайсызланып куйды. Гуманоид исә сүзен дәвам итте:

— Тәҗрибәнең төп максаты итеп башка планеталарда да цивилизациягә ирешеп булу-булмау мөмкинлеген ачыклау куелган иде.

— Шуннан, нинди нәтиҗәгә килдегез инде?

— Әйе, ирешеп була икән!

— Ходайга шөкер!— дип сөенеп куйды Бачана.

— Тик сезнең цивилизациянең үсеше зигзаглар рәвешендә бара. Кеше йөрәгенең кардиограммасына охшаш ул. Сез бихисап күп, гел кирәкмәгән, артык йөрешләр ясыйсыз, шул сәбәпле байтак кына җәфа-интегүләр кичерәсез. Кешелек дөньясы һаман дулкынланып, икеләнеп яши, инде сезнең генезис күрәләтә ялгыш юнәлеш алганда, илдә сугышлар чыга, кизү чире, ачлык-бөлгенлек, рухи фәкыйрьлек, бәла-казалар башлана...

— Алай булгач, нишләп соң сез безне дөресләмисез, бердәнбер туры юлны күрсәтмисез? Кешелеклелек, шәфкатьлелек дигәнегез нәрсәдән гыйбарәт соң алайса?

— Чөнки галәм күләмендә, бер-береңнең эчке эшләренә тыгылмаска, дигән кагыйдә яшәп килә. Һәр терек организм цивилизациянең югары баскычына үзлегеннән күтәрелергә тиеш.

— Гаделсезлек бит бу, Галактион Георгиевич! Инде тәҗрибә үткәрергә алынгансыз икән, сез бит ярдәм күрсәтергә, уңышка ирешү юлында булышлык итәргә тиешсез.

— Асылда шулай килеп чыга да инде ул. Безнең ярдәм сезгә каршылык күрсәтүгә кайтып кала. Аңлашыламы? Без кешелек дөньясына ялгыш юлдан борылып китәргә комачаулыйбыз, кирәкмәгән якка таба үсеш алган бөртекләрне төбе-тамыры белән йолкып ташлыйбыз.

— Сезнең бу ярдәмегез нәрсәдә күренә соң?— дип ихлас күңеленнән кызыксынды Бачана. Хәзер инде ул әлеге чып-чын гуманоид белән юлдан язган кешелек дөньясы исеменнән бәхәсләшә иде.

— Дөрес юлдан тайпылган халыкка без ярдәм кулын ике мәртәбә суздык: беренчесе — әхлаксызлык, азгынлык Содом һәм Гоморра шәһәрләренең башына җиткәндә; икенчесе — дөньяны туфан суы басып, бөтен кешелек токымына куркыныч китергән көннәрдә. Әлеге афәтләрне сез аллаһе тәгаләнең каһәре төшү дип аңлатасыз, хәер, анысы сезнең эш, төшке ашны кичке дип әйтәсезме, әллә кичкелекне төшке дип атыйсызмы — безнең өчен

анысы барыбер.— Мтварадзе, түбәнчелекле бер кыяфәттә, елмаеп куйды.

— Кешелек дөньясына күрсәткән ярдәмегез бары шуңа гына кайтып каламыни? Рухи ярдәмегез кайда соң сезнең? Әхлак ярдәмегез? Ни өчен соң әле сез безне әхлакый яктан югарырак, чистарак итәргә тырышмыйсыз?— дип, Бачана үзен дә, Җирдәге башка ырудашларын да ихлас күңелдән кызганып куйды.

— Нишләп тырышмасын ди! Кешелек җәмгыяте үсешенең төрле этапларында, нинди чорда булуга карамастан, гуманоид геннары уяна тора. Ул геннар кешелекнең әхлак нигезләренә ниндидер тәэсир ясарга омтылалар, уңай якка, әлбәттә... Андый катышуны без мөмкин булган һәм кирәкле нәрсә дип санныйбыз.

— Галактион Георгиевич, үзегездән гайре тагын берәр гуманоидның исемен атый алмыйсызмы сез?— дип сорады Бачана.

— Нишләп атамаска ди, бик рәхәтләнеп! Барысын да хәтерләп бетермим, әлбәттә, тик шулай да кайберләрен санап китәм: Гомер, Сервантес, Бетховен, Руставели, Шекспир, Гёте, Леонардо да Винчи, Боккаччо, Архимед, Джордано Бруно, Жанна д'Арк, Толстой, Пушкин, Парнаваз патша, Давид Строитель, Авраам Линкольн, Фолкнер, Гегель, Кант, Владимир Ульянов, Блок, Эйнштейн, Чарли Чаплин, Галактион, Важа, Акакий, Илья... [1] Барысын да санап бетерерлек түгел...

— Галактион Георгиевич, сез ничек уйлыйсыз: кешелек дөньясы бүгенге көндә дөрес, туры юлдан барамы?

— Кешелек дөньясына бик авыр хәзер!—дип көрсенеп куйды Мтварадзе.— Әгәр дә ул үз вакытында әлеге мин санап киткән гуманоидларның киңәшенә колак салса, бүгенге көндә сезнең хәлегез алай ук мөшкел булмас иде... Әмма кешелек дөньясы, космоска таба карашын юнәлткәннән бирле, бездә, ягъни гуманоидларда, өмет чаткысы уянды. Кешедә кызыксыну дигән гаҗәеп зур һәм көчле энергия барлыгы беленде. Әйе, әйе! Кешеләргә хас булган нәкъ әнә шул сыйфат, Җирнең искиткеч зур тарту көчен җиңеп, сезгә галәм киңлегенә чыгу мөмкинлеген ачты...

---

[1] *Парнаваз* — Грузия патшасы, Александр Македонскийның замандашы; *Давид Строитель (1073—1125)* — Грузия патшасы Давид IV Георгиевич; *Галактион Табидзе* — Грузиянең халык шагыйре; *Важа Пшавела, Акакий Церетели, Илья Чавчавадзе* — грузин әдәбияты классиклары.

— Ничек уйлыйсыз, моннан соң да безгә туфан суы басу яисә шуның кебек башка афәтләр янамыймы?

— Әлеге мин санап киткән гуманоидларның тәгълиматын искергәнгә санап, аннан йөз чөермәсәгез, әлбәттә... Ышаныгыз миңа, андый катарсис, рухи сафлану сезгә файдага гына булачак!.. Шунлыктан, цивилизацияне саклагыз, үткән заманнарның иң мөхтәрәм акыл ияләре тудырган иҗат байлыгын саклагыз! Чөнки бит аларга ирешү өчен күпме хезмәт-көч сарыф ителгән, күпме күз яше һәм кан түгелгән!— дип, Мтварадзе сәгатенә күз салып алды да урыныннан күтәрелде.— Мин сезгә мәсьәләнең төп асылын сөйләп бирдем... Күрсәткән игътибарыгыз өчен зур рәхмәт сезгә!— дип, ул, кулын йөрәк турысына куеп, башын иде.

— Сезгә тагын бер соравым бар, Галактион Георгиевич. Ни өчен сез нәкъ минә минем янга килдегез? Ни өчен серегезне миңа ачтыгыз?

Мтварадзеның йөзе яктырып-балкып китте, бары шунда гына Бачана аның күзләренең сәламәт булмаган бер елкылдау белән янганын күреп алды.

— Минем исем-фамилиям сезгә бернәрсә дә сөйләмимени соң? Галактион — Галактика, галәм! Мтварадзе[1]— Ай дигәнне аңлата. Иртәгә мин үземнең туган илемә, Гомос планетасына кайтып китәм... Җирдәге үземә йөкләнгән бурычны мин тулысынча үтәдем. Ә хәзер миңа тапшырылган соңгы йомышны йомышлап сезгә шуны җиткерергә тиешмен: сез, кадерле Бачана Акакиевич, гуманоид!

Бачананың йөрәге кысылып куйды, тамагына төер килеп утырды.

— Хушыгыз, дустым һәм туганым! Хәзер инде сез үзегезнең Җирдәге бурычыгызны беләсез!

Галактион Бачананы кочаклап күкрәгенә кысты, аннары кырт кына борылды да кызу-кызу атлап кабинеттан чыгып китте.

...Бачана секретарь хатынның бүлмәгә керүен дә, өстәл өстенә бер өем кәгазь кертеп куюын да ишетмәде. Ул, нindидер мәгънәсез бер елмаю белән елмаеп, тәрәзәгә текәлгән килеш басып тора бирде. Аның яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәри иде...

Бачананың күзенә төнозын йокы кермәде. Иртәгесен, редакциягә килүгә, ул беренче эш итеп Статистика идарәсенә шылтыратты.

---

[1] *Мтваре* — грузинча «ай» дигән сүз.

— Әйе, тыңлыйм сезне!— диде трубкадан мөлаем яшь тавыш

— Статистика идарәсеме бу?

— Әйе.

— Әйтегез әле, зинһар, сездә Галактион Мтварадзе дигән кеше эшлиме?

— Мтварадзе дисезме?.. Теге акылга туймаган нәрсәме?.. Гафу итегез, кем сорый аны?

— Галактионның дусты мин.

— Галактион, бер атна инде менә, суга төшкәндәй юкка чыкты...

Бачананың трубка тоткан кулы һавада асылынып калды.

— Алло, алло...— диделәр теге яктан.

Бачана трубканы урынына куйды.

16

Бачана Рамишвилиның туган көне 14 июльдә иде. Бу көн дөнья календарьларының һәммәсендә билгеләп үтелгән, тик, әлбәттә, Бачананың туган көне хөрмәтенә түгел, ә бәлки Бастилия алынып, Франция республикасы барлыкка килгән көн буларак.

...Бачана, каршысында яткан календарьга елмаеп караган килеш, уйга калды.

...Дөньяга 14 июль көнне килгән французлар үзләренең туган көннәрен галәмәт зурдан кубып үткәрәләрдер, мөгаен. Ә менә бүген Бачананың туган көне икәнен кем генә белә икән? Юк, беркем белми! Хәер, шәхси делосы сакланган кадрлар бүлегендә һәм әле яңарак кына сроксыз паспорт алынган милиция бүлегендә бу турыда беләләр булыр. Ләкин бит белү — хәтерләү дигән сүз түгел әле... Соңгы тапкыр Бачананың туган көнен аңа тугыз яшь тулгач үткәргәннәр иде. Ул көнне аңа үзе белән бергә укучы дусты Вахтанг Элкабидзе янгын сүндерә торган үзйөрешле бик шәп бер кызыл машина бүләк иткән иде... Аннан бирле инде күпме гомерләр үтте... Ә бит шуннан бирле Бачананың туган көне өч кенә тапкыр телгә алынды түгелме соң?

— Дөньяга килгән көнеңне каһәр генә суксын иде!— дип, сүгелде ул авызына беренче тапкыр тәмәке капкач;

— Ни пычагыма дип кенә тудың икән син!— диделәр аңа беренче мәртәбә исереп кайткач;

— Кем генә тудырды икән син явызны!— диделәр аңа икмәк карточкасын югалткач.

Әлеге сүзләрне ул төрле вакытта төрле кешеләрдән ишетте, ләкин шул чакта да, соңыннан да аларга карата күңелендә рәнжү-үпкә кебек нәрсә сакламады, чөнки ул сүзләр беренче ике очракта аның сәламәтлеген кайгыртып, соңгысында — ач үлемнән куркып әйтелгән иделәр. Аның туган көнен телгә алган, хәзер инде гүр иясе булган әлеге кешеләрне Бачана һәрвакыт зур рәхмәт хисләре белән исенә төшерә иде. Күрсәткән яхшылыкларына җавап итеп ул бер дә онытмыйча зиратка йөри, аларның каберләрен миләүшә, гөлчәчәк, канәферләр белән бизи иде.

...Менә бүген дә... Туган көннәре белән котлап, күпме кешегә чәчәк бүләк итәчәкләр, һәм шушы көнне дөнья куйган күпме кешенең кабере чәчәкләр белән бизәләчәк... Дөньяга килгән күпме сабыйның бүген күзләре ачылыр һәм күпме күзләр мәңгегә йомылыр... Бачананың күз алдына тормыш агачы сыман гаҗәеп зур, әйләнеп торган бер карусель килде. Анда утырган меңнәрчә кешеләрнең йөзләре чалынып-чалынып киткән кебек тоелды. Арада танышлары һәм таныш булмаганнары да, елмайганнары һәм кайгылылары да, дөньяга гаҗәпләнеп һәм сокланып-куанып караганнары да, төкселәре һәм шатлары да, йончыганнары һәм бәхетлеләре дә бар иде... Талчыгып һәм башлары әйләнеп киткән кешеләр карусельдәге уенчык кораблардан, машиналардан, очкычлардан, атлардан төшә баралар, алар урынына башкалар утыра тора... Бачана да кинәт үзен әле генә карусельдән төшкән сыман хис итте, аның да башы әйләнеп киткән кебек тоелды. Ул урыныннан торды, чайкала-чайкала тәрәзә янына килеп, аны ачып җибәрде. Бүлмәгә җиңелчә кичке җил ургылып керде. Аннары Бачана ишек катына барып, коридорга күз салды. Редакциядә берәү дә юк иде. Бүген Бачана, нәрсә беләндер туган көнен билгеләп үтмәкче булып, әмма уйлап-уйлап та рәтле фикергә килә алмагач, үзенең хезмәткәрләрен, гаҗәпләндереп һәм сөендереп, эштән иртәрәк кайтарып җибәргән иде.

Бачана өстәл янына әйләнеп килде, урынына утырды һәм кулына эләккән беренче корреспонденцияне тартмадан алды. Мәкалә «Ни өчен ярканатлар баштүбән асылынып йоклыйлар?» дип исемләнгән иде.

Шулчагны телефон шылтырады. «Бу вакытта шыл-

тыратырга кайсысының башына килде икән?» — дип гаҗәпләнде Бачана һәм трубканы алды.

— Тыңлыйм сезне!

Телефон дәшмәде.

— Тыңлыйм сезне, тыңлыйм!

Трубкада, сулыш алган тавышны хәтерләтеп, ниндидер шыштырдау ишетелде. Бачана, көтеп-көтеп тә җавап ала алмагач, трубканы куеп, кабат кулъязмага тотынды. Чыннан да, ни өчен ярканатлар баштүбән асылынып йоклый икән? Бачана кулъязманы укып тормады, аның, ни сәбәптәндер, әлеге юк кына тоелган сорауга җавапны үзенең табасы килә иде. Ни сәбәптән икән? Ә бәлки... Кечкенә чакта шулай физкультура дәресендә турникта шактый озак баштүбән асылынып торып, Бачана укытучыдан һаман саен мактау сүзләре ишетә иде, тик шул хәлдә эленеп торудан ул әллә ни рәхәт тапмый иде. Бервакыт шулай Кобулетида аңа, баштүбән асылынган килеш, унбиш минутлар чамасы торырга туры килде; ярымүле малайны судан сөйрәп чыгарган балыкчылар көч-хәл белән аны һушына китергәннәр иде. Шуннан бирле, баштүбән асылынып тору, Бачананың хәтерендә күңел кайтаргыч бер нәрсә булып сакланган. Тик шулай да әлеге гадәти булмаган рәвеш ярканатларга нәрсәсе белән ошый икән соң? Һич аңлашылмый. Бачана, соравына җавап тапмакчы булып, алдында яткан кулъязмага иелмәкче иде, кинәт ишек ачылып китеп, бусагада искиткеч бер чибәр ханым күренде.

— Мин килдем! — диде ул.

Бачана үз күзенә үзе ышанмады: аның каршысында Мария басып тора иде. Бачана аңа урын тәкъдим итәргә теләде, ләкин телен әйләндереп сүз әйтә алмады; урыныннан торып басмакчы иде — аяклары тыңламас булды; елмаерга теләде, әмма йөзе, әйтерсең, таш булып каткан иде. Ниндидер бер мизгелгә ул тәмам өнсез-авазсыз калды. Агарынып киткән ханым исә, еш-еш тын алып, кымшанмыйча басып тора бирде, аның муен тирәләренә тимгел-тимгел булып кызыл таплар бәреп чыкты.

— Мин сезгә шылтыраткан идем! — диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Бачана уянып киткәндәй булды:

— Әйе, мин сезнең сулаганыгызны ишеттем, — диде ул. — Өегездә җавап бирүче булмады, шуңа күрә бирегә шылтыраттым...

— Һи йомышыгыз бар?— дип сорады Бачана үзенең ни әйткәнен аңышмыйча.

— Әйдә, киттек!— диде ханым.

— Кая?— дип гаҗәпләнде Бачана.

— Җаныгыз кая тели — шунда!

Бачана аптырап калды.

— Утырыгыз, зинһар!— диде ул көчкә-көчкә.

Ханым басып тора бирде. Яшел төстәге кофта белән ап-ак итәк кигән, зифа буйлы, чем-кара чәчле, чиядәй кызыл иренле әлеге ханым тәрәзәдән килеп кергән язны хәтерләтә иде.

— Әйдә, киттек!— диде ханым, кулындагы кечкенә яшел сумкасын гасабиланып әйләндерә-әйләндерә. Бачана урыныннан күтәрелде һәм бары шунда гына ханымның төз, матур аякларындагы яшел туфлиләрне күрде.

Алар сүзсез генә бүлмәдән чыктылар.

Урамга чыккач, Бачана такси туктатты.

— Кая илтергә сезне?— дип сорады шофер.

— Кая теләсәң — шунда!— дип җавап бирде Бачана һәм ханымга карады. Тегесе елмаеп куйды.

Алар Комсомол аллеясына күтәрелделәр һәм кечерәк бер павильонның верандасына кереп утырдылар.

Официант Бачана алдына меню китереп куйды да китеп барды.

— Нәрсә алабыз?— дип сорады Бачана.

— Кыздырган бәрәңге.

— Тагын нәрсә?

— Башка әйбер кирәкми.

— Шәраб алабызмы?

— Үзегезгә карагыз.

— Бәлки, коньяктыр?

— Юк, кирәкмәс.

— Алайса «тибаани» алыйк.

— Ихтыярыгыз.

Официант килгәләгәнче дип, Бачана сигарет кабызды һәм Мариягә дә тәкъдим итте.

— Рәхмәт, тартмыйм мин.

Икесе дә сүзсез калдылар. Бачана сигаретын тартты, ара-тирә Мариягә караштыргалап, уйларын уйлады... Ник килде икән бу ханым аның янына? Йомыш белән микән? Әллә инде танышлыкларын дәвам иттерәсе килде микән? Әллә югыйсә... Юк, юк, андый хәлнең булуы мөмкин түгел, туган көне турында кай-

дан белсен ул?!. Тик шулай да Бачана янына килергә нәрсә мәҗбүр итте икән аны?.. Әллә шулай дип турыдан-туры үзеннән сорарганы? Ләкин андый сорау бирергә аңа нәрсәдер комачаулый иде. Һәм әлеге «нәрсәдер» әдәп саклауга гына кайтып калмый, шушы сәер ханым белән очрашкан көннән башлап күңел төпкелендә пыскып яткан өмет чаткысын сүндерүдән курка иде Бачана...

Ниһаять, официант әйләнеп килде һәм Бачана җиңел сулап куйды.

— Нилэр белән сыйлыйсыз безне?— дип сорады ул.

— Теләсәгез, күгәрчен сөте белән!— дип җавап кайтарды официант.

— Алайса, кыздырган бәрәңге белән «тибаани» китерегез.

Официант бердән күңелсезләнеп калды.

— Бәрән итеннән кыздырылган шашлык, бозау итеннән хәзерләнгән шашлык, кыздырган чебешләр, чакапули, абхазура, мужужи, татаряхны[1], надуги[2], мчади[3], яшь сыйр, чикләвек... Кайсысын сайлыйсыз?

— Кыздырган сандугач теле дә юкмы соң?— дип шаяртты Бачана.

— Кыздырганы юк, ә пешкәнен — рәхим итегез!— диде официант авызын ерып.

— Алайса, барысын да рәттән китерегез!

— Чикләвек белән «тибаани»,— диде Мария.

Официант, күндәм генә башын кагып, китеп барды.

— Мария, хәзерге вакытта сезнең кайда йөргәнегезне ирегез беләме?— дип искәрмәстән сорап куйды Бачана һәм шундый ахмак сорау бирүе үзенә дә сәер тоелды.

— Мин сезгә андый сорау бирмим, чөнки сезнең ялгыз кеше икәнегезне беләм,— дип елмайды Мария.

— Алайса, сез тормышта түгел?— дип, ни өчендер шундый нәтиҗә ясады Бачана.

— Әйе, хәзерге вакытта мин тормышта түгел,— диде Мария.

— Ни өчен?— дип сорады Бачана һәм тагын үзенең ахмак сорау бирүен аңышып алды.

---

[1] *Чакапули, абхазура, мужужи, татаряхны* — грузиннарның иттән хәзерләнгән милли ашамлыклары.

[2] *Надуги* — сөттән хәзерләнгән ризык.

[3] *Мчади* — кукуруз онынннан пешерелгән тәбикмәк.

Ханым бу сорауга каршы ни дип тә дәшмәде.

— Кызыгызның әтисе бармы дип соравым иде,— диде Бачана үзенең килешмәгән сүзен йомшартмакчы булып.

— Әйе, әтисе дә бар, ирем тиешле кеше дә бар!— дип җавап бирде Мария.

Бачана тагын сигаретка үрелде. Ниһаять, официант әйләнеп килде, тик аның кулы буш иде.

— Шашлык беткән икән, хөрмәтлем... Чебешләрне мин сезгә үзем үк тәкъдим итмим — инкубатордан алынган... Ит бөтенләй китермәгәннәр икән бүген... «Тибаани» юк, шампан шәрабы да... Швейцария һәм Ростов сыйры бар да, «саэро»[1] белән редиска бар...

Бачана аптырап калды.

— Ә күгәрчен сөте?— диде Мария.

— Анысы әчегән!— дип шаяртты официант.

Мария кычкырып көлеп җибәрде, павильонда утыручылар хәтта аңа таба борылып карадылар.

— Директорыгыз кайда сезнең?— дип сорады Бачана официанттан.

— Хәзергә биредә юк әле ул, хөрмәтлем... Кайтып җитүгә, яныгызга алып килермен!

«Йә бу официант иләсрәк бер нәрсә, яисә болар, мине танып алып, базардан сатып алынган азык-төлекне күрсәтмәскә маташалар»,— дип уйлады Бачана һәм Мариягә таба борылып:

— Китик әле без моннан! Беренче очрашуыбызны «саэро» һәм редиска белән генә билгеләп каласы килми!— диде.

— Хикмәт андамыни?— дип җавап бирде Мария. — Нәрсә бар — шуны китерсен. Ә без үзебезне Ленинград блокадасында калган кебек хис итәрбез... Бер-беребезгә карашып утырырбыз... Бүгенге кич күңелебезгә мәңгегә кереп калыр...

Бачананың күңелендә баягы шик-шөбһәләре тагын кымырҗый башлады. «Шулай да ни кирәк икән моңа? Кайсысы җибәрде икән аны? Ни өчен килде икән ул минем янга? Әллә чыннан да минем белән очрашасы килде микән?» Ул башын күтәреп Мариягә карады. Мария исә каядыр читкә, Бачана аркасы белән утырган якка төбәлгән иде. Бачана да Мария караган як-

---

[1] *Тибаани, саэро* — шәраб исемнәре.

ка күз салды һәм әлеге официантны күреп алды. Официант, базык гәүдәле нииндидер бер ир кешенең әйткән һәр сүзен җупләп, борып җибәрелгән уенчык сыман, карусыз бер кыяфәт белән баш кагып тыңлап тора иде.

— Сезгә каршы заговор коралар!— диде Мария Бачанага.

— Әгәр сезне миннән талап алып китәргә җыенсалар — юкка азапланалар!— дип көлде Бачана һәм кулына өстәлдәге бөгелеп-яньчелеп беткән алюмин пычакны алды.

— Андый пычак белән генә саклап кала алмассыз мине!— дип елмайды Мария.

— Алайса — тешем-тырнагым белән!— диде Бачана, официант ягына таба карашын ташлап, ләкин официант та, аның әңгәмәдәше дә юкка чыкканнар иде инде.— Мария,— дип сүзен дәвам итте Бачана,— башка түзәрлегем калмады: әйтегезче, минем янга килергә сезне нәрсә мәҗбүр итте? Сезгә миннән ни кирәк?

— Мин сездән бернәрсә дә сорамыйм түгелме соң? — дип гаҗәпләнде Мария.

— Сез миңа бик авыр мәсьәлә бирдегез. Йә шуны миңа төшендереп бирегез, йә җанымны алыгыз...

— Сере бик гади моның: иртәгә мин Кутаисига очам, китәр алдыннан күңелемә якын кешем белән хушлашасым килде. Бар хикмәте менә шул гына!

— Нишләп хушлашасыз соң әле сез?— дип сорады Бачана кинәт каушап.

— Ничектер... берәр җиргә очарга җыена башласам, самолетка нидер булыр, якын, кадерле кешеләрем белән соңгы тапкыр күрешәмдер кебек тоела башлый...— дип, Мария башын түбән иде.

— Мин шул «кадерле кешеләр» рәтенә керәмме инде?— дип гаҗәпләнүен белдерде Бачана. Мария, Бачанага күтәрелеп карамыйча гына, башын какты.

— Ә ничек соң мин алай...

— Әгәр белсәм икән!..

— Андый кадерле кешеләрегез күпме инде сезнең?

Мариянең җавабын көтеп, Бачананың йөрәге ярсып тибәргә тотынды.

— Бүгенге көнгә кадәр әле берәү генә — кызым Майя гына иде. Инде хәзер менә икенчесе — сез бар...

«Төш кенәме соң бу, әллә инде, шушы хатын сурәтенә кереп, минем янга иблис үзе килгәнме?!»— дип уй-

ланды Бачана. Ул да түгел, Мария кинәт башын күтәрде һәм дулкынлана-дулкынлана сөйләп китте:

— Күреп торам, сез мине акылдан язган хатын яисә берәр авантюристка дип уйлыйсыз... Валлаһи дип әйтәм, барысы да минем ихтыярымнан тыш шулай килеп чыкты!.. Бер ел инде менә үз-үзем белән көрәшәм... Тик бар да файдасыз! Әмма мин көчле хатын-кыз! Кирәк икән — менә хәзер торам да күз алдыгыздан юк булам! — дип, Мария урыныннан күтәрелде.

— Сез китсәгез, мин дөньяда бүтән яши алмас идем!— дип, Бачана ханымның салкын бармакларына орынды. Мария, бу сүзнең ихлас күңелдән әйтелгәнен күреп, моңа ышануын белдерде. Бачана исә, шуны аңлап, аның кулыннан үпте.

— Рәхмәт!— диде Мария һәм урынына кире утырды.

Шулвакыт, гаҗәеп зур поднос өстенә берсеннән-берсе затлырак ризыклар тезеп, официант килеп җитте.

— Бу ни хәл? Кайдан болай?— дип гаҗәпләнде Бачана.

— Директор килде дә, сезне күреп, саклап тоткан байлыкны чыгарырга кушты!— дип аңлатты официант.

— Директорыгыз кем сезнең?

— Хәзер сезнең янга үзе килер!

— Нәрсә, мине беләмени ул?

— «Беләме» дип сорыйсыз тагын... Сезнең аркада мине чак кына эшемнән куммый калды! Мин гаепле түгел бит, хөрмәтлем, кешенең кем булуы, кайдан икәнлеге мангаена язылмаган ич! Гафу итегез инде!— дип, официант башын иеп саубуллашты да ашыгып китеп барды.

Бачана җанланып китте: «шалт!» иттереп шампан шешәсен ачты, касәләргә мөлдерәмә тутырып шәраб салды.

— Сезгә бер серемне чишмәкче булам, Мария...

— Юк-юк, беренче сүзне үзем әйтәм!— дип касәсенә үрелде Мария.

Бачана, тып-тын калып, тыңларга әзерләнде.

Мария, касәдәге күбекнең шиңгәнен көтеп, беравык тынып торды, аннары, касәсе аша карап, Нарикала[1] өстенә калыккан алтын ай урагына күз салды. Бачана да аның хәрәкәтләрен кабатлады. Башта ай дерелдәп, чайкалгалап куйгандай итте, аннары касәгә төшеп тулды да гәрәбәдәй сары шәраб эчендә эреп юкка чыкты.

---

[1] *Нарикала* — Тбилисидәге борынгы крепость.

Бачанага кинәт кенә салкынча саргылт айны кулында тотып тора кебек тоелды.

— Бүген — айның ундүртенче кичәсе...— диде Мария әкрен генә.— Аның кайчан калкып, кайчан батуы да, кайчан яңа ай булып, кайчан тулып җитүе дә һәркемгә яхшы мәгълүм. Әмма айның җиһанда кайчан барлыкка килгән көнен дөньяда берәү дә әйтә алмый... Кайбер кешеләрнең дә туган көннәрен һичкем хәтерләми... Мин әнә шуларның сәламәтлеге өчен эчәм...

Мария Бачана белән чәкешеп алды. Бачананың касәсендәге ай башта янә калтыранып куйды, аннары, эреп, үтә күренмәле саргылт сыеклыкка әверелде. Мария дә, Бачана да тамчысына кадәр эчеп бетерделәр. Бачана кабат күк йөзенә карады, ләкин бу юлы инде анда ай күренмәде: болытлар арасына кереп югалган иде ул.

— Без бит, шәраб белән бергә, айны да эчеп бетергәнбез,— дип кычкырып җибәрде Бачана, шушы сәер хәлгә балаларча куанып.

— Ходай сезгә айдай озын гомер бирсен! Туган көнегез белән котлыйм сезне!— дип, Мария касәсен өстәлгә куйды.— Бая сүзегезне бүлдердем, сез ниндидер сер турында сөйли башлаган идегез,— дип аның исенә төшерде Мария.

Бачананың, кинәт кенә, шушы гаҗәеп хатынның күкрәгенә сыенып, үксеп-үксеп елыйсы килде.

— Минем бары «Сез искиткеч чибәр, Мария» дип әйтәсем генә килгән иде. Үбәргә мөмкинме сезне?

Ханым, җавап итеп, елмаеп кына куйды. Бачана урыныннан торды һәм өстәл аша иелеп, Мариянең зур дымсу күзләрен үпте. Шулчакны ул баярак официант белән сөйләшеп торган таза гәүдәле ир кешене күреп алды: ул туп-туры аларның өстәленә таба килә иде.

— Исәнмесез!— диде әлеге ир карлыккан тавыш белән.

— Исәнмесез!— дип җавап бирде Бачана.

— Хөрмәтле Бачана, әгәр рөхсәт итсәгез, мин бары бер генә минутка сезнең тынычлыкны бозар идем...

— Рәхим итеп утырыгыз... Бу минем танышым Мария...

Ир кеше гаҗәеп зур тәкәллефлек белән баш иеп, Мариянең кулын үпте дә өстәл артына утырды.

— Сез мине танымадыгыз, ахры, хөрмәтле Бачана?— дип, ир кеше кесәсеннән өч кап «Винстон» сигареты чыгарды һәм капның берсен Мариягә табарак этеп куй-

ды, икенчесен Бачанага сузды, өченчесен үзенең алдында калдырды.

Бачана, исенә төшерергә тырышып, әлеге кешегә текәлебрәк карады, ниндидер бер мизгелдә ул аны кайдадыр күргән дә кебек тоелып китте, ләкин тәгаен генә хәтерли алмады һәм кыенсынып:

— Нишләп танымаска, таныдым, тик менә кайда күргәнемне генә искә төшерә алмыйм,— диде.

— Сандро Маглаперидзе булам мин, тире эшкәртү комбинатыннан...

— Ә-ә-ә!— дип кычкырып җибәрде Бачана,— аннан соң күпме гомерләр үтте бит инде!.. Хәзер кайда сез, ни хәлләрдә яшәп ятасыз, хөрмәтле Сандро?

— Рәхмәт, яшәгәндәй булабыз инде шунда...

— Элекке эш өчен үпкә белдерергә дип килүегез икән, бүгенгә, зинһар, сабыр итегезче... Бүген Франция республикасының, шулай ук минем дә туган көнем!— диде Бачана шат күңел белән һәм Маглаперидзега мөлдерәмә тулы касәне сузды.

— Нәрсә сөйлисез сез! Нинди үпкә тоту ди ул? Киресенчә, мин сезгә рәхмәт әйтергә дип килдем, хөрмәтле Бачана!.. Ничә яшь булды инде сезгә?

— Кырык биш!

— Йа хода! Дөньяның күпме рәхәте көтә әле сезне! Һәм дә күпме мәхәббәте!— дип Маглаперидзе Мариягә карап куйды. Мария уңайсызланып кызарып китте.— Котлыйм сезне, хөрмәтле Бачана! Аллаһе тәгалә үзегезгә бәхет бирсен! Сез, бик теләсәгез дә, һичкемгә начарлык кыла алмый торган кеше!

— Шулай дип уйлыйсызмы?

— Әлбәттә! Теге фельетон басылып чыккан көннән соң мин галәмәт бер популяр кешегә әйләндем! Минем исем бөтен Грузиягә мәгълүм булды!..

Бачана көлеп җибәрде:

— Андый танылуны мин хәтта дошманыма да теләмәс идем.

— Нишләп алай дисез... Танылу-танылу инде ул... Шул ук Геростратны исегезгә төшерегез... Сезнең фельетон дөреслеккә җиңеп чыгарга ярдәм итте, явызлыкны фаш итте...

— Анысында шигем юк...

Маглаперидзенең рәхмәт әйтер өчен килмәвен Бачана, әлбәттә, эчке бер сиземләве белән тоя иде.

— Әйе, әйе... Тикшерү органнары фельетон белән кызыксына калдылар һәм теге хатынның ниндидер бер

алдакчы, угры булуын ачыкладылар... Ә теге, чарасын күрсен дип, сез фельетонны җибәргән кеше исә чын-чынлап патриот булып чыкты...

— Ничек итеп?—дип сорады Бачана, Маглаперидзега өстәл янынннан урын тәкъдим иткәненә үкенеп.

— Сезнең хисап буенча, бастырырга дип җыелган газеттан фельетонны алып ташлау дәүләткә илле мең сумга төшәр иде, шулаймы? Әлеге кеше исә ул зыянны егерме биш мең сумга калдырды.

Бачана, ни әйтергә белмичә, югалып калды. Маглаперидзе, аның аңышмый торуын күреп, тыныч кына аңлатып бирде:

— Әлеге мәсьәләне ул бик җиңел хәл итте: сезнең фельетонны игътибарга алып маташмады.

— Сез, ришвәт бирдем, ягъни, егерме биш мең сум түләдем, дип әйтмәкче буласызмы?

— Хөрмәтле Бачана, сез, гомумән, нәрсәне ришвәт дип атыйсыз соң? Авыр көнендә сиңа ярдәм кулы сузган, игътибар күрсәткән кешегә рәхмәт белдерүнеме? Без әле бүген дә Руставелиның әхлак кодексына таянып эш итмибезмени? Автандилның вәзиргә әйткән сүзләрен исегезгә төшерегез әле:

Дус өчен дусның йөрәге әллә бер дә сызламасмы.
Ярдәм кирәк була калса, ике җиңен сызганмасмы...

— Әйе, сез үзегезнең пычрак фәлсәфәгезне нигезле итеп, чыганакларга таянып исбатларга өйрәнгәнсез,— дип чәнчеп әйтеп куйды Бачана.

— О, классик әдәбият — бөек нәрсә ул... Руставелины мин, инҗил китабы сыман, кулыма көн саен алам... Әйтергә кирәк, мин сезнең әсәрләрне дә укып барам һәм үземә сабак булырдай байтак нәрсәләр табам... Сезнең танышыгыз шундый чибәр, хөрмәтле Бачана,— дип, Маглаперидзе кинәт сүзне икенчегә борды,— энҗе-мәрҗәннәр такмаган шундый гүзәл хатын-кызны беренче күрүем!

Бачана сүзнең мондый юнәлеш аласын көтмәгән иде, шуңа күрә, нәрсә әйтергә белмичә, аптырап калды.

— Алайса, сезнең хатыныгызның энҗе-мәрҗәннәре бик күптер инде?— диде Мария һәм, дулкынлануын яшермәкче булып, шәраб йотып куйды.

— Зарлануын зарланмый алай... Ләкин бит мин үз хатыннарыбызны күздә тотып әйтмим... Гаиләдән тыш,

безнең тормышка ямь өстәүче башка хатын-кызлар да бар бит әле...

Мария кып-кызыл булды, ләкин дәшмәде.

Бачана исә, башлаган сүзне дәвам итмәкче булып, баягы әңгәмәгә кайтып төште:

— Фельетон басылып чыкканнан соң тормышыгызда үзгәрешләр булмадымыни?

— Булмыйча соң, хөрмәтле Бачана! Беренчедән, безнең производствода янгын чыкты: электр чыбыклары искергән булган... Икенчедән, минем вәзир пенсиягә китте һәм минә сәүдә өлкәсенә эшкә керде... Аннан мине үз янына алды. Шуннан инде без яңа рестораннар берләшмәсе төзедек... Нерон көлгә әйләндергәннән соң, хәрабәләр өстендә яңа Рим күтәрелеп чыккан кебек, без дә яңадан аякка бастык, ха-ха-ха!— дип, Маглаперидзе җирәнгеч итеп хихылдап куйды.

— Әйе, хөрмәтле Сандро, мин сезнең бик сәләтле һәм куркыныч мошенник булуыгызга торган саен ныграк ышана барам... Мин бу мәсьәләгә, мөмкинлек булса, һичшиксез, кабат әйләнеп кайтачакмын,— диде Бачана җитдиләнеп.

— Ә менә мондый җавапны мин сездән һич көтмәгән идем! Шушы вакыт эчендә сезне акылга утыргандыр, бу инде адәм рәтле җырларга өйрәнгәндер дип уйлаган идем... Ә сез һаман әле үзегезчә кытаклап маташасыз икән... Вакытлы-вакытсыз кычкыра торган әтәчне нәрсә эшләткәннәрен белмисезмени сез?

— Нәрсә, янавыгыз дип аңларгамы моны?— Бачана ачуыннан агарынып китте.

— Мондый адәм актыгы белән җирәнмичә ничек сөйләшеп торасыз?— диде Мария гел көтмәгәндә.

Маглаперидзе чәчрәп урыныннан сикереп торды. Мария да аягүрә басты.

— Китегез моннан!— диде Бачана Маглаперидзега, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Хатын-кызның чыгымчылавына алай исегез китмәсен, хөрмәтле Бачана... Фахишә хатыннар Македония сугышчыларын җир йөзендәге иң гүзәл шәһәр Персеполисны көлгә әйләндерергә мәҗбүр иткәннәр...— диде Маглаперидзе, нәфрәт тулы төссез сары күзләрен Мариягә төбәп. Шулчакны, Бачана нәрсә дә булса уйлап өлгергәнче, Мария кинәт, селтәнеп торып, Маглаперидзенең яңагына чалтыратып җибәрде. Бу тавышка павильондагылар ялт итеп алар ягына борылып карады, ләкин әлеге хәл шундый тиз булды, беркем бернәрсә күрми калды...

Алар өстәле янында авыр тынлык урнашты... Кинәт, Маглаперидзе ягыннан өстәлнең бер кырые күтәрелә башлаганны сизеп, Бачана бөтен авырлыгы белән өстәл читенә таянды, Маглаперидзе исә, бар көчен җигеп, өстәлне әйләндереп ташларга тырыша, әмма берничек тә булдыра алмый иде. Бу сүзсез тартышу бер минут чамасы дәвам итте. Бачананың да, Маглаперидзеның да чигә тамырлары бүртеп чыкты, күзләрен кан басты...

— Маташма!— дип, тешен кысып, ниндидер бер дәһшәт белән пышылдады Бачана һәм, ни хикмәттер, Маглаперидзе кинәт бердән суынып, сүрелеп калды. Йөзе әүвәлге кыяфәтенә керде, күзләре кабат елмая башлады. Ул, өстәл яныннан читкәрәк тайпылып, Мариягә мөрәҗәгать итте:

— Рәхмәт сезгә, ханым! Күрсәткән хөрмәтегезне мәңге онытмам!

Киндердәй агарынып калган Мария дәшмәде.

— Юлыгызда булыгыз, Маглаперидзе!— диде Бачана, үзенең тыныч тавышына үзе гаҗәпләнеп.

Маглаперидзе кырт борылып китеп барды.

Бачана белән Мария, исләрен җыя алмыйча, шулай беркавым басып тордылар да кире урыннарына утырдылар. Өстәл артында тынлык урнашты. Беренче булып Бачана телгә килде:

— Мария, самолет билетыңны күрсәт әле.

Мария, сумкасын ачып, калтыранган куллары белән аны актарырга кереште, ниһаять, билетын табып, Бачанага сузды.

Бачана, билетка карап та тормыйча, ерткалап, төпчек савытына салды да ут төртте.

— Ташлап китмә мине, Мария!— диде ул аннары, төпчек савытындагы билет янып беткәч. Мария җиңелчә генә баш кагып куйды. Бачана касәләргә шәраб салды һәм официантны чакырды.

— Исәпләгезче, зинһар!

— Барысы өчен дә түләнгән инде.

— Кем түләде?

— Безнең директор!

Бачана көлеп җибәрде.

— Менә сиңа кирәк булса — Бастилияне алу көне!.. Синең өчен, Мария!— Алар чәкешеп куйдылар. Шунда Мария урыныннан торды да, Бачана янына килеп, иреннәрен аның битенә тидереп алды. Аннары кабат урынына барып утырды һәм, йөзе белән кулларына капланып, сулкылдый-сулкылдый елап җибәрде.

Тау башындагы Шавнабада[1] чиркәве, читтән карагэнда, чыннан да, иңенә кара чикмәнен салып, каш өстенә кулын куеп, Мтквари, Алгети, Машавера, Храми [2] яр буйларында утлап йөргән сарыкларны күзәткән көтүчегә охшап күренә иде. Ә тау итәгенә сибелешкән һәм авызларыннан бертуктамый төтен һәм эссе бөркеп торган Рустави, Болниси, Марнеули [3] шәһәрләре исә шул сарыкларны саклап яткан иләмсез зур этләрне хәтерләтә.

Өрфиядәй җиңел томанга төренеп, түбәсе белән күкләргә ашкан Шавнабада тавы көзнең соңгы айларында аеруча матур.

Якшәмбе көннәренең берсе. Тар гына арба юлыннан зур авырлык белән бер машина сөйрәлеп бара. Ул, аватүнә атлаган исерек кеше сыман, һәр борылышта туктый да башта бераз артка чигенеп ала һәм, бераз хәл җыеп торганнан соң, кабат алга ыргыла.

Чиркәүгә менеп җитәрәк соңгы борылышта машина янә туктады. Бачана, машинаны беренче тизлеккә күчереп, педальгә басты. Арткы тәгәрмәч астыннан вак чуерташ, ком өермәсе бөркелде. Бачана акселераторга ныграк басты. Тәгәрмәчләр күз иярмәс тизлек белән котырып әйләнергә кереште, тирә-юньгә резин янган ис таралды.

— Мин төшим булмаса,— диде Мария.

— Кирәкми, утыр. Авырлык җитмәгәнгә шулай бер урында таптана да ул,— дип аңлатты Бачана.

Машинаны ул арткарак чигендерә төште һәм, тизлеккә салып, газга басты. Машина алга ыргылды.

— Менә, килеп тә җиттек!

Бачана машинаны агач төбенә китереп туктатты.

Мария машинадан чыкты, туфлиләрен салып ташлап, яланаяк чирәм өстеннән йөгереп китте һәм чиркәү ишегалдының урта бер җирендә туктады да, кулларын җәеп, кечкенә балалар кебек, аяк очында бөтерелеп куйды.

— Ау, ходайның янына ук менеп җиттек!— дип кычкырды ул.

Аннары ул чиркәү каршына килеп чүкте, йөзе белән тезләренә капланды һәм, аллага сәҗдә кылучы диндар бер хатын сыман, кинәт тынып калды.

---

[1] *Шавнабада* — тау исеме; грузин телендә «шави» — кара, «набади» — җилән дигәнне аңлата.

[2] *Мтквари, Алгети, Машавера, Храми* — елга исемнәре.

[3] *Рустави, Болниси, Марнеули* — Тбилиси тирәсендәге шәһәр исемнәре.

Бачана багажниктагы азык-төлекне бушатып, агач төбенә корыштырып куйган өстәл өстенә тезде дә Мария янына килеп тезләнде һәм аны иңнәреннән кочып алды.

— Мария, берәр дога укы әле!— диде ул көлемсерәп.

Мария җиргә тезләнде, кулларын кушырып, югары күтәрде һәм, күзләрен йомган килеш, ишетелер-ишетелмәс пышылдап догасын башлады:

Иң мөкатдәс өметем син,
Син — чиксез йөрәк җылым,
Йолдызым син балкып янган,
Син — сүнмәс кояш нурым,
Үлемсезлек чыганагым,
Ак канатлы фәрештәм;
Тәңрем, безне аерма, дип
Дога укыйм кич-иртән...

Мария тынып калды.

Әлеге шигырьне Бачана да яттан белә иде, әмма дога сүзләрен хәтерләткән бу юлларның мәгънәсе турында аның бер генә тапкыр да, беркайчан да уйлап караганы булмады. Хәзер исә аның җанына гаҗәп бер рәхәтлек, тынычлык иңгән кебек булды, бөтен гәүдәсе буйлап ниндидер җылы дулкын таралды. Ул Марияне кочаклады да:

— Нәрсә бу — догамы, әллә изге бер теләгеңме?— дип сорады.

— Аларның икесе дә бер үк нәрсә түгелмени?

Кояш, кояш, нурлы кояш,
Качма таулар артына!
Күрмисеңме, бер кыз бала
Туңып тора салкында!
Җылыт аны, куйныңа ал,
Әйт бер сөю сүзеңне.
Юкса башканы табар ул,
Көтеп ятмас үзеңне.

Шулвакыт, Мариянең сүзләрен ишеткәндәй, тау артыннан зур булып кояш балкып чыкты һәм кайнар куллары белән чиркәүне кочагына алып, тау битләре буйлап җәелгән ак томанны, сөт эчкәндәй, күз ачып йомган арада ялмап та бетерде.

Мария Бачананың күкрәгенә сыенды һәм, дога укыган сыман, сөйләргә кереште:

— Ташлап китмә мине, Бачана!.. Ташлама мине, бердәнбер өметем!.. Ник моңарчы минем янымда булмадың икән соң син? Күпме бәлаләрдән йолып алган булыр идең!.. Сине беренче тапкыр күргән көннән бирле мин

тормышымдагы бар нәрсәмнән ваз кичтем!.. Синнән башка дөньяда миңа бүтән бернәрсә дә кирәк түгел!.. Син минем тәңрем! Шуның өчен дә синнән ялварып сорыйм: беркайчан да ташлама мине, үткәннәргә әйләнеп кайтырга мәҗбүр итмә мине! Алай яшисем килми минем! Ардым мин андый тормыштан!.. Мин торган саен сиңа якыная барам. Менә-менә хәзер кулларым белән сиңа килеп орынырмын күк.. Мин синең янда, синең белән... Ташлама мине!..— дип, Мария елый башлады.

Күңеле кузгалган хатынның дулкынланып, ихлас әйткән сүзләрен тын алырга да куркып тыңлап торган Бачана тынычландырырга тырышты.

— Ни булды сиңа, Мария?.. Нишләп ташлыйм ди мин сине?.. Йә, тукта инде!.. Елама, кадерлем!.. Мин мәңге синең янда булырмын!..

Мария бераз тынычлана төшкәч, Бачана аны иплән кенә чирәмгә яткырды һәм, торып, чиркәүгә таба атлады. Ул үзе дә шактый дулкынланган иде.

Чиркәү эче салкынча һәм ярым караңгы иде. Бачана як-ягына каранды.

Дым тарткан юеш стеналар... Бер җирдә бер генә икона-сурәт тә, бер генә бизәк тә калмаган... Гыйбадәт кыла торган урын кубып, сыдырылып беткән... Бер почмакта кайчандыр яшел постау белән тышланган булган чатан аяклы өстәл тора; аның өстендә яньчелеп калҗайган шәмдәл белән кайсыдыр бер хыялые мәзәк өчен ясап куйган Мәрьям ана сурәте күренә... Шәмдәлдә төбенә кадәр диярлек янып төшкән өч шәмнең калдыклары... Өстәлдә, бер бәйләм юка балавыз шәмнәр янында, бөгәрләнеп беткән кәгазь өчлек...

— Әй!— дип кычкырды Бачана.

— Ә-ә-әй!— дип кайтып яңгырады аның авазы.

Тавышка кайдадыр югарыда, гөмбәз астындагы куышларда гөрләшеп утырган күгәрченнәр пырхылдашып урыннарыннан куптылар һәм чиркәүнең тар тәрәзәләренә ташландылар... Бачана чиркәү эчен әйләнеп чыгарга булды. Көнчыгышка караган стена, кеше биеклеге чамасында, урыны-урыны белән шәм корымына ысланып беткән. Анда-монда фамилияләре алфавит буенча тезелеп төшкән, йорт адреслары һәм бирегә экскурсия белән килгән көннәре язылган озын-озын исемлекләр күзгә ташлана. Чиркәүнең түр стенасында, Гайсә пигамбәренең яртылаш уңган бердәнбер сурәте астында, билгесез бер шагыйрьнең аллаһе тәгалә колагына төбәлгән өйрәнчек шигыре язылган:

Ышанмыйм мин аллага —
Төсе уңган ялганга!

Бу икеюллыкның астына: «Комсомол-атеист» дип куелган иде.

Тагын бераз астарак, стенаны тырнап, аңа җавап та язганнар:

Әгәр инде ышанмагач алланың барлыгына
Ни генә дип соң, ускәнем, сөйрәлеп килдең монда?
Үз хәсрәтем үземә җиткән, ерак юллардан килеш,
Син калдыр мине тынычта — инде булгач атеист!

Һәм «Гайсә пигамбәр» дип имза куелган.

Бачана кычкырып көлеп җибәрде: әлеге читтән торып үткәрелгән шигъри бәйгедә атеистның ходай-тәгаләдән шактый калышуы күзгә бәрелеп тора иде.

Бачана чиркәүдән чыкканда Мария якын-тирәдә күренмәде.

— Мария, кайда син?— дип кычкырды Бачана.

Ләкин җавап ишетелмәде. «Нишләп ялгызын гына калдырдым икән?»— дип уйлап алды Бачана һәм чиркәү тирәли эзләргә керешге.

Мария агач төбендәге өстәл янында ниндидер бер карт белән тыныч кына әңгәмә корып утыра иде. Бачана алар янына килде.

— Кая юкка чыктың син? Куркыттың бит!.. Исәнмесез!— диде ул аннары, картка борылып.

— Ходай сәламәтлек бирсен үзеңә!— диде карт, кечерәк киез эшләпәсен башыннан күтәрә төшеп.

— Бәлки, капкалап алырбыз?— дип сорады Бачана Мариядән.

— Әйе шул, минем бик ашыйсым килә!— диде Мария.— Абзый да менә, бәлки, безнең белән тамак ялгап алыр.

— Шулай, нишләп әле бергәләп утырып алмаска ди! Миндә дә капкалардай нәрсәләр булырга тиеш!— дип, карт, букчасын чишеп, табын өстенә йорт икмәге, сыйр, пешкән ит, сарымсак, ярты шешә аракы чыгарды. Бачана машина эченнән бер шешә шәраб алып килде.

— Иң әүвәл, балалар, берәр чәркә аракы эчеп җибәрик!— диде карт, букчасыннан кечерәк бер мөгез чыгарып, өргәләп-сыпырыштырып куйды һәм, аракы салып, Бачанага сузды:

— Йәле, тут җимеше аракысыннан авыз итеп, берике сүз әйтеп җибәр әле!

— Дусларга сөенечкә, дошманнарга көенечкә булсын!— дип, Бачана эчеп җибәрде һәм, беравык дәшми торганнан соң, канәгать төс белән.

— Әйе, аракысы шәп!— дип телен шартлатты, аннары алдындагы сарымсакка үрелде.

Макталудан күңеле үсеп киткән карт үзенә дә салып алды.

— Шатлык булган җирдә кайгысы да булмый калмас... Тегесе өчен дә, монысы өчен дә эчик әйдәгез бер, тик сәламәт булып, исән-имин яшәргә язсын! Яшәвебез өчен!— Карт, мөгезне бушатып, сакал-мыек баскан йөзен учы белән сыпырып куйды, аннары Мариягә салып бирде.— Хәзер инде, кызым, син берәр сүз әйт! Ходай сине шундый чибәр итеп яраткан, сүзләрең дә синең, мөгаен, күңелне сөендерми калмас!

Мария мөгезне кулына алды.

— Ничә яшь сиңа, абзый кеше?

— И-и-и,— диде карт кулын селтәп,— җитмешнең теге ягына чыктым инде!

— Ходай сиңа тагын шуның кадәр гомер бирсен!

— Алай күбрәк булмасмы соң? Шулай да рәхмәт үзеңә! Яшермим, тормышны яратам мин! Тагын бераз яшисе килә әле!

Бачана елмаеп куйды.

— Исемең ничек соң синең, абзый?— дип сорады ул.

— Георгий исемле мин, фамилиям Тушмалишвили.

— Кай яктан үзең?

— Ә-ә-әнә теге авылдан.

— Биредә соң нишләп йөрисең?

— Көтү көтәм.— Карт каршы яктагы тау битләве буйлап утлап йөргән ике сыер белән өч сарыкка төртеп күрсәтте.

— Синең маллармыни?

— Минеке.

— Доходы бармы соң?

— Нинди доход ди инде ул! Үз тамакларын үзләре туйдыра алмаганны...

— Алайса, ник асрыйсыз соң?

— Ник дип... Әз-мәз сөте, бераз йоны, кайчак ите дә булгалап куя... Күбрәк асрасаң иде дә бит... Ә болай нәрсә: бөтене бергә бүрегә бер ашарлык ризык...

— Дәүләткә тапшырасыңмы соң?

— Әйе, тапшырам...

— Нәрсәләр тапшырасың?

— Нәрсә дип инде... әз-мәз сөтен, бераз йонын, кайчак итен...
— Әгәр малың ишлерәк булса?
— Нәрсәсен сорап торасың инде аның, улым! Ишлерәк булса, тапшыруын да күбрәк тапшырыр идек... Артыгын нишләтәсең инде аның? Хөкүмәткә яисә базарга илтер идең...
— Колхозда эшләмисеңдер инде, Георгий абзый?
— Кайда инде ул эшләүләр, улым, шушы яшькә җиткәч!.. Балаларым эшли, билгеле. Алар минем көтү белән йөрүемә дә каршы, безне хур итәсең, имеш. Өйдә ял итеп кенә утырсаң ни булган, диләр. Без ул ит белән сөтне сдача акчасына кибеттән дә ала алабыз, имеш. Белдеңме? Кибеттән, имеш! Кайдан килеп кибеттә ит булсын ди! Анысы турында уйламыйлар бит ул эттән туган нәрсәләр!
— Георгий абзый, бу чиркәүнең хуҗасы бармы?— дип кинәттән генә сорап куйды Мария.
— Бар дисәң дә инде... Авылдан бер карчык килгәләп йөри... Мария исемле ул да... Чиркәү эчендәге өстәлдә торган иконаны да ул ясап куйды... Тик авырый шул, бичаракай, атнасына бер тапкыр менә алса да рәхмәт инде.
— Андагы шәмнәрне кем яндырган соң?— дип сорады Бачана.
— Мин булмыйча, тагын кем яндырсын инде.
— Ә акча кайдан килгән...
— Кайдан дип... Мин куйдым, шәм өчен...
— Георгий абзый, аллага ышанасыңмы син?— дип сорады Мария.
— Георгий карт бермәлгә уйга калды. Аннары, түбәсеннән алып баскычына кадәр, чиркәүне күздән кичерде, башын кашып куйды, кабат чиркәүгә карады.
— Ничек дип әйтим... Дөресен генә әйткәндә, бик үк ышанып та бетмим кебек... Тик көнозын шушында, бер ялгызың йөри торгач, теләсәң-теләмәсәң дә ходай тәгалә турында уйлана башлыйсың...
— Нәрсәләр дип уйлыйсың инде син аның турында?
Георгий карт тагын бер тапкыр чиркәүгә күз салды.
— Нәрсә уйлыйм дисеңме?.. Әгәр кеше башка берәүләр салган гыйбадәтханәне җимерә икән, аның урынына ул элеккесенә караганда да күп өлеш матуррак, зуррак булган үз сараен җиткерергә тиеш... Менә бу чиркәүне генә алыйк... Кемнеке ул, кайсысы салган аны — берсе дә билгеле түгел. Храм бәйрәме көннәрендә кайлардан

гына килмиләр монда: әрмән, татар, грек, урыс дисеңме... Грузиннарны инде әйткән дә юк... Киләләр, гыйбадәт кылалар... Мәсәлән, минем үземә калса, ул чиркәүгә кергәнче, кола яланга чыгып гыйбадәт кылуың меңтапкыр яхшырак... Анда укыган догаларың аллаһе тәгаләгә тизрәк барып ирешер иде... Ә бит бу хәрабә эчендә ходай тәгаләнең түгел, бәндә баласының да басып торасы килмәс... Нәрсәдән чыгып әйтә дисезме? Чиркәү ташландык хәлгә килгән, аны караучы да, күз-колак булырдай кешесе дә юк, ә аның урынына алмашка нәрсә салдылар соң?

— Нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңламадым әле мин, Георгий абзый...

— Аңламастай әллә нәрсә юк монда. Әүвәле, улым, чиркәүгә барырга дип чыккан кеше иң әлек тауга күтәрелер, аннары, башын иеп, капкадан керер һәм, чиркәү катына җиткәч, бүркен салыр, чиркәү эченә аяк баскач инде шәм яндырыр иде... Хәер, нәрсә дип сөйләнеп торган булам, үзегез дә, шәт, укымышлы халыктыр, миңа караганда яхшырак беләсездер... Инде килеп, безнең авыл советын алыйк... Бүгенге көндә ул вакытлыча файдаланууга алынган ярым җимерек бер йортка урнашкан. Анда кергәндә кешеләр — кайда ул бүрек салу!— сүгенеп-төкеренеп керәләр... Миңа калса, бөтен авылында авыл советыннан да күркәмрәк мәһабәтрәк бина булырга тиеш түгел... Ничек уйлыйсыз, әллә әүвәлге халыкның чиркәүдән дә биегрәк итеп йорт салырга хәленнән килмәгәндер дисезме? Хәленнән килгән килүен, тик кыймаган халык! Андый эшкә хакы булмаган аның!.. Ә хәзер, безнең колхоз председателенең йортын авыл советы белән янәшә куйганда, әнә теге калкулыкны Казбек белән чагыштырган кебек булыр иде. Авылдагы шофер Митьканың гаражы да безнең клубтан өч мәртәбә зуррак!.. Андый авыл советына аяк басасы килер микән?.. Юк шул, килмәс!.. Ә бит хәерчеләр түгел без, барлык белән яшибез. Авылыбыз, аллага шөкер, таза, нык тормышлы! Икмәге дә мул, шәрабы да, яшелчәсе дә җитәрлек! Кеше дигәнең чучкадан нәрсәсе белән аерыла? Адәм баласы агачтагыны ашый, ә дуңгыз — җиргә коелганын, аяк астындагысын. Нәрсәдән китереп әйтәм дисезме? Һәрбер эшкә үз вакытында хуҗа кулы кирәк, димәкче булам. Соңга калдыңмы — алма агачыннан өзелеп төште дә дуңгызга ризык булды дигән сүз!.. Авыл советы председателенә: «Син бит хуҗа кеше, авылда совет власте бит син. Бераз кыймылда инде, эттән ту-

ган нәрсә, кеше авыл советына сөенеп керердәй итеп адәм рәтле бер йорт салдыр!— дип күпме әйттем!— «Акчасыз, лимитсыз ничек итеп йорт җиткерим!»— ди бу миңа. «Ул шайтан орган лимиты тагын нәрсә?»— димен. «Кирпеч дигән сүз ул!» — ди. Белдеңме инде, кирпече юк икән аның! Алайса, кайдан килеп, Митьканың гаражына, колхоз председателенең таш пулатына кирпеч табылды икән соң?.. Ярар, кирпечне ул таба да алмасын ди, әмма инде, һич югы, чиста итеп кырынып, сакал-мыегын адәм рәтле итеп йөртә аладыр бит? Авыл халкы ихтирам беләнрәк карарлык итеп өс-башын да рәтли аладыр? Рәтли ала, әлбәттә, тик ул, эттән туган нәрсә, боларның барысына төкереп тә бирми! Авылда минем сыерның да әлеге председательгә караганда мәртәбәсе зуррак! Ни өчен дисезме? Чөнки ул һәрвакыт чиста итеп юылган булыр, көндәгесен көнгә сигез литр сөтен биреп барыр! Менә нәрсә өчен! Бәлки, мин ялгыш уйлыймдыр! Дөрес булмаса, әйтегез сез!— дип карт, сүзен тәгәлләп, стаканнарга шәраб салып чыкты.

— Дөрес уйлыйсың син, Георгий абзый,— дип җавап кайтарды Бачана,— тик дөресен генә әйт әле: бу турыда синең бер генә тапкыр булса да җыелышта сүз алып сөйләгәнең булдымы?

— Бер тапкыр сөйләгән идем...

— Кайчан?

— Сиңа ничә яшь хәзер?

— Кырыкның теге ягында.

— Ә миңа ул чакта утыз иде... Шул сүзләрем өчен аздан гына, беләсеңме, кая эләкми калдым мин?..

— Хәзер бит инде заманалар башка, Георгий абзый!

— Алайса, менә башкалар сөйләсен дә инде... Мин яшисемне яшәгән...

— Ә үзең: «Яшисе килә әле»,— дисең...

— Ай, сүз сөйләргә оста да соң сез, яшьләр! Тик менә эш күрсәтергә дигәндә генә бик ашыкмыйсыз!.. Син үзең, улым, алай-болай райкомнан килгән кеше түгелсеңдер бит?

Бачана көлеп җибәрде.

— Юк, Георгий абзый, язучы мин, газета редакциясендә эшлим.

— Редакциядә дисеңме? Алайса, менә тот та шушыларның барысын гәзитеңдә язып чык!

— Язармын да!

— Ай-һай, булыр микән...

— Нишләп булмасын ди... Нәкъ әнә шулай дип, Георгий Тушмалишвили менә ничегрәк уйлый дим дә язам...

— Бөтенесен дә минем өскә аудармакчы буласыңмы?— диде карт сагая төшеп.

— Юк, нишләп аударыйм ди! Кайбер фикерләре белән мин дә килешәм дип язармын...

— Кайберләре белән генәмени?

— Әйе.

— Димәк, син минем белән тулысынча килешеп бетмисең?

— Әйе, килешеп бетмим.

— Шулай да, яртылашы белән килешәсеңдер бит?

— Әйе, шул чамасы белән килешәм...

— Ярый алайса, яртылашын яз!

— Вәгъдә!

— Ярар, исән булсак — күрешербез!— дип әйтеп куйды карт бик үк ышанып бетмичә, аннары Мариягә таба борылды:

— Язардыр бит?

— Язар!— дип җавап бирде Мария көлеп.

— Ә сез бер-берегезгә кем буласыз соң әле?— диде карт һич уйламаганда.

Андый сорауны көтмәгән Мария кыенсынып китте һәм, җилкәсен җыерып, «нәрсә әйтергә?» дигән кебек Бачанага карады.

— Георгий абзый,— диде Бачана елмаеп,— без бер-беребезне бик нык яратабыз һәм бирегә никахлашырга дип менүебез иде. Тик менә чиркәүдә изге ата юк икән.

— Нәрсәгә ул сезгә изге ата? Бер-берегезне яратасыз икән, сезне мин дә никахлый алам,— диде Георгий, урыныннан кузгала-кузгала.— Кая, икегез дә торып басыгыз әле! Исемең ничек синең?

— Бачана.

— Синекен беләм инде — Мария.

Георгий кулларын югары күтәрде, уң кулына ул шәраб салынган стаканын тоткан иде.

— Балакайларым, Мария белән Бачана! Тормышыгыз иртәнге чык бөртегедәй саф булсын, күктәге кояш сезнең таҗыгыз, менә бу борынгы чиркәү белән туган җирегез сезнең мәхәббәтнең шаһитлары булсын. Мин, Георгий Тушмалишвили, гаделлек, тугрылык белән көн итүче Ной һәм аның балаларына ходай тәгалә фатиха биргән кебек, сезгә үземнең хәер-фатихамны бирәм. Гаиләгез ишәйгәннән-ишәя барсын! Сезнең балаларга

илебезнең данын үстерергә язсын! Мәхәббәт сезнең юлдашыгыз булсын! Бер-берегезгә тугрылык саклагыз, авыр минутларда да, дөнья мәшәкате арасында да бер-берегезгә терәк булыгыз!.. Амин!.. Аннары тагын шул — мине туйга чакырырга онытмагыз!

Георгий стаканын төбенә кадәр эчеп бетерде дә авызын җиң очы белән сөртеп куйды һәм, Мария белән Бачана янына килеп, икесен дә бер-бер артлы чупылдатып үбеп алды.

— Изге аталардан берәрсе «хәер-фатиха бирү, никах уку кебек эшләрне Георгий Тушмалишвилига караганда шәбрәк башкарам мин», дип мактанып карасын менә хәзер!— дип көлеп өстәде Георгий һәм күкрәген кагып куйды.

— Рәхмәт сиңа, Георгий абзый!— диде Бачана. Мария исә, башын игән килеш, сүзсез генә басып тора бирде.

— Ә балаларыгыз сезнең матур булачак! Дөньяга күбрәк китерегез!— дип, Георгий кулына букчасын алды.

— Китәсезмени инде, Георгий абзый?— дип сорады Бачана, аның белән аерылышасы килмичә.

— Китәргә кирәк, терлек-туар колхоз бакчасына керә-нитә калса, каравылчы мине тереләй тотып ашар!.. Ярый, балалар, хуш булып торыгыз! Бу тирәләргә тагын шулай килеп чыга калсагыз, эзләп табыгыз мине, мин шушы тирәдә булырмын...

— Сау булыгыз, Георгий абзый! Кешесез, аулак бу сахрада синең хәлеңә кергән, сине ярдәменнән ташламаган һәркемгә дә — ир-атмы ул, хатын-кызмы — ходай тәгалә сәламәтлек бирсен үзләренә!— Бачана белән Георгий каты итеп кулларын кысыштылар да карт үз юлына китеп барды. Ләкин берничә адым атлауга, ул кинәт артына борылды һәм хәтере калгандай:

— Мария, әллә син миңа ачуландыңмы? Никахны начар укымаганмындыр бит?— дип кычкырды.

Мария томырылып Георгий янына йөгереп барды да, кочаклап алып, картның сакал-мыек баскан яңакларыннан кат-кат үбеп алды. Аннары, шулай ук кырт борылып, чиркәүгә таба йөгерде.

Бачана, әкренләп ерагая барган картны карашы белән озатып, беркавым карап торды да Мария артыннан чиркәү эченә керде.

Мария өстәл янына килеп тезләнгән, ә Мәрьям ана сурәте каршында өч шәм яныи тора иде.

Бачана аныңниләрдер пышылдавына байтак колак

салып тыңлап торды, әмма бер сүзен дә анык кына ишетмәде, шулай да Мариянең дога укыганын аңлады. Аннары Бачана теге бөгәрләнгән өчлек янына ун сум акча куйды һәм, аяк очларына басып, әкрен генә чиркәүдән тышка атлады.

17

Бачана купега килеп кергәндә, анда инде ике ир кеше нәрсә турындадыр кызып-кызып әңгәмә куертып утыралар иде. Өлкәнрәк дигәненең — авыл кешесе, икенчесе — яшьрәгенең шәһәрдән икәнлеге күренеп тора иде. Бачана аларга сәлам бирде дә, сумкасын багажникка урнаштырып, гәзит укырга кереште. Ләкин ирексездән аларның сүзенә колак салырга мәҗбүр булды, чөнки авыл кешесе бик кычкырып сөйләшә иде.

— Юк инде, хөрмәтле Роланд,— диде ул,— мылтык тоткан кеше янында күз яшен агызып басып торучы ана сыны кирәкми безгә! Безгә һәйкәлнең беләсеңме нинди кирәк: яныннан узганда хәтта таш йөрәкле кешенең дә күзеннән яшь килерлек булсын!

— Ул чагында, хөрмәтле Хута, Леонардо да Винчи яисә Микеланджелоны эзләгез!— диде яшьрәге.

— Әнә Марнеулидагы «Батырлар үсеп җитәр әле» дигән һәйкәлне бер дә Микеланджело коймаган! Минә аны һәйкәл дисәң дә ярый, ичмасам! Кулларына үзләре буе кылыч тоткан шул ике шәрә баланы күргәч, күзләремнән яшь атылып чыкты минем! Сез дә безнең авылда әнә шундыйрак бер һәйкәл салып бирсәгез, безнең өчен Леонардо да Винчига әйләнер идегез!

— Белмим инде... Минем эскизларны күргән идегез ич сез, алар сезгә ошаган да иде кебек, шулаймы?— диде яшьрәге үпкәләгән тавыш белән.

— Әйе, ләкин бит сез аны үзгәртеп эшләргә вәгъдә иткән идегез, шуңа күрә мин сезне худсоветта яклап чыктым да. Югыйсә сезгә эшегез өчен түләмәячәкләр иде. Сүз биргәч үтәргә кирәк иде!.. Ләкин мылтык белән, күз яшьләре кирәкми безгә!..

— Сезгә ярамассың... Корган агачларга эленгән чаң кирәкми, арысланны арканлаган шәрә егет кирәкми! Яралы бөркет кирәкми! Күнитеге белән еланны сыткан солдат та кирәкми! Шулай булгач инде нәрсә генә кирәк соң сезгә?— дип, кулларын җәеп җибәрде Роланд.— Ничек итеп мин Ватан сугышы, анда һәлак булган солдатлар темасын чагылдырырга тиеш?!

— Сугыш вакытында син ничә яшьтә идең?— дип сорады Хута.

— Ул чакта әле мин дөньяга да килмәгән идем!— диде Роланд.

— Алайса, син нәкъ әнә шуны сурәтләп бир!

— Нәрсәне?— дип сорады Роланд аңышып бетмичә.

— Сугышның нәрсә икәнен син, гомумән, белмисең, һәйкәлеңдә нәкъ әнә шуны чагылдыр!

— Ничегрәк була соң инде ул?

— Ничек дисеңме? Әле күптән түгел генә минем оныкм, кечкенә Хута, фронттан кайткан каскамны каяндыр табып алган да шунда... беләсеңме... бер сүз белән әйткәндә, кече йомышын йомышлаган! Башта, кызып китеп, арт сабагын укыткан идем үзенең, соңыннан оялып йөрдем... Ышанасыңмы, төн буе йоклый алмадым!..

— Ләкин бит дөньяда андый һәйкәлнең булуы мөмкин түгел... Һәм, гомумән, скульптор кеше авылыгызга килеп, сезне кукуруз игәргә өйрәтеп йөрмидер бит?!

— Хәзергә әле андый хәлнең булганы юк, ләкин ул скульптор дигәнең кукуруз үстерү буенча нindidер яхшы киңәш бирә ала икән, ник аның сүзенә колак салмаска ди?.. Ә сез ничегрәк уйлыйсыз?— дип, һич көтмәгәндә Бачанага мөрәҗәгать итте Хута.

Бачана гәзитен читкә куйды.

— Гафу итегез, сүзегезнең ни турында икәнен ишетмәдем,— дип алдашты Бачана. Бәхәсләшүчеләрнең берсе дә җиңел генә чигенергә уйламый, шуңа күрә Бачана бәхәскә катнашмаска булган иде.

— Эш менә нәрсәдә,— дип сүз башлады Роланд,— мин алар колхозыннан бер эш алган идем... Сакициао авылы колхозыннан. Хөрмәтле Хута Шелия менә — шул колхозның председателе була... Мин Бөек Ватан сугышына багышланган мемориал төзергә тиеш идем... Эш башланып, һәйкәл өчен дип каралган акча тотылып беткәч, алар минем икенче төрле итеп эшләвемне таләп итә башладылар! Ничек? Ни рәвешле итеп эшләргә аны? Алар билгеләгән суммага шуннан да яхшыракны төзеп булмый! Бирсеннәр акча — мин аларга Эйфель манарасы да корып бирә алам! Ахыр чиктә бит, бөтен эш шул акчага килеп терәлә! Акча өчен әнә Леонардо да Винчи дөньясының иң кабахәт кешесе Чезаре Борджиа белән эшләргә мәҗбүр булган. Ул кеше бит хәтта үзенең анасы белән сеңелесенә...

— Булды, җитте! Сөйләмә!— диде Хута өстәл кырыена ябышып.

— Нәрсә булды?— дип гаҗәпләнде Роланд.
— Аның ише сүзне сөйләргә ярамый!— диде Шелия, бераз тынычлана төшкәч.
— Нинди сүзне?
— Әнә син сөйли торганны!.. Сүз Ватан сугышы турында барганда андый әшәкелек, шакшылык турында кычкырып әйтү түгел, күңелеңнән дә уйларга ярамый!
— Ул кадәр искитәрлек нәрсә әйттем соң әле мин?— диде Роланд кызарып.
— Мин андый сүзләрне кабатлый алмыйм һәм сиңа да киңәш итмим!— дип, Хута сигаретын кабызды.
— Гафу итегез, зинһар!— Роланд, урыныннан торып, купедан чыкты.
— Хөрмәтле Хута,— дип, колхоз председателенә мөрәҗәгать итте Бачана,— әгәр мемориал төзү өчен акча дөрестән дә аз каралган булса, нишләргә тиеш соң ул?
— Исем-фамилиягез ничек сезнең, хөрмәтлем?
— Бачана Рамишвили.
— Хөрмәте Бачана, акча аз каралган дигән сүз беләсезме нәрсә ул? Без бит аннан нindидер гигант мемориал төзүне сорамыйбыз... Безгә аның кечерәге дә ярый, тик әйбәт кенә булсын... Кечкенә дә төш кенә диләрме әле?
— Бәлки, аның хәленнән килмидер. Икенче берәүгә кушыгыз соң!— дип киңәш итте Бачана.
— Шулаймы? Ә халыкка ни дип әйтермен? Акчасы тотылып беткән бит инде аның!.. Менә авылга үзен алып кайтам әле, ничек тели шулай ерып чыксын! Мин аны барыбер үзебез теләгәнчә эшләргә мәҗбүр итәчәкмен! Инде алай да барып чыкмый икән, кәҗә мае чыкканчы чәй плантациясендә эшләтәчәкмен мин аны, акчасын ала белгәч, хезмәтен дә күрсәтсен! Аның ишеләрне генә күргән бар! Беләсегез килсә, мин хәтта Тараси Дараселиянең улына да арт сабагын укыттым! Ә ул моннан да каттәрәк иде!— Хута Шелия үз сүзенә үзе елмаеп куйды һәм Бачанага сигарет сузды. Тегесе сигаретны алды, ләкин кабызмады.
— Ә шулай да сезгә ниндирәк мемориал кирәк соң?— дип кызыксынды Бачана.
— Әлеге һәйкәл яныннан узганда «нәрсә икән бу?» дип баш ватып торырлык булмасын, кешеләр, аңа күз салуга, барган җирләреннән тукталып, уйга калырлык булсын! Әнә шундый мемориал кирәк безгә!

— Әйе, дөрестән дә катлаулы мәсьәлә!— дип көлемсерәде Бачана.

— Шулай, җиңел түгел! Ә беләсезме нәрсә җиңел булды? Күптән түгел без терлекләргә ферма салдырган идек. Шуны бизәргә дип бер рәссамны чакырттык. Беләсезме нәрсә ясады ул? Ферманың бөтен стенасын сыер, дуңгыз, кәҗә сурәте белән тутырган. «Нәрсә бу?» — дип сорыйм тегеңәрдән. «Йорт хайванын танымаган колхоз председателен беренче күрүем»,— ди бу миңа. «Эттән туган нәрсә,— дим моңарга,— стенага да шулар сурәтен төшермәсәң, ферманың үзендә мал-туар беткәнме әллә!» — дим. «Нәрсә ясарга иде соң?» — дип сорый бу шуннан. «Син башта бу рәсемеңне сөртеп ташла, аннары нишләргә икәнен уйлашырбыз»,— димен.

— Нишләдегез инде шуннан?

— Нишләдекме? Мин аңа кулларына стакан тоткан ике шәрә бала: малай һәм кыз сурәте ясарга куштым. Әйләнә-тирәдә яшел болын, чәчәкләр. Шул болында сыер йөри. Балалар, стаканнарын тотып, сыердан сөт сорыйлар. Менә шул.

— Ә сыер нәрсә дип әйтә соң?— диде Бачана көлемсерәп.

— Миңа үлән бирегез, мин сезгә сөт бирермен дип әйтә!— дип көлде Хута. Ә рәсем бик шәп килеп чыкты. Кайчагында, шунда барып, озаклап карап торырга яратам мин. Тәки ясый алды бит, эттән туган нәрсә! Югыйсә, тоталар да: «Леонардо да Винчи кирәкмени»,— дип үзәккә үтәләр. Син ничек телисең, шулай яса, тик мин теләгәнне яса! Хак сүз сөйлимме мин, хөрмәтле Бачана?

— Хактыр, мөгаен... Тик шулай да рәссам кешенең үз фикере, үз уе да булырга мөмкиндер бит... Сәнгать дигәнең бик четерекле нәрсә ул...

— Әйе, сүз нәкъ әнә шул сәнгать турында бара да инде... Югыйсә сыер сурәте ясап куялар да — шуның белән эш бетте! Сыерны аны икенче класста укыганда ук ясый идем инде мин... Антон Гугунава исемле рәсем укытучысы бар иде безнең, шул өйрәткән иде... Үзе дә сыерларны шундый оста итеп ясый иде, нәкъ тере кебек инде менә, тотып савасы килә башлый иде үзләрен!.. Ә бу... Роланд дигәннәре... Мылтыклы кеше, мылтыклы кеше дип тәрәлеп катты бит! Әгәр инде алай мылтыклы кеше кирәксә, мин әллә кайчан кулына чып-чын мылтык тоттырып, берәр ир-атны бастырып куйган булыр

идем! Әллә авылда җилкуарлар беткән дисеңме?— Хута сигаретын төтәтә башлады, аңа ияреп Бачана да кабызды.

Роланд коридорда басып торып ялыкты булса кирәк, әллә инде үпкәсе сүрелдеме: ул, купега кереп, тыптын гына әүвәлге урынына килеп утырды.

— Син нәрсә, улым, әллә үпкәләдең инде? Хәтереңкалырдай сүз әйтмәдем шикелле!— дип, Хута бирчәйгән кулы белән Роландның башыннан сыйпап куйды һәм, Бачанага карап, сүзен дәвам иттерде:— Хәзерге яшьләр әзергә бәзер генә яшәргә ярата шул! Минем улым әнә, мәктәпне тәмамлауга, ике балалы бер хатынга өйләнде! Хәтта шунда да эш күрсәтәсе килми бит хәерсезнең!.. Ә сезнең ничә балагыз бар, хөрмәтле Бачана?

— Өйләнмәгән мин.

— И-и-и, менә монысы гафу итәрлек эш түгел инде, хөрмәтле Бачана.

— Ә сезнең ничәү?

— Шул берәү генә инде, әле әйттем бит... Ләкин гаеп миндә түгел. Хатыным, бичара, бик иртә үлеп китте. Мин фронттан кайтканда дөнья куйган иде... Ә менә малай... Начар егет түгел иде үзе, тик әлеге мәсьәләдә минем белән килешеп бетми. «Бу ике бала — синеке, әлбәттә,— димен,— тик шулай да чын үзеңнеке түгел,— дим,— ичмасам хет берне генә үзеңнекен булдыр! Хайван да әнә синнән яхшырак, кәҗәбез берьюлы өч бәти алып кайткан!» — дим. «Кәҗәнең аның ни кайгысы бар,— ди бу миңа.— Ашаган нәрсәсе печән генә, кием гел дә кирәк түгел: балалары итекле-тунлы булып туа. Ничек итеп мин ул балаларны киендереп бетерә алыйм, джинсы чалбар гына да спекулянтларда ике йөз сум тора!»— ди бу.

— Дөрес әйтә!— дип әңгәмәгә катышты Роланд.

— Синең үзеңнең ничә балаң бар соң, яклаучы?— дип аңа таба борылды Хута.

— Миңа, хөрмәтле Хута, утыз яшь, минем өч балам бар, бүгенгесе көндә хатыным дүртенчесен көтә!— дип үҗәтләнеп җавап бирде Роланд һәм тәрәзәгә таба борылып утырды.

— Менә егет икәнсең, ичмасам!— дип, кулын кулга шапылдатып сугып куйды Хута.— Менә моны аңлыйм мин! Герой ата! Хәтереңне калдырган булсам, зинһар гафу ит!

— Әйдә инде...— дип кулын селтәде Роланд.

— Гафу ит мине, улым, гафу ит!— дип кабатлады Хута.

— Нәрсә инде сез ул кадәр...— диде Роланд кыенсынып һәм, әңгәмәне икенчегә бормакчы булып, Бачанага мөрәҗәгать итте:— Сезнең кай тарафларга китеп барышыгыз, хөрмәтле Бачана?

— Сухумига, командировкага.

— Сезгә рәхәт... Диңгездә коеначаксыз...

Бачана, елмаеп, башын кагып куйды.

— Безнең эш нишләр икән соң инде, хөрмәтле Роланд?— дип башлады Хута.

— Нинди эш ул тагын?— дип аңламаганга салышты тегесе.

— Соң, һәйкәл диюем инде...

— Уйладым инде мин, хөрмәтле Хута, уйладым! Тик мин үземчә хәл кылдым, сез өйрәткәнчә түгел!— диде Роланд ачуы килеп һәм кабат тәрәзәгә борылып утырды.

— Ничегрәк була инде ул?— диде Хута сагая калып.

— Ничек дисезме? Башына каска кигән, кулына мылтык тоткан солдат басып тора! Аңа яланаяклы яшь бер хатын килеп сарылган, хатынның итәгенә берсеннән-берсе кечерәк дүрт шәрә бала куркышып ябышкан! Менә шул!— Роланд кызарынып китте, сугышырга җыенган кеше төсле, йодрыгын төйнәп, кулларын өстәлгә салды.

— Менә, әйттем бит мин сиңа!— дип, Хута сөенеченнән нишләргә белмичә, урыныннан сикереп торып, Роландның маңгаеннан үбеп алды.— Хәзерге яшьләр уйларга иренә дип, әйткән идемме мин сезгә, хөрмәтле Бачана! Әзергә бәзер булып кына яшәргә ярата дип! Аз гына башын эшләтеп караса, таулар күчерә ала бит ул! Инде ышандыгызмы менә?!

Бачананы, бик тиз кайтып җитәргә кушып, командировкадан редакция эшләре буенча чакыртып алдылар.

Үзәк Комитет инструкторы аңа туры гостиницага шылтыратты:

— Сезгә секретарь кушканны тапшырам: иртәгә иртәнге унда сез секретарь янында булырга тиешсез!

— Нинди мәсьәлә буенча?— дип сорады Бачана, ләкин трубкада «пип-пип» иткән тавыш кына яңгырап калды.

Үзәк Комитет секретаре белән әңгәмә кыска булды. Хәер, моны әңгәмә дип атавы да кыен иде, секретарь

гел сөйләде, ә Бачана тыңлап кына утырды. Аннары, нәрсә әйтә ала иде соң ул, чөнки моннан да хурлыклырак эшне күз алдына китерүе дә мөмкин түгел: аның бер хезмәткәре көпә-көндез, редакция бинасында ришвәт алып маташканда өстенә барып кергәннәр!

Көндезге сәгать икедә Бачана ашыгыч рәвештә партия членнарын җыеп алды. Редколлегия әгъзалары һәм редакция хезмәткәрләреннән тыш җыелышта Үзәк Комитет инструкторы белән Эчке эшләр министрлыгыннан әлеге операцияне үткәрүче вәкил дә бар иде.

Җыелышны партком секретаре ачты:

— Мәсьәләне тикшерүгә керешкәнче, мин Шалва Хелая иптәшнең әлеге ришвәт вакыйгасы турында ачыграк итеп сөйләп бирүен үтенер идем.

Хелая тамагын кырып куйды, кара галстугын төзәткәләп алды да сүзен башлады:

— Моннан ике ай элек сезнең редакция хезмәткәре Шота Цуладзеның куркытып-янап Калоян фамилияле бер иптәштән акча таләп итүе хакында безнең бүлеккә хәбәр килгән иде. Әлеге Калоян өстеннән редакциягә гаепләү хаты килгән булган икән...

— Хелая иптәш, әлеге хәбәр моннан ике ай элек алынган, ә нигә мин бу турыда менә хәзер генә ишетәм?— дип гаҗәпләнде Бачана.

Хелая беравык ык-мык итеп торды да:

— Эш шунда ки, хөрмәтле Бачана, редакция коллективын һәм дә шик төшкән Цуладзены вакытыннан элек борчымас өчен, әлеге хәбәрнең дөреслеген әүвәл тикшереп карамакчы булдык. Ә бәлки, ул шик бөтенләй нигезсездер? Шуңа күрә, хәбәрнең дөреслегенә ышанмас борын, сезгә әйтмәскә уйладык.

— Ә хәзер әнә сезнең ул «шик төшкән» кешегез төрмәдә утыра һәм бөтен редакция исеменә дә кара ягылды. Сезнеңчә, шулай яхшыракмы?— дип сорады Бачана.

— Әй-е-е... Нишләмәк кирәк... Ләкин факт факт булып кала: Цуладзе җинаять өстендә фаш ителде...

— Карагыз әле, иптәш Хелая, сез ришвәт алуны булдырмас өчен тырыштыгызмы, әллә инде Цуладзены сак астына утыртыр өченме?— дип сорады Бачана үзен көч-хәл белән тыелырга мәҗбүр итеп.

— Иптәш редактор, минем, әлбәттә, сезгә хөрмәтем зур, ләкин миңа шунысы аңлашылмый: ни өчен әле сез ришвәтче хезмәткәрегезне яклыйсыз?— дип җавап кайтарды Хелая.

— Мин дә якламагач, тагын кем яклар аны?— диде Бачана сәерсенеп.

— Гаепсез кешеләрне якларга кирәк!

— Цуладзе ничек кенә гаепле булса да, дөрес эшләмәгәнсез сез!

— Иптәшләр, сез мине мәгълүмат алыр өчен чакырдыгыз булса кирәк. Әгәр инде Цуладзе урынына партиядән мине чыгарырга җыенасыз икән, турысын әйтеп сөйләгез!— диде Хелая хәтере калып.

— Гафу итегез, мин кызыбрак киткәнмен...

Хелая, папкасын ачып, аннан бер бит кәгазь чыгарды.

— Менә бу — редакциягә сезнең исемгә килгән аноним хат, Бачана Акакиевич.

— Ничек сезнең кулга килеп эләккән соң ул?

— Кулга алынган Цуладзедан табылды. Ришвәт алганнан соң, әлеге хатны ул Калоянның күз алдында ертып ташларга тиеш иде.

— Күрсәтегез әле!— дип, Бачана хатка үрелде.

— Рәхим итегез!— дип, Хелая хатны аңа сузды.

— Кычкырып укыгызчы!— дип үтенде редколлегия әгъзаларынан берсе.

Кәгазь битенә күз салуга, Бачана әлеге аноним хатны да, сул почмагына үз кулы белән язылган резолюцияне дә исенә төшерде. Хат озын түгел һәм эре-эре басма хәрефләр белән язылган иде. Борчылуның чигенә җиткән Бачана хатны укый алмаячагын аңлады.

— Мә, укып бир әле!— диде ул, хатны партком секретарена сузып.

«Хөрмәтле редактор!— диелгән иде хатта.— Урбнели урамында төрле караңгы эшләр эшләнә. 571 номерлы йортта яшәүче Гайоз Константинович Калоян (кибет мөдире) һәм аның шунда ук яшәүче сөяркәсе Ксения Гавриловна Вартагава (шул кибетнең кассиры) төрле вакытта һәм тәрле микъдарда ризыгына һәртөрле агулы матдәләр салып, үтерү максаты белән, даими рәвештә Калоянның хатынын, Лили Герасимовна Аманатидзены агулыйлар. Бүгенге көндә ул хатын агуланып больницада ята. Хөрмәтле редактор! Кайчанга кадәр ул азгын террорчылар безнең җирне таптап йөрерләр? Кайчанга кадәр ул караңгы эшләр яшерен килеш кала бирер? Үзегезнең үткен каләмегез белән череп таркалган бу кеше үтерүчеләрне тиз арада фаш итүегезне үтенәм! Хөрмәт белән — Гуманист!»

— Хатта редакторның резолюциясе бармы?— дип сорады баягы редколлегия әгъзасы.

«Ип. Ш. Цуладзега. Хатны Эчке эшләр министрлыгына җибәрүегезне үтенәм. Б. Рамишвили»,— дигән сүзләрне укыды партком секретаре.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Бачана секретарьның кулыннан хатны алып Хелаяга кайтарып бирде.

— Цуладзе хатны министрлыкка җибәрмәгән!— диде шунда Хелая һәр сүзенә басым ясап.

Бачана дәшмәде. Эшнең ничек-ничек булганлыгы аңа хәзер бик яхшы аңлашыла иде. Хелая исә сүзен дәвам итте.

— Шота Цуладзе хатны министрлыкка җибәрмәгән. Ул Калоянның өенә үзе барган һәм аны исемсез хатның эчтәлеге белән таныштырган. Калоян, әлбәттә, язылганнарның барын да инкяр иткән. Вартагава да хатта әйтелгән фактларга каршы килгән. Цуладзе исә, «редакция бу эшнең төбенә төшәргә тиеш» дип, китеп барган. Калоян, әлеге күңелсез хәлләрдән котылырга уйлап, теге хатны юк итү шарты белән, Цуладзега биш йөз сум акча тәкъдим иткән. Әмма Цуладзеның алай гына ризалашасы килмәгән. Калоян исә тагын шуның кадәр вәгъдә иткән. Цуладзе аннан ике мең сум сораган. Әлеге сумма, күрәсең, Калоянга бик кыйммәт тоелган һәм ул, «газетаның әдәби хезмәткәре мине һәм минем белән бергә эшләүче хатынны куркыту-янау юлы белән акча алмакчы була» дип безгә гариза язды... Шуннан без, оператив группа төзеп, Цуладзега тапшырырга дип, Калоянның кулына ике мең сум акча тоттырдык. Цуладзе артыннан исә күзәтү оештырдык.

Хелая папкасыннан тагын бер бит кәгазь алды:

— Унҗиденче сентябрь көнне, көндезге сәгать өчтә «Баһадир» универмагы урнашкан йортның икенче подъездында Калоян белән Цуладзе очрашалар. Калоянның гаризасыннан күренгәнчә, Цуладзе «редактор әлеге эшне өйрәнеп, газетага мәкалә язарга кушты» дигән сылтау белән акчадан баш тарта.

— Гафу итегез, хөрмәтле Шалва, Калоян язган гаризаның дөреслеккә туры килмәве сезгә мәгълүм идеме?— дип сорау бирде редакциянең җаваплы секретаре.

— Юк, мәгълүм түгел иде, чөнки ул вакытта әле редакторның резолюциясе салынган хат безнең кулга кермәгән иде.

— Димәк, сезнең әлеге операциягез барган вакыт эчендә редактор үзе дә шик астында булдымы?

— Юк, бер генә минутка да башыбызга кереп чыкмады. Чөнки бит Цуладзе һаман «редактор тикшерүне таләп итә» дип бара.

— Сезнеңчә, ни өчен Цуладзе шундый адым ясаган?

— Бәяне күтәрер өчен.

Җаваплы секретарь тынып калды. Хелая исә сүзен дәвам итте:

— Ун көннән без эспериментны тагын кабатладык. Очрашу Ташбака күле буендагы этнография музее урнашкан биналарның берсендә билгеләнде. Бу юлы да, һаман шул бер сәбәпне сылтау итеп, Цуладзе акчаны алмый... Хәлбуки, Калоянга Эчке эшләр министрлыгына хатны җибәрттермәс өчен редактор белән сөйләшергә вәгъдә иткән булса да. Калган ягын инде Калоян үзе чамаларга тиеш була... Егерме җиденче октябрь көнне, редактор командировкага киткәнлектән, бәлки, Цуладзе кыюрак эш итәр дип, без экспериментны тагын ясап карадык. Һәм бу юлы инде без көткәнебезгә ирештек. Иртәнге сәгать унда, редакция бинасында Цуладзе Калояннан акчаны алды!

— Исбатлардай дәлилләрегез дә бармы?— дип сорады Үзәк Комитет инструкторы.

— Бар. Әлеге акчалар Цуладзеда иде! Ул үзе дә хатасын таныды. Әмма кичә ул, башта сөйләгән сүзләреннән баш тартып, «акчаны бурычка алып торган идем» дип белдерде.— Хелая папкасын ябып куйды.

Бачана ни үле, ни тере хәлдә, нәрсә әйтергә дә белмичә, өстәл артында утыра бирде.

— Хөрмәтле Шалва,— дип сүзен башлады ул, ниһаять,— сез: «Цуладзе ике тапкыр акчадан баш тартты, бары өченче очрашуда гына Калояннан акчаны алды»,— дидегез. Аңлатып бирегезче миңа, зинһар: ни өчен әлеге экспериментны өчәр тапкыр кабатларга кирәк булды сезгә? Бәлки, кеше, акылына килеп, үзенең хатасын аңлаган, законга каршы килә торган бу ниятеннән баш тартмакчы булгандыр? Сез шул турыда уйлап карамадыгызмы?

— Сез безнең эшнең нечкәлекләре белән таныш түгел, шуңа күрә әлеге вакыйганы кешенең акылына килүе, хатасын төшенүе дип икенче төрлерәк итеп аңлатмакчы буласыз. Ләкин бу, сез уйлаганча, хакыйкатькә туры килми... Әгәр Цуладзе башта ук бәяне арттыру турында Калоян белән сатулашмаган булса, бәлки, без

аның яхшы күңелле кеше икәненә ышаныр да идек. Аның бит әлеге эшне бары тик бәяне арттыру өчен генә шулай сузганы көн кебек ачык!

— Ләкин бит таләп ителгән сумманы Қалоян төп-төгәл итеп алып килгән. Ни өчен соң ул барыбер баш тарта?

Хелая урындыгында кыбырсып куйды.

— Миңа калса, Цуладзе башта әйтелгән бәяне тагын да күтәрергә исәпләгән. Шул сәбәпле без аны өч тапкыр сынап карадык.

— Белмим, сынап карау дип сез нәрсәне атыйсыздыр, әмма минемчә, бу — кешене кызыктыру, нәфсен котырту.

— Безнең максат — җинаятьнең тамырын корыту! — диде Хелая катгый тавыш белән.

— Миңа калса, сезнең максатыгыз — җинаятьне фаш итү, күңелгә вәсвәсә салу, ымсындыру түгел! — дип җавап бирде Бачана.— Әгәр сез бу турыда вакытында хәбәр иткән булсагыз, мин Цуладзены эштән алыр һәм шуның белән җинаятькә юл куймас идем!

— Хөрмәтле Бачана, ришвәтчеләр белән алай назланып йөрергә безнең вакытыбыз да, мөмкинлегебез дә юк!

— Ә Қалоян белән ни сәбәпле назланасыз?

— Қалоянга кагылышлы эшне икенче бер группа өйрәнә... Исемсез хаттагы фактлар расланса, аны нәрсә көткәнен сез яхшы беләсез...

— Мәгълүматларыгыз өчен рәхмәт, хөрмәтле Шалва! — диде Бачана, урыныннан күтәрелеп. Хелая бүлмәдәгеләр белән хушлашты да тиз-тиз атлап кабинеттан чыгып китте.

— Кемнең әйтәсе сүзе бар, иптәшләр? — дип бүлмәдәгеләргә мөрәҗәгать итте партком секретаре.

— Миңа мөмкинме? — дип кулын күтәрде редактор урынбасары.

— Рәхим итегез!

Урынбасар аягына торып басты, алдында яткан кәгазьләрне рәтләштереп куйды. Күрәсең, ул сөйләргә дип алдан хәзерләнеп килгән иде, тик шулай да шактый дулкынлана иде.

— Бүген бирелдә Үзәк Комитет вәкиле катнаша, шул сәбәпле мин, коммунист буларак, барысы турында да ачыктан-ачык сөйләп бирергә мәҗбүрмен. Әйе, бүген без, һичшиксез, Цуладзены партия сафларыннан чыгарачакбыз, әмма да ләкин безнең редактор аны үзенең

канат астына алып, һәрвакыт яклап килмәсә, бу эшне без инде күптән эшләгән булыр идек... Цуладзе совет журналисты дигән изге исемгә кара якты! Җәмәгатьчелек алдында бөтен редакциябезнең яман аты таралды! Шул сәбәпле кабатлап әйтәм: бар җаваплылык иптәш Рамишвили өстенә төшәргә тиеш! Рамишвили дусты Цуладзены редакциягә үзе чакырып китерде, ул кадәр күрсәткән эшләре булмаса да, аны шушы көнгә кадәр яклап килде, һәм менә бүген дә әле, анысын үзегез дә сизгәнсездер, һаман аны акларга тырыша... Нәкъ менә редакторыбызның әнә шундый «тәрбияви» эш алып баруы нәтиҗәсендә без ямьсез хәлдә калдык... Ахыр чиктә, нинди кеше соң ул әлеге Цуладзе? Ышанычсыз дус,— хәер, мин беркайчан да аның белән дустанә мөнәсәбәттә булмадым,— начар бала, начар туган, начар ата, булдыксыз әдәбиятчы һәм аннан да бигрәге — ришвәтче!.. Менә кем ул Цуладзе! Аның редакциягә эшкә килүенә мин һаман каршы тордым, һәм әгәр мин редактор булсам, ул безгә килмәгән дә булыр иде... Цуладзеның ришвәт алу белән шөгыльләнүе турында мин үз вакытында Үзәк Комитетка да, Эчке эшләр министрлыгына да хәбәр иткән идем. Шул сәбәпле мин нинди дә булса җаваплылыкны үз өстемә алмыйм, бар җаваплылыкны тулысынча иптәш Рамишвилига йөкләүне таләп итәм.

Урынбасар, кесәсеннән ап-ак яулыгын чыгарып, маңгаендагы тирне, ияк очын сөртеп алды да, әйбәтләп үтүкләнгән чалбар балакларын саклык белән генә күтәрә төшеп, урынына кире утырды.

Урынбасар сөйләгән арада, Бачананың күз алдыннан студент еллары тезелеп үтте. Менә алар өчесе, ахирәт дуслар — Бачана, хәзерге урынбасар, Цуладзе — университет клубына җыелып, студент сәхнәсендә чыгыш ясыйлар, әнә алар студент телендә «Фән ресторааны» дип исемләнгән ашханәдә соңгы телем икмәкне бүлешеп ашыйлар, әнә алар Удзо, Шиомгвиме [1] монастырена экскурсиягә баралар, өчесе дә бер кызга гашыйк булалар... Барысын да исенә төшерде Бачана һәм аның, бу яшьлек елларын хәтерендә саклаган һәркем ишетелерлек итеп, кычкырып-кычкырып елыйсы килә башлады...

---

[1] *Удзо, Шиомгвиме* — Тбилиси тирәсендәге борынгы монастырьлар.

— Тагын кемнең сүзе бар?— дип сорады партком секретаре.

— Миндә Гиви иптәшкә бер сорау бар!— диде әдәби хезмәткәр.

— Нинди сорау?— дип гаҗәпләнде урынбасар.

— Менә син: «Цуладзеның ришвәтче икәнен беләидем»,— дисең. Ничә елдан бирле мәгълүм инде бу сиңа?

— Биш-алты еллап булыр,— диде урынбасар озын-озак уйлап тормастан.

— Алайса, ни өчен соң син узган ел аңа партиягә керергә рекомендация бирдең?

Урынбасар агарынып китте, кипкән иреннәрен ялап алды һәм:

— Урынсыз сорау бу...— дип сөйләнеп куйды.— Беренчедән, мин кемгә һәм кайчан рекомендация биргәнемне хәтерләп бетерә алмыйм, икенчедән, партиягә керү, яисә чит илгә бару өчен рекомендацияләр, гадәттә, формаль төстә генә бирелә...

— Гиви Давидович, сез моны шаярып сөйлисезме, әллә чыннан да шулай уйлыйсызмы?— дип сорады Үзәк Комитет инструкторы, исе китеп.

— Нәрсә, әллә сез партиягә керү өчен рекомендация биргән кешеләрнең барын да истә тотасызмы?— дип, урынбасар да үз чиратында аңа сорау бирде.

— Әлбәттә! Башкача булуы мөмкин дә түгел!— диде инструктор кулларын җәеп.

— Миндә бер сорау бар,— диде партком секретаре.— Ярый, Цуладзега кайчан рекомендация бирүеңне син хәтерләмисең дә ди. Алайса ни өчен син моннан бер ай элек, Цуладзеның ришвәтче һәм кеше талаучы булуын белә торып, аның белән командировкага чыгып киттең?

— Редактор тапшырган эшкә каршы килә алмыйм бит инде мин!

— Редакторның катнашы юк монда! Ул ялда иде. Цуладзега да, үзеңә дә командировканы син яздың!

— Әйе, алай-болай тагын кыек юлга кереп китмәсен дип бардым мин аның белән!— диде урынбасар судан коры чыгарга исәпләп.

Әдәби хезмәткәр шаркылдап көлеп җибәрде. Секретарь карандашы белән өстәлгә суккалап куйды.

— Тагын бер сорау бирергә мөмкинме?— дип, редколлегия әгъзасы сүз алды.— Гиви Давидович, сез Цуладзеның яман эшләре турында үз вакытында Үзәк Ко-

митетка һәм Эчке эшләр министрлыгына хәбәр иткән идем, дисез. Ни өчен әлеге инстанцияләр сезнең сүзегезне игътибарсыз калдырды, шуны аңлатып бирсәгез иде.

— Ул чагында эш башында башка җитәкчеләр тора иде... Аларның күбесе инде хәзер ул урында эшләми, кайберләре, гомумән, дөньядан китте...

— Ни өчен сез бу турыда яңа җитәкчелеккә хәбәр итмәдегез?

— Монысы тагын ни дигән сүз?— диде урынбасар төрпә генә.

— Шулай дигән сүз, кадерлем: әгәр сез җитәкчелеккә барысы турында хәбәр итеп тә, алар сезнең сүзегезгә колак салмый калган булса, менә бүген безнең өскә төшкән гаепне ничектер бераз җиңеләйтер иде. Менә шул!— дип җавап бирде редколлегия әгъзасы.

— Мин үземне бернәрсә өчен дә җаваплы дип санамыйм һәм шулай ук кемнең дә булса яклавына да мохтаҗ түгелмен!— дип кырт кисте урынбасар.

Фикер алышулар дәвам итте. Әлеге күңелсез вакыйгага һәммәсе бик нык борчыла иде, аннары һәммәсе, шулай ук бертавыштан, Цуладзены партия сафларыннан чыгаруны таләп итте.

Менә сөйләргә Бачананың чираты җитте. Ул аягүрә торып басты һәм тыныч-салмак, ләкин калтыравык тавыш белән сүзен башлады:

— Дусларым, монда әйтелгәннәрнең барысы да диярлек хак сүз. Әйе, Шота Цуладзе — минем яшьлек дустым... Без аның белән бергә университетта укыдык, Ваке һәм Верэ буйлап бергәләшеп йөрдек... Ул һәрвакыт бер дигән иптәш, балалары өчен үлеп торган ата, ата-анасына игелекле бала булды... Редакциягә мин аны дустым булганы өчен түгел, бәлки, зирәк акыллы һәм искиткеч сәләтле журналист буларак чакырдым... Ләкин миндә, күрәсең, аңа йогынты ясар өчен, тәҗрибә дә, осталык та, абруй да җитеп бетмәгән... Кайбер кылган эшләре минем игътибардан читтә калган... Дөресен генә әйткәндә, Цуладзе белән булган хәлне мин бары тик «бәлки, акылына зыян килгәндер» дип кенә аңлата алам... Җаваплылыкны үз өстемә алудан качарга җыенмыйм. Әйе, урынбасарым белән килешәм: җаваплылык тулысынча минем өскә төшә, һәм мин моңа әзер...

Бачана урынына утырды һәм су салып бирүләрен үтенде...

...Иң элек аның уң як җилкәсе авыртырга кереште. Аннары әрнү әкрен генә, сулкылдап, күкрәгенә таба үрмәләде һәм сул имчәк турысына җитәрәк туктап калды. Шуннан кемнеңдер сөялле тупас кулы, күкрәк читлегенә кереп, йөрәкне учына йомарлап тотты, йөзем тәлгәшен сыткандай, рәхимсез кысарга керешге. Ул аны ашыкмыйча, тырышып-тырышып кысты: бер-ике, ике-өч, өч-дүрт... Инде, ниһаять, сыгылып, тәмам хәлен җуйган йөрәктә канның тамчысы да калмагач, шул ук кул аны гамьсез генә читкә алып ыргытты...

18

Ул көнне Иорам-ата янына хәл белүчеләрдән бер кеше килде. Аларның аңлаешсыз һәм гаять шомлы тоелган әңгәмәсе озакка сузылмады.

— Атакай,— дип сүзен башлады әлеге кеше, сәлам биргәннән соң,— теге төнне сезнең гомерегезне саклап калган дусларыгызның исем-фамилияләрен онытсагыз, алар бик шат булырлар иде!

Килүче кеше Бачанага аркасы белән утырганлыктан, ул аның йөз чалымнарын күрә алмады, әмма Иорам-атаның кыяфәтенә караганда, керүченең яман бер зат икәне аңлашылып тора иде.

— Тәрене дә онытыргамы?— дип сорады Иорам-ата.

— Шулай ук адресны да!

— Ләкин бит «Ашыгыч ярдәм» станциясендә адресны язып алалар,— диде йөзеннән кан качкан рухани.

— «Ашыгыч ярдәм» машинасы сезне урамда яткан җирегездән табып алды, ә станциягә телефон-автоматтан шылтыраткан булганнар.

— Димәк, барсы да алдан уйлап эшләнгән иде?

— Әйе.

— Ә тәре?— дип кабатлады Иорам-ата.

— Белмим, нинди тәре турында сөйлисездер сез...

— Беләсез!

— Миңа үзем сөйләгән кадәресе генә мәгълүм!

— Нәрсә, сезнеңчә, дөньяның түбәсе салам белән генә ябылган булып чыгамыни инде?— диде изге ата күңелсез көлемсерәп.

— Чирәп белән, атакай, Марсель чирәбе белән,— дип төзәтте аны әлеге бәндә.

— Теге адәм актыгыннан сез тәрене күпмегә сатып алдыгыз?— Иорам-атаның тавышы калтыранып китте.

— Мин сезгә чын дөресен сөйлим: ниндидер тәре

турындагы сүзләрегез миңа гомумән аңлашылмый. Әгәр инде авыру баштан шулай сөйләнәсез икән — мин сезгә берничек тә ярдәм итә алмыйм. Әгәр инде сезгә тәре кирәк булса, яисә, киресенчә, сез аны сатарга теләсәгез — турыдан-туры үземә әйтегез, ярдәм итәрмен. Кыенсынып тормагыз, бер тиен өчен сатулаша торганнардан түгел без...

— «Без» дигәнегез кем инде ул?— дип сорады Иорам-ата.

— Без!— дип кырт кисте әлеге зат.

— Ә сез үзегез кем?

— Мин — арадашчы...

— Сезнең белән сөйләшер сүзем юк минем!

— Мин дә сөйләшергә дип бик ашкынып тормыйм...

— Алайса — сау булыгыз...

— Сезнең белән кабат-кабат очрашудан мәгънә чыкмас дип уйлыйм, шулай булгач — хушыгыз,— дип, килүче кеше аягына торып басты.

— Нәрсә, куркытмакчы буласызмы?— дип сорады Иорам-ата, ләкин изге атаның инде коты алынганлыгы тавышыннан ук сизелеп тора иде.

— Юк, хәзергә кисәтеп кенә куюыбыз!

Әлеге сәер, аңлаешсыз әңгәмәгә колак салып, монарчы сүзсез ята биргән Бачананы таныш булмаган кешенең соңгы сүзләре тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Агай-эне, бире килегезче!— дип үтенде ул. Бачананың бу сөмсез зат белән гәп куертырга һич кенә дә теләге юк иде, ләкин шулай да бу адәм актыгының йөз чалымнарын хәтерендә калдырасы килде аның.

Таныш булмаган кеше ашыкмыйча гына Бачанага таба борылды һәм, мыскыллы елмаеп, ясалма бер әдәплелек белән:

— Миңа әйтүегезме?— дип сорады.

Бачана, аңа карауга, имәнеп китте: әлеге кешенең йөз-чырае юк иде! Югыйсә аның бөтен җире: авыз-борыны да, күз-колаклары да үз урынында кебек... Тик шулай да төссез йөз чалымнары бернинди тойгы-хис тә, бернинди уй-фикер дә белдермиләр иде. Мондый кешене истә калдыру — мөмкин булмаслык эш, күрәсең. Ә менә үзләренә кирәкле, үзләрен кызыксындырган кешене моныңише бәндәләр җир астыннан да эзләп таба алалардыр. Шуны аңлап, Бачана күзен йомды һәм әлеге затның йөзен хәтерендә калдырмакчы булды, ләкин барсы да юкка гына — билгесез бу затның йөз-кыяфәте нindидер бер шәүлә сыман таралып юкка чыкты.

Бачана кабат күзен ачканда теге кеше инде бүлмәдә юк иде.

— Кем ул?— дип сорады Бачана телдән язган руханидан.— Шундый шөкәтсез кешене беренче күрүем!

— Кеше түгел, иблис ул...

Иорам-атаны больница караватына яткырган бу инфаркт исәп буенча икенчесе иде инде. Хөрмәтле укучы, Ортачала монастыре башлыгын бу яман чир мәшһүр «Декамерон» әсәрен, яисә Валтасар сараендагы мәҗлесне тасвирлаган Даниил пигамбәр язмаларын укыган чакта аяктан еккан дип уйлый күрмәсен тагын.

Иорам-ата бөтенләй көтмәгән-уйламаган җирдән бәлагә тарыды.

1970 елны Париж шәһәрендә эмиграциядә яшәүче туксан яшьлек грузин князе Саурмаг Әмиреджиби вафат була. Әлеге князь, җеназа уку өчен, үзенең гәүдәсен Грузиягә, Ортачала изге троица чиркәвенә алып кайтырга дип васыять әйтеп калдыра. Соңгы минутына кадәр үзе белән йөрткән зөбәрҗәт ташлы алтын тәрене дә ул шушы ук чиркәүнең Мәрьям ана иконасына мирас итеп калдыра.

Әмиреджиби оныгының кызы Кетеван Андроникашвили-Миролюбская гомере буе туган илен сагынып, җирсеп яшәгән нәсел башлыгының васыятен җиренә җиткереп үти: князьне Куки зиратына алып кайтып күмә, ә тәрене, васыятьнамә һәм аңлатма кәгазе белән бергә, Иорам-ата кулына тапшыра.

Аңлатмада, тәренең тасвирламасыннан һәм бәһасеннән тыш, аның Вахтант Горгасал[1] сеңлесе Гурандухтныкы икәнлеге дә язылган була. Уналты яшьлек Горгасалның, аланнар һәм хазарлар явын кырып салып, сеңлесен дошманнардан йолып алганнан соң, әлеге тәрене үз кулы белән сеңлесенең муенына асып куюы әйтелә. Бу мәгълүматлар ни дәрәҗәдә дөрестер һәм ничек итеп бу тәре Әмиреджиби нәселенең кадерле ядкяренә әйләнгәндер — анысын әйтү кыен, әмма тәре искиткеч зур бәһага ия була. Ә инде очын-очка ялгап, көч-хәл белән дөнья көткән Ортачала чиркәве өчен бу бүләк күктән иңгән бер могҗиза кебек тоела, һәм Иорам-ата аны нәкъ шулай — ходайның рәхим-шәфкате дип кабул итә дә.

[1] *Вахтанг Горгасал (502 елны үлгән)* — Грузия патшасы, Тбилиси шәһәренең нигезен салучы.

Шул вакыттан бирле һәр елны, изге ана көнен бәйрәм иткәндә, Иорам-ата ак атлас мендәр өстендә яткан тәрене бик кадерләп, хөрмәт белән сейфтан алып, Мәрьям ана сурәте каршына китереп куя башлый. Гыйбадәт кылучылар, сокландыргыч зөбәрҗәт нурлы күзләре белән бишенче гасыр ераклыгыннан карап торган бу могҗизаны күреп, дулкынланудан калтыранган иреннәре белән тәрене килеп үбәләр, ә Иорам-ата белән аның ярдәмчесе дьякон Авель Арджеванидзе исә, шундый ук дулкынлану кичереп, чиркәүгә килүчеләр, дини хисләргә чамасыз бирелеп китеп, француз экспертларының исәбенчә, 250 мең долларга бәяләнгән изге ядкярне алай-болай эләктереп чыгып китмәгәйләре дип, чиркәү халкына күз-колак булып торалар иде.

Бу хәл 1973 елга кадәр шулай дәвам итте, Мәрьям ана бәйрәме шул рәвешле уза иде.

Ә аннан бер ел элгәре, ягъни 1972 елны, изге ана бәйрәме үткәннең икенче атнасында, Иорам-ата үзенең хөҗрәсендә, күңелләре нечкәреп, инде йөзенче тапкыр Гүзәл Йосыф һәм аның абый-энеләре турындагы кыйссаны укып утырганда, бүлмә ишеге ачылып китеп, бусагада һич көтмәгәндә-уйламаганда дьяк Арджеванидзе пәйда булды.

— Сәлам, Иорамчик!— дип, үзенең башлыгы белән авыз ерып кына исәнләште һәм гөбердәтеп кикереп куйды.

Аннары ул тәмам өнсез калган Иорам-атаның җилкәсенә шапылдатып сугып алды да аның каршында өстен чишенә башлады. Иң әүвәл ул таш идәнгә башлыгын салып томырды, аннары өстендәге чапанын йолкып алып, аны да шул тарафка олактырды, ниһаять, күкрәгендә эленеп торган зур көмеш тәрене тартып өзеп, Иорамның йөзенә ыргытты да ниндидер шайтани бер көлү белән шаркылдарга тотынды. Коты алынган Иорам-ата бары:

— Күз алдымнан югал, иблис!— дип кенә пышылдый алды һәм «тфү, тфү!» дип төкеренеп куйды.

— Хәзер юкка чыгам!— диде Арджеванидзе һәм, бичара изге ата авыраеп киткән уң кулы белән чукынган арада, бөтен христиан дөньясына ләгънәт яудырырга тотынды:

— Барыгызны да алланың каһәре суксын: синең үзеңне дә, поп, атаңны да, балаларыңны да, изге рухыңны да, синең черек чиркәвеңне дә! Төкерәм мин сезнең барыгызга да, үземнең шакшы җаныма да төке-

рәм! Мәгез, тончыгыгыз шул җан белән!— дип дьяк тирән итеп тын алды һәм үпкәсендәге бар сулышын сызгыртып, гыжлатып өреп чыгарды. Хөҗрә эчендә аракы исе, тагын әллә нинди күңел болгаткыч әче-төче исләр таралды.— Мәгез, бөтенләе белән алыгыз ул җанны, карап карарбыз, нәрсәгә ярар икән ул сезгә!.. Киттем мин, ошбу кара карга киемен сезгә бүләк итәм!— Ул идәндә яткан чапан белән башлык өстенә лач итеп төкерде дә, аларны аяк очына эләктереп, очыртып җибәрде.— Ә менә бу бер потлы тәрене муеныңа ас та Курага сикер, елга төбендә ничә таш барын санарсың, бәлки!

— Акылыңа кил, ахмак! Аллаһе тәгаләнең каргышы төшмәсен! Көфер сүзләреңне ишетсә, телеңнән яздырыр тәңре, бичара җан!— дип, Иорам-ата бәйдән ычкынган дьякны әдәп хөкеменә тарттырмакчы булып.

— Егерме ел буена ишетмәде ул мине, инде бер бүген генә минем сүзләрем аңа барып ирешерме? Чукрак ул синең аллаң, атакай, чукрак! Каядыр болытлар арасына менеп кунаклаган да кукраеп утыра шунда! Җиргә төшеп, тиешле больнисенә барса, бәлки, ул бетәшкән картны терелтеп чыгарырлар иде!.. Сиңа да, атакай, киңәшем шул: салып ташла бу хөлләңне, дөньяда әле тән дигән нәрсә дә бар бит! Анысы аның җаннан кадерлерәк! Ә мин сездән китәм! Биредә берәүгә дә бернәрсә тиеш түгелмен! Әгәр җаным кирәк булса, мәгез, алыгыз, зинһар, рәхәтләнегез!— диде Арджеванидзе һәм, баягы сыман сызгыртып, сулышын өреп чыгарды.— Ә гәүдәмне мин үзем белән алып китәм!.. Хуш! Арриведерчи!..

Дьяк, изге атага кулын болгап, үбү ишарәсе ясады һәм аракы белән кызыл борычтан шешенеп беткән телен стенадагы иконаларның һәммәсенә чиратлашып күрсәтеп чыкты да, куларын кесәсенә тыгып, күңелле бер җыр көйли-көйли, Иорам-атаның хөҗрәсеннән чыгып китте.

Иорам-атаны үзенең хөҗрәсендә аңсыз яткан җиреннән килеп табалар. Ләкин әле монысы инфаркт булмый: изге атаның таза йөрәге бу тетрәнүгә биреши.

Инфаркт аны нәкъ бер елдан соң, изге Мәрьям ана бәйрәме алдыннан сейфны ачып, атлас мендәр өстендә әлеге мәшһүр тәре урынына зур бер редис күргәч, аектан екты. Рухани «изге ана чын күңелдән инанганны һәм дә үзенә карата булган хөрмәтне белә торып, бу ка-

дәр үк усал итеп шаяртмаса да ярар иде» дип уйлап бетерүгә, Иорам-ата чабылган үлән сабагыдай авып төште. Моныбы инде чын инфаркт иде.

Иорам-атаны аяктан еккан әлеге инфарктан соң, табигый ки, Арджеванидзе кулга алына. Ләкин эш судка барып җитми. Шик астындагы кеше белән зыян күрүчене, кара-каршы китереп, беренче мәртәбә сорау ала башлауга, әлеге эшкә нокта да куела.

Иорам-ата больницадан чыгып, бер атна үткәч, суд тикшерүчесе Арджеванидзены аның өенә алып килде. Озата килүче милиционерны бүлмәдән чыгарып җибәргәч, суд тикшерүчесе элеккеге дьякны изге атаның караваты янына китереп утрытты, үзе исә, өстәл артына урнашып, беркетмә төзергә тотынды...

— Гражданин Канделаки, шик астындагы Арджеванидзега сорауларыгыз бармы?— дип беренче соравын бирде ул.

Иорам-атаның күзләренә яшь бәреп чыкты, ияге калтырана башлады.

— Җавап бир, хәсис, иблис токымы, кемгә саттың син изге тәрене?— дип Арджеванидзега мөрәҗәгать итте ул.

— Хөрмәтле следователь, безнең чиркәү телендә әйтелгән бу сүзләр сезнең телгә күчергәндә иң әшәке сүгенү сүзләреннән дә яманрак яңгырый! Шул сәбәпле мин менә бу... коммунистик идеологияне какшатучының кыланышын вак хулиганлык дип бәяләвегезне сорыйм!— диде Арджеванидзе, горурлыгы рәнҗегән бер кыяфәт белән.

Арджеванидзеның үтенечен суд тикшерүчесе игътибарга алмады һәм, үз чиратында, аңа сорау бирде:

— Әйтегез әле, Арджеванидзе, тәрене алмавыгызга шаһит булырдай кеше бармы?

— Аллаһе тәгалә — үзе шаһит!— дип кычкырды Арджеванидзе, куларын гарешкә таба сузып.

— Андый изге сүзне теленә аласы булма!— дип, бичара рухани яткан җирендә хәтта сикереп куйды.

— Арджеванидзе, юк сүз сөйләп утырмагыз!— дип кычкырды суз тикшерүчесе элеккеге дьякка.— Алланы без шаһит итеп чакырта алмыйбыз, икенче бер тере кешене күрсәтегез!

— Рәхим итегез: рухани Иорам Канделаки шаһит.

— Ми-и-ин!— дип, Иорам-ата гаҗәпләнүдән караватыннан егылып төшә язды.

— Нәкъ үзе!— дип, аның сүзен җөпләде Арджеванидзе.

Элек дьяк булган бу адәмнең оятсызлыгыннан Иорам-ата телдән язды. Ә тегесе исә сөйли бирде:

— Хөрмәтле следователь, сез ул яла ягучыдан сорагыз әле, мин чиркәүдән китеп, күпме вакыт үткәннән соң югалган ул тәреләре?

Тикшерүче изге атага мөрәҗәгать итте:

— Тәренең югалуы сезгә кайчан мәгълүм булды?

— Арджеванидзе киткәннән соң бер ел чамасы үткәч... Мин бит сейфны елга бер генә тапкыр, изге ана бәйрәме көнендә генә ачам... Эш анда түгел! Ул бит тәрене аңарчы урларга мөмкин иде!

— Хәзер инде сез аннан: «Сейфның ачкычын кайда саклыйсыз?»— дип сорагыз.

Тикшерүче сорауны кабатлады.

— Менә монда!— диде Иорам-ата, муенындагы чылбырны капшап.

Тикшерүче протоколга: «Зыян күрүче сейф ачкычын гел муенында йөрткән»,— дип язып куйды да яңа соравын бирде:

— Сез караганда сейф нинди хәлдә иде? Ягъни, бикле идеме, әллә ватып ачылган идеме?

— Бикле иде...

— Сез аны үз кулыгыз белән ачтыгызмы?

— Әйе, үз кулым белән...

— Сез кайчан да булса Арджеванидзега ачкычны биреп тормадыгызмы?

— Юк!— дип җавап бирде Иорам-ата һәм шушының белән бу эшнең тәмамланачагын аңлап алды.

— Атакай, зиһенегезне җыеп, сөйләгән сүзләрегезне әйбәтләбрәк уйлагыз әле. Бәлки, сезнең кәефегез начардыр? Ул чагында әңгәмәне кичектереп торырбыз.— Тикшерүче Иорам-атаны кызганып куйды.

— Юк-юк, кичектермибез!— дип чәчрәп торды Арджеванидзе.

— Әйтегезче, атакай,— дип дәвам итте тикшерүче,— сез ачкычны һаман шулай үзегез белән йөртәсезме?

Иорам-ата җавап итеп башын гына чайкады: чөнки ул тәре асылган чылбырны мунча кергәндә дә салмый иде.

— Кемнең дә булса, ачкычның күчермәсен ясатыр өчен, аны сездән урлавы ихтимал идеме?

Иорам-ата андый ихтимал булуын инкяр итми иде итүен, ләкин аның моңа ышанасы килмәде, шуңа күрә ул әлеге сорауны җавапсыз калдырды. Ул тагын бер,

соңгы тапкыр Арджеванидзены намус хөкеменә тарттырып карамакчы булды:

— Әгәр җанында аз гына вөҗдан әсәре калган булса, әйт, хыянәтче: кемгә, күпмегә саттың тәрене?!

— Хыянәтчедән ишетәм!— дип чәпчеде элекке дьяк.

— Алайса, ул Глданидагы йортны син нинди акчага салдың? Мин чиркәү түбәсен ябарга ике кисәк чирәпне алыштыра алмый интегәм, ә син...

— Ул йорт минем кайнатайныкы. Ә инде чиркәүгә килгәндә, синең ише кеше талаучы кулында әле ул, гомумән, ничек исән калгандыр?!

Бичара Иорам күгәренеп китте. Тикшерүче исә Арджеванидзега:

— Әгәр тагын бер каршы сүз әйтсәгез, мин сезне...—дип җикерә башлаган иде дә, караклыкта гаепләнеп, болай да инде кулга алынган кешене тагын нинди җәза биреп өркетергә мөмкин икәнлеген уйлап таба алмагач, бармак янау белән генә чикләнде.

— Әлеге өйгә кагылышлы документларны сез үзегез тикшердегез бит,— диде Арджеванидзе. Суд тикшерүчесе «әйе» дигәнне аңлатып башын какты.— Алайса, ни өчен миңа яныйсыз? Намуслы кешене нахак яладан аралыйсы урында, сез ниндидер чиркәү әһелләрен яклап маташасыз.

Тикшерүче югалып калды.

— Ә машина?— дип сүзгә катышты Иорам-ата.

— Гражданин Канделаки!— дип мөрәҗәгать итте аңа суд тикшерүчесе.— Тикшерү органнары әлеге эшкә кагылышлы булган барлык мәсьәләне җентекләп өйрәнде... Шулай булгач, мәсьәләдән читкә тайпылмый гына сөйләгез!

— Машина мәсьәләсенең бу эшкә кагылышы юкмыни?— диде рухани бердән сүрелеп.

— Тикшерү эшләре тәре югалу уңае белән алып барыла, шулай булгач, машинаның монда бернинди катнашы юк, өстәвенә әле ул машина гражданин Арджеванидзеның каенэнесенеке...

— Бүтән сорауларым юк!— дип көрсенеп куйды Иорам-ата һәм валидол шешәсен ача башлады.

— Ә сезнең сорауларыгыз бармы?— диде Арджеванидзега тикшерүче.

— Сорауларммы?— Арджеванидзе аягүрә торып басты.— Мин, үзем теләп дин белән араны өзгән, рәсемем атеистлар җәмгыяте бинасындагы Кызыл тактага эленгән кеше һәм әлеге җәмгыятьнең президиумы члены бу-

ларак, рәсми һәм катгый рәвештә түбәндәгеләрне таләп итәм: беренчедән, явыз ният белән яла ягучы менә бу карагруһчыны кичекмәстән җавапка тартырга һәм башкаларга да сабак булырлык итеп җәза бирергә. Икенчедән, мине, башбаштаклык һәм яла корбаны буларак, тиз арада азат итәргә. Өченчедән, мәҗбүри рәвештә эшсез торудан күргән зыянны җинаятьче Канделакидан түләтергә! Минем сүзем бетте!— дип Арджеванидзе, авыз читенә җыелган күбеген сөртеп, урынына утырды.

— Кемгә нәрсә йөкләүне суд хәл итәр, сездән аны сын сораган кеше юк! Гражданин Канделакига сорауларыгыз булса — әйтегез!

— Рәхим итегез!— дип, Арджеванидзе кабат торып басты.— Грузин халкының милли байлыгы һәм кабатланмас изге ядкаре булган патша кызы Гурандухт тәресен менә бу дәҗҗал кая куйган?

Тикшерүче, руханиның җавабын көтеп, аңа текәлде. Шулчакны Иорам-ата хәтеренә ерак яшьлек елларында булып узган бер вакыйга килде...

...Көннәрдән бер көнне, унынчы номерлы трамвайга утырып, ул стадионга бара иде. Дезертирлар базарына җитәрәк кемдер аның кесәсенә керде. Иорам каракның кулыннан эләктереп алды, ләкин ул авыз ачып сүз әйтергә өлгергәнче, теге кеше селтәнеп торып аның яңагына чалтыратып җибәрде дә бөтен трамвайны яңгыратып кычкырырга тотынды:

— Оят түгелме сиңа, егет?! Карап торуга культуралы, тәрбияле генә кеше кебек, яхшы гаиләдәндер, күрәсең! Ә үзең минем кесәгә керәсең! Хурлык бит!..

Вагондагы бар халык, дәррәү кубып, Иорамны әрләргә, оялтырга тотынды. Аңа, трамвайның туктаганын да көтмичә, барган шәпкә сикереп төшүдән башка чара калмады.

Шул күңелсез хәл исенә төшкәч, Иорам-атаның үзеннән-үзе яңаклары кызышып, күзләренә яшь килде.

— Йә, ни диярсез, атакай?— дип сорады тикшерүче.

Иорам-ата урын өстеннән шуып төште дә, яланаяк килеш алпан-тилпән атлап, эчке киемнән генә күрше бүлмәгә кереп китте һәм, стенадан бабасының искиткеч зур хәнҗәрен алып, төртенеп куйды, аннары аны кынысыннан тартып чыгарды да, ике куллап югары күтәргән килеш, акылдан шашкан кеше кебек, тикшерүче белән Арджеванидзе утырган бүлмәгә атылып керде.

— Дөмек, иблис!— дип кычкырып җибәрде рухани һәм кулындагы хәнҗәрен бар көченә селтәнеп Арджe-

ванидзеның башына төшерде. Әмма тегесе шул вакыт читкә тайпылып өлгерде, хәнҗәр исә һаваны ярып, урындык аркасына килеп төште дә аны икегә аерып ташлады.

Иорам-ата хәнҗәрне идәнгә томырды.

— Күземнән югалыгыз!— диде әллә нинди карлыккан чит тавыш белән һәм гөрселдәп идәнгә ауды да үкереп еларга керешге.

...Мондый хәлдә инде сорау алу һәм беркетмә язу мөмкин түгел иде. Тикшерүче биредән кичекмичә китәргә тиеш иде, югыйсә изгеләр сурәте белән бизәлгән бу бүлмәдә кан коелуы ихтимал иде. Әйе, тикшерүче моны аңлады, шуңа күрә ул, Арджеванидзены ияртеп, таланган Ортачала чиркәве башлыгының фатирыннан тизрәк чыгып китү ягын карады...

Иорам-атаны Бачана белән янәшә ятарга мәҗбүр иткән икенче инфаркт әле күптән түгел — моннан ике ай элек, күпләргә мәгълүм, дәрәҗәле бер кешенең өендә булды. Ул төнне Иорам-атаны, — әлбәттә, яшертен рәвештә,— әлеге иптәшнең каенатасына җеназа укытырга дип чакырганнар иде.

Иорам-ата хәтта табут янына да барып җитә алмады: бусагадан атлап кереп, хуҗа ханымның чамасыз зур итеп уелган изүендә... патша Вахтанг Горгасал сеңлесе Гурандухтның тәресен күрүгә, каһәр төшкән инфаркт аны икенче тапкыр аяктан екты.

...«Ашыгыч ярдәм» машинасында аңына килгәч, Иорам-ата, зарыгып көтелгән тәре урынына, медицина тартмасына төшерелгән зур кызыл хач сурәтен генә күрде. Аннары, больницага барып җиткәнче, күнегелгән, җанга якын ладан исе урынына, күңелне болгата торган нашатыр, камфара иснәргә мәҗбүр булды.

Иорам-ата, беренче инфаркттан соң алган ачы сабакны истә тоткан хәлдә, авыруының сәбәбе турында бу юлы авыз ачып бер сүз дә әйтмәде. Ул, гадел хөкемнән тәмам өметен өзеп, язмышын аллаһе тәгаләиркенә тапшырырга карар кылды. Кайчан да булса гаеплегә ходаның каргышы төшәсенә ихлас күңеленнән ышана иде ул.

Иорам-атанын күңеле бары бер генә нәрсәгә рәнҗи иде: ни өчен соң ходай тәгалә шундый авыр сынаулар өчен башка берәүне түгел, нәкъ менә аны сайлады икән? Ни өчен бу газап-михнәтләр икенче берәүгә түгел, бәлки, аның башына төште икән?

Иорам-ата җанын борчыган шул сорауларга җавап таба алмый интегә иде...

Соңгы көннәрдә Бачана Иорам-атаны гаҗәпсенеп күзәтә башлады. Теге сәер кеше килеп киткәннән соң, рухани танымаслык булып үзгәрде: хәзер ул бөтенләй диярлек сөйләшми иде. Күңел төшенкелеге идеме бу, эч пошумы, әллә куркумы — анысын Бачана түгел, Иорам-ата хәтта үзе дә тәгаен генә әйтеп бирә алмас иде. Тик шулай да үзенә күрә бер могҗизаи хәл булды: рухани теге йортның адресын да, хуҗаларының фамилияләрен дә бөтенләй онытты. Әйтерсең Иорам-атаның әлеге хәвефле төнгә кагылышлы хәтер почмагын теге адәми зат пычак белән кыеп төшергән иде.

Үзен авыруга сабыштырган вакыйга турындагы чын дөреслекне Иорам-ата больницадан чыгарына бер атна калгач Бачанага сөйләп бирде. Ләкин Бачана тәре хуҗасының фамилиясен әйттерергә күпме тырышса да, күпме үтенсә дә, руханины ризалата алмады: Иорам-ата җавап бирүдән катгый рәвештә баш тартты.

Тбилиси шәһәрендә грипп эпидемиясе котырынган көннәр иде. Больницада егерме көнгә карантин игълан ителде. Профессорның боерыгы буенча, авырулар янына хәл белергә килүчеләрне түгел, хәтта якын туганнарын да кертми башладылар. Авыз-борыннарын томалап бәйләгән больница хезмәткәрләре коридор буйлап өрәк сыман йөриләр иде. Профессор палаталарны көненә өчәр тапкыр үзе әйләнеп чыга иде. Больница, хәтта кош та очып керә алмастай итеп, дошман явы белән чолгап алынган таш пулатны хәтерләтә иде. Шуңа күрә көннәрдән бер көнне иртән иртүк палата ишеге ачылып китеп, бусагада авызы колагына хәтле ерылган яшьлек дусты Вахтанг Амбокадзе күренгәч, Бачананың гаҗәпләнүенә чик-чама булмады.

— Вахо!— диде ул караватыннан күтәрелә төшеп.

— Беркатлылар президенты, кадерле Бачога сәлам! Амбокадзе кулындагы зур гына төргәкне уртак өстәлгә куйды да, Бачананың караваты янына килеп, көрәк чаклы дәү куллары белән аны кочаклап алды, аннары әкрен генә урынына яткырды һәм каршы килмәслек катгый тавыш белән:

— Кыймылдыйсы булма, тик кенә ят!— диде.— Профессор сиңа селкенергә ярамый дип әйтте! Исәнмесез!— диде ул аннары Иорамга таба борылып.

— Сәламәт кенәме сез!— дип җавап бирде рухани.

— Ничек керә алдың син монда?— дип сорады Бачана үз күзенә үзе ышанмыйча.

— Исең киткән икән! Кешеләр әле банк бинасына кереп акча да урлап чыгалар! Синең янга палатага керү дә булдымы эш?— дип көлемсерәде Амбокадзе.

— Кайдан килеп чыктың син?— дип һаман сорашуында булды Бачана.

Амбокадзе Иорам-атага күз салып алды.

— Әйе-әйе, таныш булыгыз,— дип кинәт исенә килде Бачана, — бу минем яшьлек дустым Вахтанг Амбокадзе, ә менә монысы минем палатадаш дустым, Ортачала изге троица чиркәвенең башлыгы Иорам Канделаки.

— Оһо, алайса инфаркт попларда да була икән. Аллаһе тәгаләнең канаты астындагы кешеләр түгелме соң сез?— диде Амбокадзе кинь елмаеп һәм каты гына итеп Иорам-атаның кулын кысты.

— Йә, утыр, сөйлә инде! Нинди җилләр ташлады монда сине? Каян килеп мине исеңә төшердең?

— Димәк, менә болай... Кайтып төштем. Малайларны күреп сөйләштем. Алар: «Бачо гарешләргә ашарта җыена»,— диләр.

— Нәрсә?— дип сорады Бачана аңламыйча.

— Үләргә җыена, диләр. «Ничек инде ул алай?»— мин әйтәм.— «Менә шулай инде,— диләр миңа,— инфарктның хәтәрен эләктергән дә, кулларын күкрәгендә кушырып, үләргә ята хәзер!»— диләр.— «Юкны сөйләмәгез!»— димен тегеләргә.— Ялганчы бит ул, хәйләләп ятадыр! Минем белән хушлашмыйча нишләп үлсен ди ул!» Шуннан, тоттым да синең яныңа килдем менә. Малхаз озата килде, тик аны кертмәделәр, урамда көтеп калды.

— Син ничек керә алдың соң?

— Ә мин туп-туры профессорның үзенә киттем. «Хөрмәтле профессор, Рамишвили янына кертегез әле мине, унбиш елдан бирле күрешкәнебез юк!»— дидем.— «Ә сез кем соң?»— дип сорый профессор. «Беркем дә түгел, гади бер кеше!»— димен.— «Ярый, алай гади кеше булгач, керегез, миннән рөхсәт!»— ди. Егет икән үзе! Гомеремдә дә андый кешелекле профессорны күргәнем юк иде!

— Хәйләләмә! Тагын нәрсәләр дип сайрадың син аңа?

— Нәрсә дип сайрыйм, бичара бер ятим мин...— дидем.

— Хәйләкәр дә соң үзең!— дип көлеп җибәрде Бачана.

Анысы шулай, бераз бер... Йә, сөйлә әйдә, ни хәлләрең бар? Йөрәк ничек?

— Миңа калса, котылдым кебек...

— Димәк, икебез дә котылганбыз... Кара әле, профессор миңа өч кенә минутка рөхсәт бирде... Менә монда дарулар...— дип Амбокадзе өстәлдәге төргәкне урелеп алды.

— Тукта әле, дарулар качмас!..— дип бүлдерде аны Бачана.— Мин сиңа үз фондымнан тагын өч минут бирәм. Йә, сөйлә әйдә тизрәк, кайларда йөрдең, ниләр эшләдең, озакка кайттыңмы, планнарың нинди? Минем ярдәм кирәкмиме?

— Син сәламәт булып, исән-имин яшәсәң, миңа башка берни дә кирәкми! Вахтанг Амбокадзега ярдәм итәрдәй кеше әле дөньяга килмәгән...

— Йә, ярар, бераз утыр инде, туйганчы карыйм әле үзеңә!..

— Кара, кара, кадерлем, ләкин профессор керсә, җавабын син бирерсең!..— дип, Бачананы кисәтте Амбокадзе.

— Ярар!— рип ризалашты тегесе.

— Кыскасы, менә шулай... Теге эшне хәтерлисеңдер бит...— Амбокадзе тагын Иорам-атага карап алды.

— Сөйлә әйдә, сөйлә, үз кеше ул!— дип елмайды Бачана.

— Димәк... хәтерендәдер, Лоткин тавында тоннель казыганнан соң...

Бачана башын кагып куйды.

— Кайда, нинди тоннель ул?— дип гаҗәпләнеп сорады шулчак Иорам-ата. Тбилисидә туып-үссә дә, андый тоннель турында ишеткәне юк иде аның.

— Сезнең чиркәүдән күренми ул, атакай!— дип җавап бирде Амбокадзе һәм сүзен дәвам итте:— Шул эш өчен безгә алты меңнән алып унике меңгә кадәр премия тиеш иде. Баджаджгана белән икәү булганлыктан, икебезгә дә алтышар меңне биреп, өстәвенә Архангельскига путевка тотырдылар... Анда мин дүрт ел булдым. Үзең беләсең, мин эшсез яши алмыйм. Ярты тайганы кисеп бетердем, агач эшкәртү промышленностена зур файда күрсәттем! Аннары марафон йөгерешендә кат-

---

[1] *Лоткин тавы* — Тбилисидәге бер төбәк.

наштым... Унау идек без. Архангельскидан Карагандага кадәр чаптык...

— Җәяүләпме?— дип исе китте Иорам-ата.

— Кайда җәяүләп, кайда поезд белән...

— Шулай да асыл егетләр икәнсез!— дип мактап куйды рухани.

— Кире кайтканда Столыпин вагоннарында кайттык. Финишка өчебез генә килеп җитә алды. Шушы эшебез өчен тагын икешәр мең премия бирделәр. Алты да ике — сигез булдымы... Аннары Мәскәүгә юл алдым. Тоннельләр буенча атаклы белгеч буларак, дуслар мине зур бер эшкә алынырга чакырдылар. Менә дигән тоннель казып бирдем, тик, «булды» дигәч кенә, җимерелеп төште... Егетләрнең өчесе һәлак булды. Берүзем исән калдым, шуңа күрә премиянең бөтенесе дә — җиде мең — миңа чыкты. Шуңа өстәп — Свердловскига путевка... Җиде дә элекке сигез — унбиш булдымы?

— Шулай!— дип җөпләде Бачана.

— Хәзер инде менә Тбилисидә. Кайтканыма өч көн. Әлегә эшсез йөрим, ләкин монда минем өчен эштән дә күп нәрсә юк диләр... Әмин менә... Әллә пенсиягә чыгыйм микән дип тә уйлыйм. Бөтенесенә төкерәсе дә ял итәсеме әллә, ә? Арыдым мин, малай, бик арыдым...— дип, Амбокадзе авыр сулап куйды.

— Ничек башыңа килде мондый шәп фикер?!— диде Бачана куанып.— Чыннан да, чык пенсиягә! Хәл ит әйдә! Әмин синең өчен кулымнан килгәннең барын да эшләрмен! Кабергә кереп ятарга да әзер, тик син бер ныклы карарга гына кил! Зинһарлап сорыйм! Яшәр җирем юк дисең икән, рәхим итеп минем өйдә тор! Вахо, кадерлем, пенсиягә китәргә сүз бир миңа!— Бачананың тавышы калтыранып китте.

— Нәрсә сөйлисез сез, Бачана Акакиевич, нинди пенсия ди әле аңа? Нәсел үгезеннән дә тазарак ич!— дип куйды Иорам-ата түземичә.

— Эшем яман да авыр шул минем, атакай!— диде Амбокадзе күңелсез елмаеп.— Кырык биш яшемнең утызын йә ябык бина эчендә, яки җир астында уздырдым...

— Шулай, тоннель төзү — җиңел эш түгел, дип ризалашты рухани,— әмма искиткеч күркәм, мактаулы эш!

— Риза булмассыз шул, югыйсә, мин сезнең белән бик рәхәтләнеп эшемне алышыр идем!— дип көлемсерәп куйды Амбокадзе.

— Вахо, моны син икенче тапкыр әйтәсең инде!— диде Бачана.

— Ә хәзер — булды, житте! Ардырды инде! Ятим-Гурҗи әйтмешли, җанга якын Тбилисиемдә үләсем килеп китте. Хәтерлисеңме?

Исәнме, минем Тифлисем, туган шәһәрем минем!
Кайтты тагын, юллар урап, синең каһәрле улың...

— Кара аны, Вахтанг, син сүз бирдең!

— Әйе, Бачо, вәгъдә—иман!— дип, Амбокадзе урыныннан кузгалды.— Ә-ә, дарулар бар бит әле монда!— Ул, төргәкне сүтеп, Бачананың караватына бер олау ампулалар, таблеткалар, порошоклар сибеп ташлады. — Менә монысы атероид, монысы интенсаин, монысы панангин, менә бусы кордарон, перитрат, персантин, монысы менә эральдин, пульснюрма, сустак, ә менә бу дару тиләләр өчен — валиум!

— Вахо, син үзең акылдан язгансың, ахры! Кайдан алдың бу даруларны?— Бачана гаҗәпләнүдән ачылган авызын яба алмый торды.

— Ишеттегезме, атакай? Гомер буе әнә шундый булды инде алар. Һәркайсы һаман да шул бер акылсыз сорауны бирә: кайдан алдың да, кайдан алдың, имеш! Кайдан икәнен шайтан белсен! Биргәннең битенә бакма, ал да куй!

— Әйе, бик кыйммәтле дарулар болар...— диде Бачана уйчанланып һәм бихисап зур байлыкка тап булган кеше сыман, алдындагы порошок, амплулаларны саклык белән генә берәмтекләп караштырырга кереште.

— Бәясе турында инде аның даруларны тапкан кеше уйласын, анысында синең эшең юк!— дип шаяртып котылмакчы булды Амбокадзе.— Сездә дә инфарктмы?— диде ул аннары руханига борылып.

— Әйе, инфаркт һәм дөньяда булган башка бөтен авырулар! — дип көрсенеп куйды Иорам-ата.

— Алайса, бер бүлмәдә яшәп, бергә көн күргәч, бу мөлкәтнең яртысы хөрмәтле атакайга тиешле. Закон—закон инде ул!.. Йә, ярый, киттем мин, вакытым беткәндер! Ә синең ул грипп дигәнеңә төкерәм мин!— дип Амбокадзе, Бачананы кочагына алып, каты итеп күкрәгенә кысты.— Хушыгыз, атакай!— диде ул Иорам-атага таба борылып һәм кызу-кызу атлап ишеккә юнәлде. Бусагада ул артына әйләнде, үзенең гаҗәп матур, моңсу күзләре белән Бачанага текәлеп карады:

— Кара аны, Бачо, үләсе түгел!— дип кычкырып көлде дә ишекне япты.

— Хөрмәтле Бачана, бу мөхтәрәм христиан кем булды? Мин аңа хәтта рәхмәт әйтергә дә өлгерми калдым!— диде Иорам-ата.

— Карак ул, атакай! Бөтен гомере угрылыкта үткән кеше!— дип җавап бирде Бачана, тамагына килеп тыгылган яшьләрен йотып.

19

Бачана машинаны юл читенә китереп туктатты.

Самадло[1] ягындагы басу-кырлар, үр-калкулыклар барысы да тирән кар юрганы астында ята иде. Әйләнә-тирәдә бер генә җан әсәре дә күренми. Ерактагы авыл өстендә җиңел ак төтен каурыйлары күтәрелә. Алар әллә нинди әкәмәт-сәер рәвешләргә керә-керә, аяз зәңгәр күккә сузылалар. Басу өстендә үсеп утырган берән-сәрән ялгыз агачлар, көтеп-көтеп тә кавыша алмагач, бер-берсенә кулларын сузган килеш, кайгыдан корып калган гашыйкларны хәтерләтә иде.

Бачана, машинадан чыгып, тәгәрмәчләрне караштырырга тотынды. Мария дә, тунын салып ташлап, анын артыннан чыкты һәм, бер сүз дәшмичә, карлы басу буйлап йөгереп китте.

— Кая чабасың?— дип кычкырды Бачана аның артыннан.

Мария дәшмәде. Ул, тезеннән карга бата-бата, һаман йөгерә бирде. Аягына озын куныччлы кызыл итек кигән, җилкәсенә аллы-гөлле бизәкләр төшкән шәлъяулык салган Мария үзе дә гаҗәеп зур бер чәчәкне хәтерләтә иде. Бачана кар ерып баручы шул чәчәккә сокланып, горурланып карап торды, чөнки әлеге чәчәкнең ул башка берәүнеке дә булмыйча, бары үзенеке генә икәнен белә иде.

Мария кинәт кенә иелде дә кушучларына кар чумырып алып башына сипте.

— Бачана, кил монда!— дип чакырды ул аны.

Бачана тунын салып машина эченә ташлады да Мария эзе буйлап китте. Кинәт аның басу бетереп йөгереп йөрисе, онытылып-онытылып карда ауныйсы килде. Мария янына җиткәч, ул аны куларына күтәреп алып бөтерелергә керешә. Менә алар икәүләшеп авып китте-

---

[1] *Самадло* — Тбилиси тирәсендәге бер төбәк.

ләр дә ак кар эченә чумдылар, зык кубарып бер-берсе белән шаярырга керештеләр. Аларның колакларына, күзләренә кар тулды, йөзләре эсселәп кызарып чыкты. Ниһаять, тәмам хәлдән тайгач, алар, кар өстенә чалкан ятып, тынып калдылар. Мария кулларын як-якка җәеп ташлаган, аның чем-кара чәчләре кар өстенә сибелеп төшкән, изүләре ачылып киткән, калку күкрәге бер күтәрелә, бер төшә. Хәзер ул, аучылар эзәрлекләвеннән качып, кар өстенә хәлдән таеп ауган боланны хәтерләтә иде.

Бачана Мариянең чибәр-сылу йөзенә сокланып байтак кына карап торды да, түзә алмыйча, аның диңгез кабырчыгына охшаган кечкенә, салкын колакларын учына кысты һәм кайнар иреннәренә урелде. Хәзер алар икесе бер сулыш белән сулый, бер җан белән яшиләр иде. Алар, ярсып типкән йөрәкләренә колак салып, байтак шулай кымшанмыйча ята бирделәр.

— Тор!— диде кинәт Мария, Бачананы читкә этеп.

Бачана аягына басты.

— Читкә борыл!— диде Мария.

Бачана күндәм генә читкә борылды һәм кабат Мариягә таба әйләнгән иде, үз күзенә үзе ышанмады: Мария, илаһи матурлыкның гөнаһсыз бер фәрештәсе сыман, анадан тума шәрә калып аның каршында басып тора иде.

Бачана чытырдатып күзләрен йомды, кабат күзен ачканда, Мария, йокыга талган сыман, кар өстендә ята иде. Бачана тиз генә аның янына килеп тезләнде, куллары белән Мариянең калак сөякләре турысыннан кочаклады да күкрәгеннән үбеп:

— Нишләвең бу, җүләркәй, салкын тидерәсең ич!— дип пышылдады.

— Бу көнне мин ике ел көттем, җаным... Менә инде, ниһаять, көтеп алдым... Хәзер минем үз кояшым бар... Нинди салкын тидерү турында сөйлисең син?..— диде Мария һәм Бачананы кочаклап алды...

...Аннары кояш, җиргә төшеп, Самадло басуларын әйләнеп узды, бу ике Адәм баласын ап-ак, җылы җәймәсенә төрде, бермәлгә аларның баш очына туктап, тирбәтеп йоклатты да кабат үзенең үтә күренмәле, көзгедәй ялтырап торган гөмбәзенә әйләнеп кайтты...

...Бачана кинәт чәчрәп сикереп торды һәм, коты алынып, кояш нурларыннан җемелдәп-янып яткан карлы басу өстенә күз ташлады: бөтен җиһанда Мария, Бачана һәм кояш — өчәү генә калган иде.

Бачана тизрәк машина янына йөгерде, ялт кына тунны эләктереп, кабат Мария янына чабып килде дә, аны тунга төреп, машинага таба алып китте.

Берәр минуттан инде алар аулак тау юллары буйлап, түбәнгә, Тбилисигә юл алдылар. Шулчак Бачана Шавнабада чиркәве ишегалдында Мария укыган шигырь юлларын исенә төшерде:

Кояш, кояш, нурлы кояш,
Китмә таулар артына!
Күрмисеңме, бер кыз бала
Туңып тора салкында!

Җылыт аны, куйныңа ал,
Әйт бер сөю сүзеңне.
Юкса башканы табар ул,
Көтеп ятмас үзеңне.

Мария машинаның арткы утыргычында акрын гына елап утыра иде. Әмма бу — рәнҗетелгән, кимсетелгән хатын-кыз елавы түгел, бу — ниндидер башка, Бачана өчен бөтенләй таныш булмаган, аңлаешсыз, акыл ирешмәслек бер нәрсә белән мәңгегә хушлашу иде. Бачана күңеле белән моны сизенә иде, шуңа күрә ул Марияне юатмады.

Аркаларына букчаларын асып, Коджори интернатыннан өйләренә кайтып килүче малай белән кыз, гаҗәеп тамашаны күреп, баскан җирләрендә катып калдылар.

— Кара әле, Натия!— дип кычкырып җибәрде малай, кулы белән басуга күрсәтеп. Самадло басуы өстендә, утә күренмәле зәңгәр ялкын булып кар яна иде.

Бачананың ишек тоткасына хат кыстырып калдырганнар иде. Редакторлык сиземе белән ул аның аноним хат булуын төшенеп алды. Бачана, хатны кесәсенә салып, ишекне ачты, бүлмәсенә кереп, эш өстәле янына барып утырды, шуннан соң гына конвертны ачты.

Хат, дөрестән дә, билгесез бер авторныкы булып, өстәвенә порнографик фоторәсемнәр белән бизәлгән иде.

Редактор булып эшләү дәверендә Бачанага йөзләгән аноним хат белән танышырга туры килгәне бар, ләкин монысы үзенең шакшылыгы, оятсызлыгы белән аларның барысыннан да яманрак иде.

«Хөрмәтле Бачана Акакиевич!

Ишегегез өстендә кызыл фонарь кабынуы белән котлыйм сезне. Даны таралган азгын хатын, Тбилиси фахишәләренең остазы бу юлы инде сезгә, үзенең чираттагы мөгезле савым сыерына (кызганыч, ләкин сезне үгез дип әйтерлек түгел!) тап булган икән. Венерик авырулардан башы чыкмаган әлеге хатынның сезгә шундый юмарт итеп үзенең мәхәббәтен бүләк итүенә һич гаҗәпләнерлек түгел. Чөнки аның өчен мәхәббәт,— фермадагы сыерлардан сөтне күбрәк алыр өчен төрле комбиазык ашаткан кебек, сезне имәр өчен бер ысул гына. Әлегә сез, Бачана Акакиевич, бу аноним хатны — сезне ихлас күңелдән кызганып язган хатны — шул фонарь яктысында укыйсыз. Әмма ләкин, «сөт» кими башлагач, ишегегез өстенә эленгән кызыл фонарьны алып ташларга соң булмагае. Абруегызны саклагыз!».

Бачана хатны бер читкә куйды, маңгаена тибеп чыккан салкын тирне сөртеп алды. Хатны укыган чакта ул кемнеңдер бик таныш тавышын ишетә кебек тоелды. Югыйсә, хат хатын-кыз кулы белән язылган кебек тоелса да, әйтерсең көчле ирләр кулы әлеге акылга сыймаслык кыргый хатның һәр сүзен, кадак каккандай, Бачананың аңына сугып кертә кебек иде. Һәм ул аны инде беркайчан да котыла алмаслык, шундый тирән, шундый нык итеп кадаклый сыман иде. Ләкин кайда, кайчан ишеткәне бар иде соң Бачананың бу тавышны? И аллам, исемә төшерче!.. Бачана, тәки берни дә исенә төшерә алмыйча, фоторәсемнәрне карарга кереште. Моннан да әдәпсезрәк, моннан да әшәкерәк рәсемнәрне күз алдына китерүе дә кыен иде! Ләкин, шуның белән бергә, боларны күчереп ясалган, ялган рәсемнәр дияр идең, шулкадәр оста итеп алдаша алулары шикле... Бачананың күз аллары караңгыланып китте, чигәләре кыса башлады. Һәм нәкъ әнә шул, дөньяның яктысы сүнгәндәй бер халәт кичергәндә, кинәт караңгылык эчендә өмет чаткысы җемелдәп киткәндәй булды: рәсемнәрнең берсендә ул Марияне... анадан туума шәрә килеш күрде. Һәм нәкъ әнә шул рәсем Бачананы билгесезлек дөньясыннан аралап алып, рәсемнәрнең ялган булуын фаш итте дә: чөнки әлеге буй-сын Мариянеке түгел иде. Рәсемдә йөзе Мариягә охшаган хатын-кыз сурәте — Мария түгел иде!

Бачана рәсемнәрне өстәл өстенә ыргытты... Менә ул Марияне Мәрьям ана сурәте каршында тезләнгән килеш күз алдына китерде, аннары аның хәтереннән ап-

ак кар белән капланган Самадло басуы чагылып үтте, һәм кинәт Бачана бөтен дөньясын күрәлмәс булды... Бөтен өметләре киселгән, рухы сүнгән Бачана, берәр дустына шылтыратып, күңелен бушатырга уйлап, телефонга үрелде, ләкин бер генә номерны да исенә төшерә алмады, һәм, гомумән, үзенең берәр дусты булу-булмавын да зиһененә китерә алмыйча, трубканы кире урынына куйды.

Әлеге исемсез хат килеп, берәр атна вакыт үткәннән соң, Бачана белән Мария Соганлуг ресторанының кечерәк бер бүлмәсендә утыралар иде. Өстәлдә ике шешә шәраб һәм Мариянең яраткан ризыклары — бер таба кыздырылган бәрәңге белән кабыгы әрчелгән чикләвек тора иде.

Бачана сөйләшмәде. Табынның тамадасына әверелгән Мария исә бертуктаусыз сөйләнде дә сөйләнде: шигърият, тарих, сәнгать мәсьәләләренә кагылып үтте, аннары хайваннар дөньясына, дельфиннарга, йолдызларга, һавада очып йөри торган тәлинкәләргә күчте, ниһаять, чират мәхәббәткә, мәңге яшәүгә, җаннарның күченүенә житте. Бачана сүзсез генә эчте дә эчте. Мариянең фикере белән ризалашса, баш какты, килешмәсә — бәхәс куертып маташмады. Ул, бер сүз дә дәшмичә, Мариянең зур булып ачылган, мәхәббәт нуры белән тулган күзләренә текәлеп, эчүендә булды. Бачананың уйчанлыгы Мариянең игътибарыннан читтә калмады, әлбәттә, ләкин ул берни төпченмәде, бары тик ара-тирә генә:

— Син мине тыңлыйсыңмы, җаным?— дип сүзен бүлә иде.

Бачана аның соравына җавап итеп баш кагып куюга, Мария кабат сүзен ялгап алып китә иде. Бачананың исә башында һаман бер уй иде — Мариянең үткәне һәм киләчәге, аның ихласлыгы, тугрылыгы, яисә матурлыгы, акылы турында уйламады ул. Аңа хәзер коточыргыч куркыныч бер уй тынгылык бирми иде: пинжәгенең эчке кесәсендә яткан, кызган тимер кебек өтепөтеп алган әлеге исемсез хатны Мариягә күрсәтергәмеюкмы?

Мария стаканнарны тутырып шәраб салды да кинәт кенә:

— Нигә син минем үткән тормышым турында бер дә сорашмыйсың?— дип куйды.

Бачана сискәнеп китте.

— Нәрсә дидең?— дип кайтарып сорады ул, җавап бирер өчен вакыт отмакчы булып.

— Минем үткән тормышым сине бер дә кызыксындырмыймыни, дим. Без синең белән инде өч ел яратышып йөрибез, шул гомер эчендә синңа кадәр ничек яшәвем турында бер генә тапкыр да сораганың юк...

— Әйе, кызыксынмыйм, шуңа күрә сорамыйм да,— дип җавап бирде Бачана, күзен читкә алып.

— Дөрес түгел... Ул нәрсә сине бик, бик кызыксындыра, ләкин син сорамыйсың! Мин үзем сөйләп биргәнне көтәсең. Шулаймы?

Бачана башын түбән иде.

— Чөнки син куркасың, җаным. Һәм син хаклы... Мин үзем дә куркам...— Мария, шәрабын йотып, дулкынланудан кипшенгән иреннәрен чылатты,— синңа карaганда да ныграк куркам... Сине югалтудан түгел, узганнарны искә төшерүдән куркам...

— Мария, шундый матур кичне бозмыйк әле...— дип үтенде Бачана.

— Болай да бозылган инде ул... Иртә таңнан ук... Әйт әле, җаным, ни булды? Мин бит барын да күрепсизеп утырам...

— Берни дә булмады, синең белән ант итәм!

— Бигрәк җиңел ант итәсең!— дип елмайды Мария һәм, кулына стаканын алып, шәраб аша утка карады да әкрен генә:— Кайсыбыз алданрак үлә, шуның өчен эчик!— дип куйды.

— Мария, шундый күңелле кичне, зинһар, җеназага әйләндермә инде... Кәефең шундый әйбәт иде, ни булды соң шулай кинәт кенә?

— Эчеп бетер әле!

Бачана эчеп бетерде. Мария кабат стаканнарны тутырды.

— Инде хәзер мине тыңла... Үз гомеремдә мин биш тапкыр үлеп, биш тапкыр терелдем. Беренчесендә мин котым алынудан үлеп, ялгызлыкта терелдем... Икенчесендә ялгызлыктан үлеп, ясалмалыкта терелдем... Өченче тапкырында мин ясалмалыктан үлеп, ваемсызлыкта терелдем... Дүртенчесендә исә, ваемсызлыктан үлеп, нәфрәттә терелдем... Бишенчесендә инде, нәфрәттән үлеп, мәхәббәттә терелдем... Хәзер мин гаҗәеп зур, олы мәхәббәт дөньясында яшим һәм шул мәхәббәттә үләчәкмен. Бу минем иң соңгы үлемем булачак... Аннан соң инде мин башка беркайчан да кабат терелмәячәкмен, шул мәңгелек мәхәббәттә эреп, юкка чыгачакмын...

Шуңа күрә, хәзер инде кайчан үлсәм дә, миңа барыбер... Үлемнән курыкмыйм мин... Үземнең алтынчы, соңгы үлемем өчен эчәм!

Мария стаканын төбенә кадәр эчеп бетерде дә Бачананың күзләренә текәлде.

Бачана, бу гаҗәеп хатынга төбәлгән килеш, ни дип әйтергә дә белмичә, гаҗиз булып утыра бирде. Ике арада авыр тынлык урнашты. Бачанага шулвакыт, кинәт кенә бүлмә икегә аерылып, Мария шуның бер ягында, ә ул икенче якта калган кебек тоелды. Мария ягында иркен саф һава, җылылык, тормыш, мәхәббәт бөркелеп тора, үзе исә салкынлыгы, шомлылыгы белән котны очыра торган хәвефле бушлык эчендә калган кебек иде. Бачана, тыны кысылып, урыныннан сикереп торды, өстәлне әйләнеп, Мариянең янына килеп утырды һәм, мәңге яшел тереклек агачына сарышкандай, башы белән аның күкрәгенә елышты... Мария Бачананы чәчләреннән үпте дә тыныч кына тавыш белән:

— Әйтче, зинһар, нәрсә газаплый сине?— дип сорады.

Бачана пинжәгенең эчке кесәсеннән аноним хат белән порнографик рәсемнәр салынган конвертны чыгарды һәм калтыранган кулы белән аны Мария алдына китереп салды. Мария озак кына конвертның тышына карап торды, аннары ачып, игътибар белән рәсемнәрне күздән кичерде, шуннан соң хатны укыды.

Мариядән күзләрен алмый карап утырган Бачана аның йөзендә бернинди үзгәреш сизмәде. Ләкин Мария, хатны укып бетереп, күзләрен тутырып аңа күтәрелеп карагач кына, Бачана үзенең төзәтеп булмаслык нинди зур хата ясаганлыгын аңлап алды. Мариянең күзләрендә ул ачу, җирәнү, тирән нәфрәт урынына шушы түбән җанлы ике кешегә — әлеге исемсез хатның авторына һәм Бачананың үзенә карата — чиксез кызгану төсмерегенә күрде.

Мария урыныннан күтәрелде.

— Хатын-кызны ялгызлык юлдан яздыра, кадерлем. Ир-атны да ялгызлык аздыра. Шулай булгач, беркайчан да ялгыз калырга тырышма...

Бачана ресторанда бер сәгать, ике, өч сәгать утырды, ләкин Мария кире әйләнеп килмәде. Әлеге гаҗәеп хатын Бачана уйлаганнан күп тапкыр горуррак булып чыкты.

— Ә сезнең... э-э-э... дустыгыз күптән китте инде...—

дип, ниһаять, батырлыгын җыеп, кыенсынып кына эндәште официант.

— Әйе, әйе, беләм!— диде аптырашта калган Бачана.

— Гафу итегез, ләкин... ресторан ябыла бит инде... Әгәр сез...

— Әлбәттә, әлбәттә, гафу итегез... Күпме тиешле миннән?

Бачана, счетка карап та тормыйча, акча түләде. Официант чыгып китте.

Бачана исә хат белән фоторәсемнәрне вак-вак кисәкләргә ерткалап төпчек савытына ташлады да шырпы сызды. Иң элек ут рәсем кыйпылчыкларын элеп алды. Бачана рәсемдәге кеше сурәтләренең башта кабарып китүләрен, аннары эреп юкка чыгуларын, көлгә әйләнүләрен беравык шулай күзәтеп-карап утырды. Төпчек савыты аңа кечкенә бер тәмугны хәтерләтте. Ялкын телләре аноним хатка үрләгәч, Бачана кабат ниндидер таныш тавыш ишеткән кебек булды, һәм ул тораташтай катып калды: хат Сандро Маглаперидзе тавышы белән сөйли иде.

20

Иорам-атаны больницадан дүшәмбе көн чыгармакчы иделәр, ләкин ул сишәмбе көнгә кадәр моннан китәргә теше-тырнагы белән каршы булды.

Ул төн Бачананың хәтерендә мәңгегә уелып калды.

...Төн уртасы җитәрәк Иорам-ата урыныннан торды һәм, аяк очларына гына басып, Бачананың караваты янына килде. Бачана йоклаганга салышты.

— Бачана Акакиевич!— дип пышылдап кына эндәште рухани.

Бачана кымшанмады. Изге ата, аның йоклаганлыгына тәмам ышангач, идәнгә тезләнде.

— И кодрәтле тәңрем!— дип тәртенеп куйды Иорам-ата.— Коткаручыбыз безнең! Изге Мәрьям ана! Менә сезнең каршыгызда алла колы Бачана Рамишвили ята һәм ул үзе сезнең улыгыз, сезнең җаныгыз, сезнең мәрхәмәтегез булуын башына да китерми... Сез кушкан эшләрне икенче бераүләр исеменнән башкарганы өчен ачу тотмагыз аңа. Ачуланмагыз аңа, чөнки ул үзе инанган алласының сезнең туфракта, сезнең ихтыярыгыз белән яралганын белми... Кодрәтле тәңрем, аның химаячесе һәм сакчысы бул, аңа озын гомер бир, синең

катыңа ул тиз генә килеп басмасын, чөнки җиһанда никаклы озаграк яшәсә, синең тарафтан яратылган бу фани дөньяда ул игелек һәм рәхим-шәфкатьне шуның кадәр күбрәк чәчәчәк. Җир йөзендә тынычлык, гаделлек, намуслылык һәм яхшылык кем исеменнән эшләнсә дә сиңа барыбер түгелмени? Әгәр инде тәкъдир кушуынча исемеңне кире кагып та, синең эшләрең мәңгеләштерелә икән, шулай була бирсен... Ни өчен соң син, кодрәтле тәңрем, җирдә тереклек яратып, кешеләргә үлмәс рух өрдең? Үзеңнең дан-шөһрәтең өчен, кодрәтеңне күрсәтер өчен генә түгел бит! Адәм балаларының гакыл көче, җаннары яңаруын кире какмыйсыңдыр бит?..

Аның табынган алласы бөек һәм кодрәтле, чөнки үз-үзеңне багышлаган эшкә тәңре ихтыярыннан башка гына шулай инану мөмкин түгел... Менә ул, Бачана Рамишвили, синең алдыңда ята. Һәм мин, синең аяк эзләреңдәге бер тузан бөртеге, синең иксез-чиксез мәрхәмәтең белән дөньяга килгән бер ком бөртеге, синең катыңда тез чүгеп, ялварып сорыйм синнән — баш күтәргән бу колыңа мәрхәмәт күрсәт!.. Әгәр инде син аны һәлакәткә дучар иткәнсең икән, аның урынына минем җаным белән тәнемне ал, чөнки мин аны, күңелендәге үз алласыннан ваз кичтереп, синең иманга күндерә алмадым!..

Иорам-ата аягына торып басты, аннары Бачананы өч мәртәбә чукындырып, муеныннан кечкенә тәресен салды һәм шул тәрене сакланып кына Бачананың мендәр астына тыгып, урынына барып ятты...

...Бачана бик озак йоклый алмады. Уянган чакта инде Иорам-ата палатада юк иде. Ул яктыра башлау белән үк киткән иде...

Бер атнадан Бачананың да больницадан чыгар вакыты җитте. Больница хезмәткәрләре белән хушлашу бик дулкынландыргыч булды. Палата врачы белән фельдшер Женя, аны, савыгып, больницадан чыгып китүе өчен кызганган сыман, хәтта елап та алдылар.

Аннан алдагы көнне исә Бачана янына палатага Женя керде һәм кулындагы өч ак канәфер чәчәген сулы банкага куйды да урындыкка килеп утырды. Бачана, «мөгаен, хушлашырга керүедер» дип, елмаеп аның сүз башлавын көтте. Әмма Женя дәшмичә утыра бирде.

— Йә, сүзеңне башла инде, Женя!

Женя ничектер икеләнеп тора бирде.

— Ярый соң, алайса, үзем башлыйм!

Бачана, торып, фельдшер хатын янына килде дә аның кулыннан үбеп алды.

— Кадерле Женя, чынлыкта чәчәкне сиңа мин бүләк итәргә тиеш идем, әмма мәрхәмәтле шәфкать туташы яхшылыкның кадерен белми торган тәрбиясез пациентының бу сансызлыгын гафу итәр дип өметләнәм.

— Бачана Акакиевич,— дип бүлдерде аны Женя,— сез авырган чакта бирегә көн саен бер хатын килеп йөрде... Бик чибәр бер хатын... Килгән саен сезнең хәлегезне сорашты...

Бачананың тыны кысылды.

— Нинди хатын, Женя?— дип сорады ул, аның кем булуын шундук төшенеп алса да.

— Ул ялынып-ялварып үзе турында әйтмәвемне үтенә иде...

— Исеме ничек?

— Белмим... Ул көн саен килеп елый да елый иде... Сез аның кем икәнен чамаламыйсызмы?

— Чамалыйм, Женя...

— Сезне бик ярата ул... Сезгә дип хат калдырды, больницадан чыгасы көнне бирерсез, диде... Менә ул...

Бачана хатны алды һәм, дулкынлануын яшермәкче булып, банкадагы чәчәкләрне рәтләштерергә тотынды.

— Сезне бик нык ярата ул, Бачана Акакиевич!

— Рәхмәт сиңа, Женя!

— Бик әйбәт, бик матур хатын ул, Бачана Акакиевич!

Женяның сөрмә тарткан күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәде.

— Иң әйбәте, иң чибәре син ул, кадерле Женя!— дип, Бачана тагын бер мәртәбә фельдшерның кулын үпте.

Женя урыныннан тиз генә торды да ашыгып палатадан чыгып китте.

Бачана караватына барып ятты һәм калтыранган кулы белән конвертны ачты.

«Кадерлем!

Инде менә хәзер, ялваруларымны ишетеп, ходай тәгалә миңа синең гомереңне бүләк иткәннән соң,— кичерүеңне соравым һәм кызгандырырга теләвем дип аңламасаң,— бөтен кешелек дөньясы күтәрә алмас кебек тоелган, тик шулай да менә бу кәгазь битенә сыеп беткән бар кайгыларымны синең белән уртаклашып, алдында эчемне бушатырга телим...

Моннан егерме еллар элек миннән дә зирәк, миннән

дә чибәр һәм... миннән дә тыңлаусызрак бала булмагандыр... Ата-аналарым үзләренең миллионнарын мине бәхетсез итәр өчен генә тотып бетерделәр... Мин мәктәптә булсын, урамда йөргәндә булсын, беркайчан беркемнең яклашуына һәм кайгыртуына мохтаҗ күрмичә, аны кирәк дип тә санамыйча үстем... Тик бервакыт мин «озатып куябыз» дип артымнан тагылучыларның машинасына утырдым һәм... минем бөтен тормышым чәлпәрәмә килеп, исемем юкка чыкты... Шуннан соң нилэр булганын мин сиңа яза алмыйм... Бу турыда мин беренче тапкыр сөйлим... тәнрем һәм синең каршыңда. Цивгомбори урманында мин тәрегә кадакландым һәм яшьлегем минем әле дә шунда, янып күмерләнгән тәредә эленеп тора...

...Шуннан соң мин уйнап-көлеп яшәдем... һәм менә бүгенгә көнгә килеп җиттем. Җиттем дә кинәт туктап калдым, тәнрене искә төшереп чукынып куйдым. Инде менә хәзер синең катыңа килеп тезләнгән килеш: «Минем корбанымны, ничәмә еллар буе сиңа омтылган, тәмуг газаплары кичергән җанымны кабул ит»,— дип ялварам... Ул газапларыма мин рәхмәт укыйм, чөнки шулар аша юл мине сиңа таба китерде...»

Әгәр шушы минутта врачлар Бачананың кардиограммасын тикшереп карасалар, аңа әле тагын да байтак кына больницада ятарга туры килер иде.

Бачана, ике таблетка седуксен йотып, үзенең йөрәгеннән тынычлануын үтенде. Аннары аны кабат алсу томан чолгап алды, һәм ул йокыга талды. Авыруы дәвамында бу аның беренче тапкыр шулай төшләнми-саташмый йоклаган йокысы булды.

Иртәгесен, һәммәсе белән саубуллашканнан соң, Бачана профессор янына төште. Профессор зур язу өстәле артында нәрсәнедер игътибар белән лупа аша карап утыра иде. Бачана профессорның ни белән мәшгуль икәнен беравык аңышмый торды, ә инде төшенеп алгач, аркасы чымырдап китте: профессор алдында өстәлдә берничә төстәге төрледән-төрле... ясалма йөрәк модельләре ята иде. Бачана, хәле китеп, ишек төбендәге урындыка килеп утырды. Профессор башын күтәрде, гаҗәпләнеп Бачанага карады һәм, керүчене танығач, кулындагы пластмасс йөрәкне өстәлгә куйды да, урыныннан торып, аңа таба атлады.

— Сезне күрүемә бик тә шатмын, Бачана Акакие-

вич, җитмәсә әле, кем әйтмешли, шулай үз аягыгыз белән килүегезгә!

Алар бер-берсенең кулларын кысыштылар.

— Ни булды сезгә?— дип сагая калды кинәт профессор.— Кулыгыз боз кебек салкын!

Бачана, өстәлдә яткан модельләрдән күзен ала алмыйча, һаман шунда карап тора бирде. Профессор шундук хәлне төшенеп алды һәм ашыгып өстәл янына килде дә, бер тартмасын тартып ачып, модельләрнең барсын берьюлы шунда сыпырып төшерде.

— Булса, валерьянка бирегезче...— диде Бачана, көч-хәл белән телен әйләндереп.

Профессор кечкенә шкафтан валерьянка шешәсе алды һәм, стаканга берничә тамчы тамызып, су өстәде дә Бачанага сузды.

— Мәгез, эчегез дә ходай хакы өчен, бернәрсәгә дә игътибар итмәгез!

Профессор Бачананың пульсын капшап карады.

— Куркырлык нәрсә юк, хәзер барсы да үтәр.

Әкренләп Бачана тынычланды.

— Нәрсә ул, профессор?— дип сорады Бачана, ниһаять.

— Җыен юк-бар шунда... Хәлегез аруландымы бераз?

— Рәхмәт, үтте кебек...

— Бик яхшы.. Менә бирегә, креслога күчеп утырыгыз әле... Бераз җанга рәхәтрәк нәрсәләр турында сөйләшик...

Профессор Бачананы тирән йомшак креслога утыртты. Бераз сүзсез торганнан соң Бачана янә:

— Ә шулай да реаль нәрсәме ул, профессор? Ясалма йөрәкме ул?— дип сорады.

— Реаль дип уйлый аласыз... Менә дүрт ел инде бер бозау ясалма йөрәк белән яши... Һәм бу нәрсә сезнең кәефегезне төшерергә түгел, киресенчә сөендерергә тиеш... Эш шунда ки, бер кешедән икенче кешегә йөрәк күчереп утырту көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Сезнең авыру — йөрәкнең үзеннән бигрәк, кан тамырларының авыруы, шулай булгач, билгеле бер вакыттан соң, нинди генә сәламәт йөрәкне күчереп куйсаң да, аның инфаркт миокарда яисә йөрәк эшчәнлегенең җиткелекле булмавы белән авырый башлавы мөмкин... Ясалма йөрәк кую хәзергә иң ышанычлы юл. Бу фикерне хәтта Кристиан Бернард та куәтли. Йә, ярый, бу турыда башка бер вакытта сөйләшербез!— дип кулын селтәде

профессор.— Дөресен генә әйткәндә, мин инде сезне хушлашмыйча китеп барган дип үпкәләргә дә өлгергән идем...— диде ул көлеп һәм Бачананың тезеннән чәбәкләп алды.

— Шуның өчен менә кердем дә инде янығызга. Иң элек, хөрмәтле профессор, күрсәткән игътибарыгыз, кайгыртуыгыз өчен сезгә иң зур рәхмәтләремне белдерәсем килә. Аннан инде, минем караватым янында үткәргән йокысыз төннәрегез өчен гафу итүегезне үтенәм. Һәм, ниһаять, сезнең хезмәтегез, сезнең алтын кулларыгыз алдында баш иям!..— Тупасрак чалымлы, кырыс йөзле, талчыккан күзләре акыллы һәм шәфкатьле бер нур сирпеп торган әлеге күркәм кешене Бачананың кочаклап үбәсе килде.

— Ул кадәр рәхмәт әйтерлек нәрсә юк монда, ә менә мактавыгыз өчен үзегезгә рәхмәт!

— Белмим, бу яхшылыкларыгызга каршы нинди яхшылык белән кайтара алырмын... Күрсәткән игелегегез өчен нинди генә бүләк тә аз булыр... Шуңа күрә, сезне туганым кебек, иң кадерле кешем кебек яратырга рөхсәт итсәгез иде...

— Рәхмәт!— диде профессор, Бачананың сүзләреннән соң ничектер каушап, дулкынланып китеп.— Рәхмәт!— дип кабатлады ул һәм абайламастан язу өстәленең тартмасын тартып чыгарды, ләкин, Бачананың баягы кыяфәтен исенә төшереп, аны шундук кире этеп куйды.

Бачана кычкырып көлеп җибәрде.

— Менә, күрәсезме, сез инде ияләнеп тә җиттегез!— диде профессор һәм ул да көлеп җибәрде.

— Нишләргә кала инде миңа?— диде Бачана кулларын җәеп.

— Минем киңәшләремне исегездә тотсагыз, сезгә андый нәрсәнең кирәге булмаячак!— диде профессор, үзенең дәү кулларын өстәл өстенә салып.

— Әйе, тыңлыйм сезне!— диде Бачана күндәм бер кыяфәт белән.

— Тәмәке тартмаска! Аракы, шәраб ишене — эчмәскә! Майлы ризык — ашамаска! Төн йокыларын калдырып утырмаска! Хатын-кызны — онытырга!

— Һәм шул тормыш буламы инде?— диде Бачана, кәефе китеп.

— Инфаркт миокардадан мин санаган нәрсәләрне алып ташласак — тормышның нәкъ менә үзе инде!—

дип профессор Бачананың алдагы көннәрдә иң гади яшәү формуласын әйтеп бирде.

— Кайчанга кадәр шулай яшәргә тиеш инде мин?— диде Бачана, суга батып барганда саламга ябышкан кебек, өметсез тавыш белән.

— Баштагы ике елда бу режимны үтәү — мәҗбүри, аннары ике ел дәвамында безнең теләкне үтәү йөзеннән саклангыз, ә аннан соңгы ике елда инде сезнең үз иркегездә... Сезне куркытырга теләвем түгел бу, Бачана Акакиевич, ләкин шуны истә тотыгыз: инфарктның сез бик зурын һәм авырын кичердегез, ә аның белән шаярырга ярамый!.. Тиешенчә карап торганда, йөрәкнең эшчәнлеге тулысынча элекке хәленә киләчәк һәм ул сезгә моңарчы күпме хезмәт иткән булса, тагын шуның кадәр әле хезмәт күрсәтәчәк. Ләкин йөрәкне сакларга, кадерләргә кирәк... Йөрәк кадерләгәнне ярата ул...

— Аңладым, профессор... Ә хәзер сезнең белән хушлашырга рөхсәт итегез...— дип, Бачана урыныннан күтәрелде.

— Хушыгыз, Бачана Акакиевич! Безнең больницаны мәңгегә онытыгыз һәм, ходай кушып, сезгә бүтән беркайчан да миңа мөрәҗәгать итәргә язмасын! Врач буларак, әлбәттә!— дип өстәде профессор.

— Мин сезнең яннан тирән бер канәгатьләнү хисе белән китәм... Монда үткәргән ике ай вакытым, Нодар Григорьевич, минем бөтен гомеремә торырлык булды!

— Ни әйтергә теләгәнегезне аңламадым...

— Кеше үз гомерендә бер генә тапкыр булса да каты итеп авырырга тиеш. Шуннан соң ул аек акыл белән, ашыкмыйча бөтен үткән тормышын күз алдыннан кичереп, анализлый, бәя бирә... Шул күзлектән чыгып караганда больница миңа искиткеч зур ярдәм итте...

— Миңа калса, сезнең тормыш кайта-кайта анализлап, бәя бирүгә мохтаҗ түгел кебек...

— Сез шулай уйлыйсызмыни?— дип елмайды Бачана.

— Һич югы, читтән караганда шулай тоела!

— Сезнең больницада үткәргән ике ай гомер минем өчен гаҗәеп зур ачышлар чоры булды!

— Ул кадәр нәрсәләр ачтыгыз соң?

— Мәңгелек канун дигән нәрсәне!

— Нәрсә?!— дип гаҗәпләнеп сорады профессор.

— Мәңгелек канун!— дип кабатлады Бачана.

— Һе-е... Алайса ул законның ниндидер формуласы да бардыр бит инде, шулаймы?

— Әлбәттә!

— Бәлки, формуласын миңа да әйтерсез? Борчылмагыз, Бачана Акакиевич, үзләштерергә яисә уртак автор булырга җыенмыйм!— дип шаяртып куйды профессор.

— Әлеге законның асылы, Нодар Григорьевич, шунда... Кешенең җаны тәненә караганда йөз тапкыр авыррак... Ул шулкадәр авыр, кеше аны ялгызы гына күтәрә алмый... Шуның өчен без — кешеләр — үзебез исән чакта, бер-беребезгә ярдәм итәргә, бер-беребезнең җанын үлемсез итәргә тиешбез: сез — минекен, мин — башка берәүнекен, ә ул — тагын берәүнекен, шул рәвешле бертуктамыйча... Кемнеңдер үлеме бу дөньяда безне ялгызлыкка дучар итмәсен өчен...

Профессор исе китеп Бачананы тыңлап торды.

— Әйе, бик катлаулы закон ачкансыз, Бачана Акакиевич!— диде ул беравык сүзсез торганнан соң.

— Әйе, катлаулы!— дип килеште Бачана.

— Һәм сез аны тормышка ашырырга уйлыйсызмы?

— Шулай булмаганда, бу дөньяда яшәүнең мәгънәсе дә юк, мәсәлән, мин үзем, әйтергә кирәк, хәзерге вакытта инде үлгән булыр идем...

Бачана профессорга кулын сузды, тегесе аңа таба якынлашты һәм Бачана, тыела алмыйча, профессорны кочаклап күкрәгенә кысты.

— Әйе...— дип әйтеп куйды профессор дулкынланып.— Ясалма йөрәк бик үк ярап бетмәс сезгә... Ясалма йөрәк белән яши алмаячаксыз сез... Әкәмәт-сәер кеше икән сез!

Профессор дәү таза кулы белән Бачананың җилкәсеннән чәбәкләгәч, Бачана шунда мәңгелек канунның гамәлгә ашуын аңлады...

Бачана үзен алырга дип килгән машинаны кайтарып җибәрде.

Клара Цеткин урамында ул трамвай юлы аркылы чыкты да 25 февраль урамы[1] буйлап Плеханов проспектына юнәлде.

Больницада яткан ике ай вакыт эчендә Бачана урам шау-шуыннан тәмам бизеп өлгергән икән инде:

---

[1] 1921 елның 25 феврале — Грузиядә Совет власте урнашкан көн.

аның башы әйләнергә, тез буыннары калтырарга тотынды. Ул ашыкмыйча, сакланып кына атлады. Ә Тбилиси үзенең гадәти тормышы белән яши — шау-гөр килә, кычкыра, дулкынлана, ыңгыраша, көлә, гүелди иде.

Плеханов проспектында кара-каршы, ике елга сыман, халык ташкыны агыла иде. Бу ике агымга эләккән кешеләр ташкын эчендәге сал агачларын хәтерләтә иделәр: алар бер-берсенә килеп бәрелешәләр, бер-берсен туктаталар, нәрсә турындадыр сөйләшәләр, кулларын болгый-болгый бәхәсләшәләр, аннары кабат аерылып китәләр һәм кайнап торган ташкын эчендә эреп юкка чыгалар...

Чатка җиткәч, Бачана проспектны аркылы чыкты һәм үзе дә әлеге халык ташкынына килеп кушылды. Ул, барган уңайга, кешеләргә бәрелмичә, аларны читләтебрәк узарга тырышты. Аннары бу проспекттан ул Марджанишвили урамына борылды һәм биредә аны икенче бер, олы елга сыман, зур халык ташкыны бөтереп алды. Бачана, урам ритмыннан бизгән йөрәгенең әкренләп шуңа җайлаша баруын, әкренләп үзенең дә шул шәһәр пульсына күнегә, ияләнә баруын тойды, һәм менә, ниһаять, аның йөрәге әлеге югалткан ритмын тапты һәм сакланып кына, әмма инде кыю итеп, нык ышаныч белән, башкалар кебек үк, ташкынга кушылып китте.

Марджанишвили исемендәге театрның игъланнар тактасы янында Бачана туктап калды. Иртәгә театр аның дусты язган «Изгеләр — тәмугта» исемле пьеса премьерасы белән чираттагы сезонын ачарга җыена иде. Бачананың кинәт җаны эреп, бөтен тәне буйлап ниндидер рәхәт, җылы дулкын таралды. «Изгеләр — тәмугта!» дип күңеленнән кабатлады ул һәм елмаеп куйды.

Күпергә җитәрәк, Бачанага ничектер хәле киткән кебек тоелды, ләкин бу авырттыра, сагайта торган хәлсезлек түгел, бәлки, рәхәт, җиңелчә бер талчыгу иде. Ул узып барган таксины туктатты да уң яктагы арткы урындыкка кереп утырды.

— Кая илтергә сезне? — дип сорады шофер, счетчигын борып җибәреп.

— Мария янына, — диде Бачана.

— Кем янына?! — дип сорады шофер гаҗәпләнеп.

— Мария янына!..

●

Думбадзе Нодар Владимирович

ЗАКОН ВЕЧНОСТИ

(на татарском языке)

Редакторы **Я. Халитов**
Тышлык художнигы **Р. Шәмсетдинов**
Художество редакторы **Ф. Хәсьянова**
Техник редакторы **Ф. Абдрахманова**
Корректорлары **Р. Хәмидуллина, Ә. Вәлиева**

ИБ № 3967

Наборга бирелде 26.3.86. Басарга кул куелды 18.8.86. Формат 84×108 1/32. Типография кәгазе № 1. Гарнитура литературная. Печать высокая. Якынча басма табагы 12,2. Усл. кр. отт. 12,5. Учетн.-изд. табагы 13,1. Заказ Т-195. Тираж 12200. Бәясе 1 сум.

Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.